PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2019 НОЯБРЬ № 11

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

МИНИСТРНЫҢ БЕР КӨНЕ
социаль проектлар эшлиме

КЫЗЫМ-ЙОЛДЫЗЫМ
закон өстенме, намусмы

«КЫЗ БИБИ» МӘДРӘСӘСЕ
мин ачкан дөнья

АЛИЯ ӘХМӘТОВА:

«ТАТАР КЫЗЫ» ТАТАРНЫ ДӨНЬЯГА ТАНЫТА

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә... ...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза! Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Шәүкәт ГАЛИЕВ

КҮПМЕ КҮЗЛӘР КҮРЕП ОНЫТЫЛГАН...

Күпме күзләр күреп онытылган,
Күпме йөзләр чыккан исемнән;
Күпме сүзләр киткән хәтеремнән?! –
Ә син һаман, һаман исемдә.

Ничә тапкыр гүзәлләрне күреп,
Мин минутлык хискә исердем.
Айныдым да, сөенеп туялмыйча,
Тагын сине искә төшердем.

Йөрәгемне, ахры, тутыргансың,
Башкаларга анда урын юк.
Күңелемдә синнән бүтәннәргә
«Сөям» дигән назлы җырым юк!

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Фәридә Гатиятуллина. 1948 ел.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.




Фото: Ксения Богданова

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Алия Әхмәтова
Фото: Анна Арахамия

Алия Әхмәтова өстендә «Александр Богданов» бренды киемнәре.

Верстка:
Резеда Галиуллина
Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды:
31.10.2019 ел.
Заказ О-3073
Тираж 4908

Учредитель:
Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә


Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+

24 НОЯБРЬ – ӘНИЛӘР КӨНЕ



«Оныкларны озаткач». Рабис Салахов эше.

Баш мөхәррир сүзе



...Нечкә иләк була бу кулларда,
Уклау була, җиләк тырысы.
Чигү чигә күлмәк изүенә... (Зөлфәт)

...Бик күп куллар күрдем,
Ләкин, әнкәй,
Синең куллардан да гадел куллар юк!.. (Әнгам Атнабаев)

Әни куллары... Шагыйрьләр, язучылар, рәссамнар аларга багышлап күпме образ тудырган. Дөньяда иң җылы, иң йомшак куллар... Шуларга нәни кулларыбыз белән тотынып, җирдә беренче адымнарыбызны ясадык. Шул кулларга таянып, тормыш дигән зур юлга чыгып киттек. Авыр чакта шул кулларга капланып еладык... Иң чиста кер – әни куллары уганы. Иң тәмле ризык – әни куллары пешергәне. Хәзер инде үземнең кызларым кайчак: «Әни, син ясаган чәй тәмлерәк була», – дип, чәйне миннән ясаталар. «Соң шул ук чәйнектән, шул ук чынаякка ясыйм бит инде», – дип әйтсәм дә, күңелемнән: «Хәйләли инде болар, иркәләнәләр», – дип уйлап куйсам да, аңлыйм аларны...
Дөньяда барысын да булдыра торган куллар... Әлбәттә, әнинеке! Мәктәптә укыган елларым. Бәйрәм алды. Өзмим-куймыйм: «Кичәгә киясе күлмәгем чигүле булырга тиеш!..» Бер төндә чигеп биргән иде миңа аны әнкәй.
Үз әнисе – әбием турында әйткән бер сүзе хәтеремә уелып калган: «Әгерҗегә кайткан чакларда гел әнкәй кулына карыйм... Картаюын шуннан күрәм...» Сиксәнне узган әнкәем янына кунакка кайткан вакытларда хәзер менә үзем дә иң элек аның кулларына күз төшерәм. Үзгәрәләр...
Вакыт бигрәк аяусыз шул... Кадерли алганда кадерләрен белик әниләрнең!

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА

Безнең тышлыкта

Татарстан кызлары өчен «Татар кызы» бәйгесендә таләпләр югарырак: тел белү безнең өчен өстенлек дип саналмый.



26 Асыл икәнеңне онытма!
Гөлнур Сафиуллина

Заман һәм без



6 Социаль проект социальме?
Чулпан Галиәхмәтова

10 Камышлының «ашыгыч ярдәме»
Лилия Гәрәева





16 Гап-гади бәхет
Чулпан Галиәхмәтова


Татар дөньясы



30

Мәсрурә кызы Әнисә
Роза Камалетдинова

Мәдәни тормыш



38

Карлыганнар өлгергән чак
Рәмзия Габделхакова


42

Балалар китапханәсе әкият илен хәтерләтсен ул...
Эльмира Закирова

Яшәеш

48

«Кызым-йолдызым...»
Гөлнур Сафиуллина



52

«Кыз Биби» яки Җәннәт әниләрнең аяк астында
Рәмзия Кашапова

Хуҗабикә



60

Хуплу

62

Витграсс – сәламәтлек эликсиры



СОЦИАЛЬ ПРОЕКТ СОЦИАЛЬМЕ?



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Халык санын арттыру, тормышны яхшырту максатларында гамәлгә ашырыла торган «Демография» илкүләм проекты биш төбәк программасыннан тора. Әлеге проектның күп өлеше Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы җаваплылыгында. Ул ничек тормышка ашырыла, халык үзгәрешләрне сизәме, өч елдан соң нинди нәтиҗәләр булырга тиеш? Әлеге сорауларга җавап бирер өчен без ведомство башлыгы Эльмира ЗАРИПОВАның бер эш көне белән таныштык.

■ 2020 елдан бала карау буенча түләүләр (халык телендәге «Путин пособиесе») 3 яшькә кадәр озынайтыла. Моңа кадәр ул балага яшь ярым булганчы гына бирелә иде. Ә аннан соң ана эшләмәсә, сабый 3 яшькә җиткәнче ай саен 50 сум түләнде. Дөрес, яңа канун буенча пособие алыр өчен гаиләнең аз керемле булуы шарт. Тәгаенләп әйтсәк, керем гаиләнең бер әгъзасына ике яшәү минимумы күләменнән азрак булырга тиеш. Моннан кала, яшь гаиләләргә ярдәм итү йөзеннән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов өстәмә түләүләр булдырды. Хәзер авылда яшәгән 25 яшькә кадәрге хатын-кыз бала тапса – 50 мең сум, 29 яшькә кадәр өченче бала табучыларга 100 мең сум күләмендә акча бирелә. Шулай ук икенче баласын тапкан әниләр өчен ана капиталы да гамәлдә. 2020 елга аның күләме – 466617 сум. Киләсе елдан аз керемле күп балалы гаиләләрдәге 3 яшькә кадәрге сабыйларга дарулар алу өчен 10 мең сумлык электрон сертификатлар кертелә. Ул елга бер тапкыр биреләчәк. Шулай ук киләсе елдан мондый гаиләләр өчен балалар бакчасына айлык түләүләр бөтенләй бетерелә.



Бала тапсаң, дәүләт ярдәм итәр

Министр ачык булырга тиеш, бигрәк тә социаль яклау министры! Эльмира Зарипованың гражданнар кабул итү көненнән кала, интернет кабул итү вакыты да бар. Хәзер авыл кешесенә министр ишеген кагу өчен Казан юлын да таптыйсы юк, интернет кабул итүгә генә язылысы. Министрның бу көне дә нәкъ менә җирлектәге халык белән аралашудан башланды. Экранның теге ягында Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Айгөл Вафина һәм борчыган сорауларына җавап эзләп килгән авыл халкы.

– Балама киләсе елның гыйнварында яшь ярым була. Аз керемле гаилә буларак, бала караган өчен 8896 сум акча алам. Киләсе елга түләүләр бирү вакыты озынайтыла дип ишеттем. Мин ул пособиегә өмет итә аламмы? – дип сорый Чулпан Гарәфетдинова.

Министр төгәл аңлата: быелдан яңа канун кабул ителде, аның нигезендә Чулпан түләүләр алуын дәвам итәчәк, һәм ул бераз артачак та. Бары тик социаль яклау оешмасына барып, гариза язарга, аз керемле гаиләдә яшәвен расларга кирәк булачак. Баласына 3 яшь тулганчы өйдә утырырга җыена Чулпан. Эшкә чыгарга уйласа, җирле җитәкчеләр балалар бакчасына чират юк дип белдерде. Гомумән, «Демография» илкүләм проекты кысаларында 2021 елга мондый чиратларны бетерү бурычы куелган. Ясле группалары да ачылачак. Чулпан ире белән рәсми рәвештә язылышмый гына яши икән. Эльмира Зарипова моңа игътибар итми калмады. «Мөнәсәбәтләр рәсмиләштерелми икән, хатын-кыз юридик яктан яклаучысыз кала. Бернәрсәгә дәгъва итә алмаячаксыз», – дип кисәтте ул.

«Мондый социаль түләүләр булдырылганнан соң, ялгыз әниләр саны артыр дип курыкмыйсызмы?» – дип сорыйбыз министрдан. «Бер минутлык табыш өчен ана үзен дә, баласын да юридик яктан куркыныч астына куяр дип уйламыйм. Әгәр ире белән фаҗига килеп чыкса йә аерылырга туры килсә, ана бернәрсәсез калачак. Аның милеккә дә хокукы булмаячак. Әнә шул хакта уйлансыннар иде», – диде ул.

«Социаль такси» табиб-гериатрга алып бара

«Демография» илкүләм проекты кысаларындагы «Өлкән буын» төбәк программасы, мөгаен, иң колачлысыдыр. Беренчедән, Россиядә, шул исәптән, Татарстанда да, өлкәннәр саны арту күзәтелә. Республикада һәр дүртенче кеше бу категориягә керә. Димәк, әлеге программа күп кешегә кагыла. Икенчедән, 2024 елга халыкның гомер озынлыгын 78 яшькә кадәр җиткерү бурычы куелган. Ә иң мөһиме: гомер көзенә кергән кешеләрнең тормышын уңайлы һәм актив итү. Моның өчен Татарстан быел «Өлкән буын» проекты нигезендә озак вакытка сузылган тәрбия системасы булдыру буенча пилот проектны гамәлгә ашыра башлады. Бу системаны укучыларыбызга аңлату өчен министр Эльмира Зарипова безне Арча районына алып китте.

Өлкән буын кешеләренең 80 проценты хроник авырулардан җәфа чигә. Хәтта берьюлы берничә чирдән интегүчеләр бар. Ә бит яшь алга бармый. Шуңа да өлкәннәр өчен озак вакытка сузылган тәрбия системасы үтә актуаль.

– Быел әлеге проектны республиканың җиде районында башладык, – дип сөйли министр. – Аларда инде гериатрия кабинетлары ачылды, табиб-гериатрлар, махсус әзерләнгән социаль хезмәткәрләре бар.

Кемнәр соң ул табиб-гериатрлар? Алар кеше организмындагы физиологик картаюның табигый процессларын өйрәнә. Өлкән буынның үзенчәлекләрен исәпкә алып диагностика ясый, дәвалый һәм профилактика уздыра. Арча район хастаханәсендә махсус кабинет ачылган. Әлеге яңа эшне районда Рәмзия Хәйруллина башкара. Ул 30 ел гомерен медицинага багышлаган. Ел башында Казанда дүрт айлык махсус курсларда укып кайткан.

– Участок терапевты табиб-гериатр кабинетына 65 яшьтән өлкәнрәк кешеләрне җибәрә. Беренче эш итеп махсус сораштыру үткәрәбез. Нигездә, ул гәүдә авырлыгы, бәвел тоту-



■ Татарстанга федераль бюджеттан бүлеп бирелгән 64 миллион сумнан артык акча ярдәмендә муниципаль районнар өчен 43 автомобиль сатып алынды. «Социаль такси» авылда ялгыз яшәгән өлкәннәргә ярдәм күрсәтә. Автотранспорт – мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр, ягъни коляскаларда йөрүчеләр өчен дә җиһазландырылган. Авылга кайчан килүе турында фельдшер алдан ук хәбәр итеп куярга тиеш. «Социаль такси» өлкәннәрне диспансеризация үткәндә генә килеп алып, китереп куя.

тотмау, мобильлек югалу, егылуларга кагыла. Әлеге анкета сораулары буенча өчтән күбрәк бал җыйганнар игътибар кирәк булган категориягә кертелә. Дәвалау буенча индивидуаль план төзелә. ЛФК белгече, диетолог, неврологка мөрәҗәгать итәргә киңәш ителә. Дәвалау билгеләнгәч, авыру ярты ел күзәтү астында була.

Табибка барып та җитәргә кирәк бит әле. «Өлкән буын» проекты кысаларында агымдагы елның сентябреннән район хастаханәләрендә социаль такси хезмәте эшли башлады. Хәзер район үзәгеннән ерак булган авылларда гомер итүче 65 яшьтән өлкәнрәк булган ялгыз әбибабайларны шушы машиналарга утыртып, диспансеризация уздырырга алып киләләр. «Рәхмәт инде җитәкчелеккә», – дия-дия, машинадан төштеләр Арча районы Курса Почмак авылыннан килгән әбибабайлар. Гомере буе укытучы булып эшләгән Гүзәл апа Гыйниятуллина: «Сәламәтлек яшьләргә дә кирәк, ләкин без, өлкәннәр өчен ул тагын да мөһим. Даими тикшерелеп торам. Галочка өчен генә эшләнми бу, балам. Шунысы бигрәк куандыра», – ди. Өлкәннәрне фельдшер, социаль хезмәткәр озатып йөри. Арча районында аларга еракган күренеп торган махсус жилетлар да тектереп кидерткәннәр.

– Россия Президенты Владимир Путин илне «80 плюс» клубына кертү бурычы куйды. Яхшы тормышта яшәгән сәламәт өлкәннәр санын арттыру дигән сүз бу. Ялгыз яшәгән әби-бабайлар бик нык авыртына башлагач кына юлга кузгала. Районнан машина килеп ала башлагач, сәламәтлекләрен кайгырту артыр дип уйлыйбыз, – ди Эльмира Зарипова.

Урын өстендә калучыларның тормышын ничек җиңеләйтергә?

Озак вакытка сузылган тәрбия системасын оештыру буенча проектка Арча Картлар йорты да кертелгән. Моның өчен директорлары Гөлназ Төхвәтуллина – Мәскәүдә, социаль хезмәткәрләр Казанда укып кайтканнар. Ишегалдыннан ук безне Скандинавия таяклары белән йөрергә чыккан бер төркем өлкәннәр каршы алды. Әүз аякларында йөри алмаганнарга волонтерлар ярдәм итәргә килгән. «Һава суларга еш йөри башладык», – дип шатлана алар. Ярдәмчеләрен көтеп алалар. Сөйләшүгә, күңел бушатуга бик мохтаҗ шул өлкәннәр. Күңел салып тыңлап утыручылар үзенчә бер дәва да бит әле ул. Рухи дәва!

Проект кысаларында үзгәрешләр моның белән генә бетми әле. Үз-үзен карый алмаган әби-бабайлар караватына махсус пәрдәләр куелган. «Гигиена процедураларын үткәргәндә бик оялалар иде. Социаль хезмәткәрдән кала, бүлмәдәшләре дә бар бит әле. Хәзер асларын җыештырган вакытта пәрдәләр белән каплап куябыз», – ди директор. 450 мең сумлык җиһазлар кайтып җитүен көтәләр. Күптөрле функцияле ятаклар, сихәтле мендәрләр урын өстендә яткан картларның тормышын бераз булса да җиңеләйтер дип өметләнәләр.

Инсульт кичергән Роза апа Хәкимова монда әле бер айлап кына яши. Улы да, ире дә үлгәч, картлык көнендә карар кешесе калмаган. «Иртәннән кичкә кадәр тәрбиялиләр безне, игътибар бик зур. Коляскалар белән урамга алып чыкканнарына бик сөенәм. Туганнар, оныклар хәл белергә киләләр, тик берсе дә: «Әйдә, кайтыйк», – дип әйтми, – ди Роза апа. – Әйтсәләр дә, моннан беркая да китмим. Минем хөкүмәткә тәкъдимем бар: ялгызлыктан тилмереп яткан әби-бабайлар күп. Күбрәк ачарга кирәк бу Картлар йортын, интекмәсеннәр иде минем кебек».

Үз өйләре түрендә урын өстендә яткан өлкәннәр дә онытылмый илкүләм проектта. Аларның якыннарын өй шартларында авыруны карарга өйрәтәләр. Арча районының «Шәфкать» үзәгендә, мәсәлән, шикәр авырулы кешене тәрбияләү буенча лекцияләр башланган. Моңа кадәр төрле темаларга 5 курс үткән инде. Зәйтүнә апа Исмәгыйлеваның әнисе күптән түгел шикәр чире белән авырый башлаган. Әнисе белән чираттагы тапкыр хастаханәгә баргач, аңа районның социаль яклау бүлегенә керергә киңәш иткәннәр. Анда махсус мәктәп оештырылуын әйткәннәр. «Моңа кадәр шикәр авырылу кешене карау буенча киңәшләр



■ Урын өстендә яткан якыннарын дөрес итеп тәрбияләргә өйрәнергә теләүчеләр һәр районда эшләгән Халыкка ярдәм күрсәтү үзәкләренә мөрәҗәгать итә ала. Сентябрь аена 225 кеше укыткаҗаннар инде.
Җан башына кереме яшәү минимумыннан 2,5 тапкырга артык булмаган өлкән яшьтәге (инвалид) мохтаҗ кешеләргә «Сиделка» хезмәте бушлай күрсәтелә.

эзләп, интернет актардым. Тик анда бик күп сорауларым җавапсыз калды, дөрес язалар микән соң дигән шигем дә бар иде. Ә монда үзебезнең белгечләр аңлата. Ышанычлы. Мондый укулар әнине дөрес итеп тәрбияләргә мөмкинлек бирде. Дөрес карыйм микән, инсулинны дөрес кадыйм микән, дип, гел борчылып йөрдем. Хәзер белгечләр аңлаткач, курку бетте», – ди ул.

Министр Эльмира Зарипова белдерүенчә, проект кысаларында республикада кеше ярдәменә мохтаҗ ялгыз өлкәннәр өчен «Сиделка» хезмәте дә булдырылды. Ел ахырына кадәр 119 кешегә ярдәм күрсәтү бурычы куелган. Мондый хезмәтләр озак тәрбияләү системасы оештырылган районнарда күрсәтеләчәк. Киләсе елга ул районнар саны 13 кә җиткерелергә тиеш. 2021 елга бөтен республика күләмендә булдырылачак.

Россиядә иң беренче

Арча районының Яңа Чүриле авылындагы психоневрология интернатының яңа корпусы төзелә. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова безне шунда алып китте. Төзелеш барган мәйданны ул даими карап кайта икән. «Яңа төзелгән бинада коридор системасы булмаячак. Ике яки дүрт кеше кухнясы, бәдрәфе булган аерым бүлмәләрдә яшәячәк», – дип аңлатты безгә интернат директоры Рамил Гарипов. Анда шулай ук ял бүлмәсе, тернәкләндерү курслары узачак кабинетлар урнашачак. Туганнарының хәлен белергә килүчеләр өчен күрешү бүлмәләре дә әзерләнә. Интернат директоры Рамил Гарипов сөйләвенчә, психик тайпылышлары булган кешеләр интернатка эләгә икән, моннан чыкмый инде. Гомере буе шушында яши. Туганнары алып киткән очраклар бар, тик бик аз. «Интернатта 32 ел эшләү дәверемдә 30 лап кешене генә чыгардык», – ди директор.

– Төзелеш планыннан күргәнегезчә, кулланылышка тапшырылачак объектта көнкүреш бүлмәләре күп. Хроник авырулы кешеләр булсалар да, үз-үзләрен карый алганнары да бар. Болар барысы да монда яшәүчеләргә уңайлылык тудыру өчен эшләнә, – ди министр.

Интернатның яңа бинасын киләсе елның августында кулланылышка тапшыру каралган. Ул «Демография» илкүләм проекты буенча төзелгән Россиядәге иң беренче объект булачак. Арча районындагы проектлар барысы да ярдәмгә мохтаҗ кешеләр өчен эшләнә. Шуңа да министр нәкъ шушы программаның гамәлгә ашырылу барышын һәрвакыт күз уңында тота. «Иң беренче ярдәм мохтаҗларга булырга тиеш», – ди ул. Өлкән буын проектының асылы шул.

■ Авыл җирендә эшләгән бердәнбер интернатка яңа бина әле 2008 елда гына төзелгән. Анда бүген 365 кеше тәрбияләнә. Тик, ни кызганыч, психик яктан тайпылышлы авырулар саны арта. Бүгенге көндә интернатка урнашу өчен чираты җиткәнен көтеп яшәүчеләр дә бар. Шуны исәпкә алып, быел май аенда Чүриледәге психоневрология интернаты каршында 97 кешегә исәпләнгән яңа бина төзи башлаганнар. Федераль һәм республика казнасыннан төзелеш өчен 71 миллион сум күләмендә акча бүленеп бирелә.



Фото: Анна Арахамия

PRESSA

**Ул бай инвестор да, иганәче дә түгел. Ләкин аның тырышлыгы белән Камышлының әле тагын унбер өендә ут яна, унбер йортның нигез җылысы сүрелми.
Азнакайның Камышлысы белән Ирекле арасы алты чакрым. Көненә бер дә урый ул юлны Рәмилә ханым, ике дә, өч тә... Җил-буранлы кышкы төннәрдә авыл урамында нинди ут бу дисәң, аның машинасы булыр. Андый төнне күзенә йокы керми шул: газлары сүнеп, әбиләр туңып утырмыймы икән дип гасабиләнеп ята да, ахыр түзми, чыгып машинасын кабыза...**





Лилия
ГӘРӘЕВА

КАМЫШЛЫНЫҢ «АШЫГЫЧ ЯРДӘМЕ»

«Гөлүсә апа, кан басымыңны үлчәдеңме, дару эчтеңме әле бүген?» – ди ул, керә-керешли. Шәфкать туташы миссиясен тәмамлагач, аңа күрше йортта телефон мастеры вазыйфасына керешәсе. Фәния апаның телефоны әллә нишләгән әле, тавышы ишетелми башлаган диме... Монда карыйсын карап, барлыйсын барлагач, каршы як капканың келәсе ачыла: «Флера апа, нихәлең бар? Кая, чиләкләрең бушадымы?» Аннары Фаягөл апага, Суфия апага кагыласы... Ләйлә апаның да хәлен белеп чыгасы булыр...

Рәмилә Зәкиева – социаль хезмәткәр. Вазыйфасының рәсми аталышы шулай. Ә әбиләр өчен ул – «безнең Рәмилә». Сердәшчебез, киңәшчебез, аяк-кулларыбыз да, дип өстәп куялар әле ахырдан. Кызы Айгөл белән икесенә унбер әби аларның. Хәер, ник кызы белән икесенә генә дим әле? Әбиләрне карашуда ире Фәрәгатьнең дә, уллары Ирек белән Радикның, Камил белән Каринаның да ярдәме зур лабаса. Әбиләрнең газ казаннарын, электр чыбыкларын алыштырганда, түбәләрен менеп үлчәгәндә, яңа койма тотарга калай кайтартканда аларның ярдәменнән башка булмый да. Яз-көз бакчаларын сукалатасы, чүпләрен түгәсе, тырмалыйсы, утыртасы, өлгергәнен җыясы, урнаштырасы, тозлыйсы, кайнатасы, пай җиренә бирелгән ашлыкны аласы... Бу эшләрне санап киткәнемә аптырадыгызмы? Әйе, боларның берсе дә социаль хезмәткәрнең вазыйфасы түгел. Районның социаль яклау бүлегенә ай саен язып илткән хисап кенәгәсендә дә телгә алынмый бу эшләр. «Бәй, бөтенесен исәпләсәң, әбиләрнең пенсиясе җитмәс, – дип көлә Рәмилә ханым. – Алар бит үземнекеләр». Бу сүзләрендә дә арттыру юк. Апаларның барысы да балачактан ук таныш, якын шул аңа. Ирекледә гомер итсә дә, Рәмилә ханым үзе дә шушы авылныкы. Монда аның әтисе Мөхәммәтдин абзый туган, әнисе Гөлүзә апа килен булып төшкән, алар – биш туган шушы урамда тәгәрәшеп үскән. Бу апалар белән гомер-гомергә бары – бергә, югы уртак инде.







Фото: Анна Арахамия

Шуның өчен дә Рәмилә ханымның язын ничә өйне юып, ничә йортка яңа пәрдә тегеп элүенә, ничә капка, ничә тәрәзә буявына гаҗәпләнмәгез. Үземнекеләргә дип, чын күңеленнән тырышуы. Авылы гына яшәсен, йортларында гына утлар балкысын.

...Гөлүзә апаларда әбиләр чөкердәшә. Рәмилә ханым барысын да чәйгә дәшкән. Бәлеш өлгергәнче, бер яшьлектән урап кайтышлары – хатирәләр сандыгын ачканнар. Барысы да дип әйтерлек сиксәннең теге ягындагылар. «Сеңлем, бу хатыннар – сугыштан соңгы иң авыр елларда шушы колхозны күтәргән хатыннар. Хәзер әнә сызламаган җирләре юк. Бу сүзләрне язмый калдырма, яме!» – сиксәнне узса да, Гөлүзә апаның яшь чактагы гаярьлеге әле дә шул килеш. Язсаң, аның да язмышын бер тарих итеп язарлык. Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлагач, монда зоотехник итеп җибәрәләр Түреш кызын. Сугыштан соң авыл хуҗалыгы әле аягына гына басып килгән 1957 нче еллар. Ул чорның авырлыгы җаннарына сеңгән: «Малларның ашарына печән юк, яшәренә абзар юк...» 30 ел колхозда ферма мөдире була Гөлүзә апа. «Үҗәт иде, егәрле иде, исереп эшләми йөргән ирләрне дә салып кына ега иде», – дип колагыма пышылдаша әбиләр. Дилбегәне кулына урап, тарантаста аягүрә генә басып чапкан Гөлүзә апа пенсиягә чыккач та эштән туктамый әле: якын-тирәнең ятим карт-карчыклары өчен картлар йорты ачтыра. Өлкәннәргә карата кайгыртучанлыгы менә кемнән Рәмилә ханымның.

Кайчан гына шалтыратсаң да, ул гел эш өстендә булыр. Кышын әбиләрнең ишегалдын көрәр, язын бакча казыр, җәен әйләнә-тирәне чабар, лапас сүтәр... Әйе, нәкъ шулай: ишегалдын ямьсезләп тормасын дип, Мәгъдәнүс апаның янтайган лапасын сүтеп, өч машина чүп түккәннәр. Бер шалтыратканымда Вазыйха апага су кертеп, канализация ясап яткан чакларына туры килгән идем. «Безнең авылның ике проблемасы инде. Берсе – су, берсе – юл», – дип зарланышып ала әбекәйләр, ул хакта сүз чыккач. Өйләренә су кергән керүен дә, суны кудыручы насос кына әледән-әле чыгымчылый икән менә. Өйдә дә чак кыймылдаган әбиләр урамдагы коедан су ташый алмый, димәк, социаль хезмәткәргә тагын эш өстәлә. Су булмагач, кер юу машиналары да эшләми. «Кызлары булганнарның кызлары кайтып юа. Булмаганнарыныкын өйгә алып кайтып, үземнең машинада юып, үтүкләп китерәм», – дип, гади генә аңлатып китә Рәмилә апа. Аның өчен болар бар да гадәти, шулай булырга тиеш кебек кенә кабул ителгән эшләр.

Азнакайга – базарга-кибетләргә барасы көннәрен әбиләр бәйрәм көткән кебек көтеп ала. Рәмиләләре һәрберсен чиратлап үз машинасында җилдереп кенә шулай дөнья күрсәтеп, үзе әйтмешли «бераз һава сулатып» алып кайта аларны. Болай азык-төлеккә кытлык кичерми әбекәйләр. Итен дә, балыгын да, сөтен-каймагын, яңа пешкән ипиен дә Рәмиләләре китереп кенә тора. Үзе китерә, үзе пешерә... Көн саен шулай.

PRESSA

Нишләсәләр дә, башта Рәмилә белән киңәшләшә Камышлы әбиләре.

Бүген берсенә әзерләп калдырса, иртәгә – икенчесенә. «Үземнекеләр бит!» – ул гел шулай ди.

«Безнең бәхеттән туган баладыр инде, – диләр әбиләр дә. – Ул булмаса, авылыбыз бөтенләй бушар иде. Үзебезнең генә яшәр җай юк хәзер». Дөресен әйткәндә, үз вакытында алар да итәк тутырып балачага үстергән, җәй көне ишегалды чирәмендә оныклары әүмәкләшкән...

Гайфуллина Фаягөл апаның балалары әнә өчәү. Бер баласы Кемеровода ук, калганнары да читтә, гел кайтып йөрергә ерак. «Балалардан артык булыша Рәмилә безгә. Газ казаным иске иде. Районнан үзе барып алып кайтты, сварщик чакырып ялгатты...» – ди Фаягөл апа. Аңа Флера апа кушыла: «Айгөле дә үзе кебек аның. Быел мунчаларымны юдылар, капкаларымны буядылар. Уңайсызланам, кызым, ярар инде, барысын да эшләп бетереп булмый бит, дим. «Без монда килгәч, эшләргә тиеш», – ди балакаем. Авыррак эш булса, Фәрәгать килә, уллары килә... Көтеп кенә торабыз Рәмиләбезне, кереп хәлне генә белсә дә, рәхәт була». III дәрәҗә Хезмәт даны ордены иясе, 7 нче сыйныфны тәмамлаганнан бирле колхозда сыер сауган Флера апаның сүзен Суфия апа эләктереп ала: «Майда 80 яшьлегемә юбилей үткәрде. Бөтенесен үзе алып кайтып, үзе әзерләде. 30 кешедән артык булдык юбилейда». Мортазина Гөлүсә апа да Рәмилә ханымның ярдәме белән яңа ишек куйдырган, түбәсен калай белән каплаткач, келәтенә су үтми хәзер.

Гәрәева Ләйлә апа арада иң яше булса да, инде дүрт операция кичергән, көндәлек эшләрне генә башкару да аңа авырлык белән бирелә. 43 ел шушы авылда фельдшер булып эшләп, күпме кешене генә дәваламаган да, кемнәрне генә үлемнән алып калмаган ул югыйсә. «Авылны ташлап, йортны калдырып китәсе килми шул. Ярый Рәмиләбез бар әле», – ди Ләйлә апа.

Һәрберсенең иң курыкканы да менә шул – картлык көнендә нигезеннән аерылу. Аларның бу хакта сүз дә кузгатасы килми. «Балаларда бик рәхәт, / Ләкин үз өең түгел. / Анда барсам, күңелем тула, / Йомшак бит ул карт күңел», – дип, шигырь белән сөйләп китә Гөлүсә апа. Флера апаның да күңел дәфтәре буш түгел: «Бәхетлеме, дип сорыйлар, / Бәхетле мин туган авылымда. / Җәелеп яткан яшел басуларым, / Аркылы каен тора каршымда». Аркылы каен – Камышлыга терәлеп кенә торган урман исеме. Авыллары бигрәк матур шул аларның. Мондый матурлыкны ташлап, кемнең китәсе килсен? Күзләренә операция ясаткач, Флера апа бер елны Түбән Камадагы балаларында яшәп алган. «Иртән торып утырам да, башта урамнан баручыларны саныйм. Меңгә тутыргач, машиналарга күчәм. Карчыкларны үтерәсегез килсә, шәһәргә генә алып килегез икән, дидем». «Шулай-шулай, – дип җөпләшә әбекәйләр, – үз нигезеңдә үләргә язсын».

Камышлы кайчандыр зур авыл булган, сыер-сарык, каз-тавык, куян фермалары эшләгән. Җидееллык мәктәбе, китапханәсе, клубы гөрләп торган. Клуб белән китапханә бүген дә эшли анысы. Клуб мөдире Люция һәм китапханәче Розалия ханымнар да, Рәмилә кебек, авылны яшәтүчеләр, ямь өстәүчеләр. Авылдашлар көче белән бәйрәмнәргә әзерләгән концерт-кичәләренең төп тамашачылары исә менә шушы әбекәйләр. Рәмиләләре генә клубка илтеп куеп, алып кайтырга иренмәсен. «Иренмим, нинди иренү ди. Өйдәге мал-туарны, бала-чаганы барлыйм да, хәзер килеп җитәм», – ди ул үзе елмаеп. Әйе шул, монда әбиләре көтсә, Иректедә зур хуҗалыгы, балалары көтә.

Ә алар җидәү аның. Үзләренең өч уллары янына тагын дүрт кызны сыендырган олы йөрәкле гаилә бу. Минем исә мондый киң күңеллелекнең серен беләсем килә. Рәмилә ханым өчен монда да ис китәрлек берни дә юк: «Камилебез бик авырлык белән туды. Ул исән калса, бер ятимне алам, дип адарынган идем. Безгә килгәндә Айгөлгә 8 яшь иде. Бик боек иде ул, гел елады. Малайлар арасында үзенә генә күңелсездер, әллә иптәшкә тагын бер кыз алыйкмы, дидек. 9 яшьлек Каринаны Казандагы бер гимназиядән җитәкләп алып чыгып бирделәр. Хәреф тә танымый иде. Акылында кимчелеге бар, дип, аны коррекцион мәктәпкә билгеләделәр. Баланың берүзен анда калдыруы бик кызганыч, бер-берләренә иптәш булырлар дип, апалы-сеңелле Маша белән Виканы алдык...»

Көн дә алты чакрым килеп, ничә кешегә хезмәт күрсәтүе (хезмәт күрсәтү түгел, аларның тормышларын җигелеп тартуы) әнә шушы киң күңеллелек, миһербанлылык белән аңлатыла да. Камышлы әбиләренең иң кадерле кешесе ул Рәмилә ханым. «Берүк исән булсын да, бездән баш кына тартмасын инде», – ди алар. Аннары: «Ул бит безнең яшәтүчебез», – дип тә өстиләр.



ФОТОБӘЙГЕ: «ОБЪЕКТИВТА – ӘНИ»



Фото: Гөлүсә Закирова. Казан.

Әни...
Безнең өчен дөньяда кадерледән-кадерле, газизләрдән-газиз зат... «Сөембикә» журналы редакциясе һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгы оештырган «Объективта – әни» бәйгесе моның шулай икәнлеген тагын бер кат күңелләргә салып куйды. Ана бәхете турында иде безнең бу фотоконкурс. Ана шатлыгы, ана сөенечләре турында. Аның безгә биргән Җылысы хакында...
Фотосурәтләр бик күп килде! Катнашырга теләк белдергән һәркемгә рәхмәтлебез! Бәйге хәзер сайтка күчә: 1 ноябрьдән башлап бу фотосурәтләр өчен тавыш бирергә мөмкин.
Ай азагында – Әниләр көнендә конкурска йомгак ясалачак, җиңүчеләр билгеләнәчәк.
Иң уңышлы эшләр «Казан Кремле» музей-тыюлыгындагы «Манеж» залында узасы күргәзмәгә урнаштырыла.
Бәйгенең соңгы көнендә карар кабул иттек: конкурс тәмамлана, әмма проект дәвам итә. Димәк, фотосурәтләрегезне безгә юллый аласыз. Иң уңышлылары журнал битләрендә дөнья күрер.



УЙНАРГА ВАКЫТ ЮК!

Өч яшьтә – музыка мәктәбенә, дүрт яшьтә – инглиз теле, алты яшьтә – мәктәпкә әзерлек курсларына. Оһо, күкрәк балалары өчен югары математика дәресләре дә ачылган икән. Бассейнга йөртергә дә кирәк, бию дә комачауламый, буш вакыты гына калмасын да, башкалардан ким булмасын! Замана әниләренең лозунгы: үзен хөрмәт иткән һәр әни баласын нинди дә булса түгәрәккә йөртергә тиеш!



Раилә ХӘЯЛИЕВА

Мондый тырышлыклар, әлбәттә инде, бала бәхете өчен дигән изге ният белән эшләнә. Әмма торган саен арган-талган әти-әниләр күбрәк очрый, ни теләгәнен үзе дә белмәгән, әмма аның өчен нидер хәл иткәннәренә ияләшкән боек балалар арта тора. Шунысы гаҗәп менә! Нейропсихолог Нуршат Галимова белән замана әниләренә хас уртак сыйфатларны барладык.

ТҮГӘРӘКЛӘР, КЛУБЛАР, СТУДИЯЛӘР... КҮБРӘК БУЛГАН САЕН ӘЙБӘТРӘК! Бар дөньяга үзебезнең һәм безнең балабызның беренче икәнен исбатларга тырышабыз. Балалар әти-әнисенең уңыш билгесе булып тора. Ә уңышлы бала ул ике-өч түгәрәккә йөрергә, чит телләр белергә һәм талантлары белән башкалардан аерылып торырга тиеш. Уйлап карагыз әле, сез нинди нәтиҗә булуын телисез? Уңышлы

бала үстерергә телибез, диләр күпләр. Ә дөрес җавап – мөстәкыйль, үзенә ни кирәген аңлаган бала тәрбияләргә тырышабыз дию дөрес булыр иде. Киләчәктә ул, нишләп мине математика түгәрәгенә йөрттегез, минем спортчы буласым килгән иде, дияргә дә мөмкин бит.

КИҢӘШ: Безнең чорда әллә нинди түгәрәкләр булмады. Шуңа күрә бүгенге әти-әниләр үзләре ала алмаганны балаларга бирергә тели. Балага үз хыялларыбызны такмас өчен, аны мөстәкыйль шәхес итеп күрергә тырышырга кирәк. Аның кызыксынуларын, үсешен, Аллаһ биргән талантларын күзәтегез. Бала фикеренә дә колак салыгыз. Әгәр дә баланың бөтен уенчыкларын чәчеп салып, үзе теләгәнчә рәхәтләнеп уйнарга да вакыты юк икән, ул үзен ничек бәхетле хис итсен инде!

«СИН УТЫРЫП ТОР, МИН ҮЗЕМ!» ЧАМАДАН АРТЫК КАЙГЫРТУ. Тормышның тизлеге зур. Тормыш арбасыннан төшеп калмаска дия-дия йөгерәбез, артыннан этеп булса да, баланы да шул ритмга кертергә тырышабыз.

«Син борчылма, балам, мин үзем!» Үзең эшләгәндә тизрәк тә, чистарак та була. Бала өлгерер әле, эшен эшләргә дә, киенергә өйрәнергә дә... Балага үзенчә булырга, үзенә әйбер сайларга, хәтта үз фикерен әйтергә дә урын калдырмыйбыз түгелме?! Безнеңчә икән – дөрес, ә бала теләге?.. Бала тормышына артык «кереп китүнең» тагын бер куркыныч ягы – бала да, әни дә үз тормышы белән яшәми. Зуррак балалар әниләренең артык кайгыртуыннан ояла да башлый хәтта.

КИҢӘШ: Кирәгеннән артык кайгыртканда, аның өчен барысын да хәл иткәндә без баланың төрле үсеш юлларын томалыйбыз. Баш мие ялкаулана, минем өчен барысын да уйлыйлар дигән халәткә күчә икән. Ә бала җайлы юл белән барырга ияләшә. Чыннан да, әгәр синең өчен барысын да эшлиләр икән, нигә тырышырга ди әле? Балага өйдә ул булдырып чыгардай эшләр кушыгыз, вазыйфаларын барлагыз. Сезгә ошамаса да, киемнәрен үзе сайласын. Аның фикерләренә дә колак салыгыз. Үзе өчен үзе җаваплы икәнен тоярга ярдәм итегез.

ГАЕП ҮЗЕМДӘ... Үзеңне гаепләү – бала тәрбиясендәге иң начар киңәшче. Әмма бүген әниләрне нәкъ менә «гаеп» хисе белән капкынга алалар. Балаңның рекламада күрсәтелгән уенчыгы да юк, киемнәре дә брендлы кибетләрдән түгел, футбол түгәрәгенә дә язылмаган. Үзеңә алгансың, ә балаларга?!. Балага вирус ияргән – әйбәтләп карамагансың! Трамвайда кычкырып елыймы – тәрбияләмәгәнсең! Үзеңне тыеп кала алмыйча балага кычкырдыңмы?! Шундый күп бу «гаепләр». Һәм күп кенә әниләр бу хисне кирәксез уенчыклар, тәм-томнар белән томалап куярга тырыша.

Гомумән, балага узуга әни кеше «гаеплеләр» сафына кереп баса кебек: «Кофе эчәсең? Ничек инде, син бит хәзер ике кеше өчен җаваплы!» Һәм шулай дәвам итә...

КИҢӘШ: Үзебез күз алдына китергән, социаль челтәрләрдә тудырылган әни образына туры килмәгәндә үз-үзеңне гаепләү хисе барлыкка килә. Идеалга күбрәк омтылып, үзебезнең асылыбызны онытып җибәрмик әле без, әниләр. Башкалар белән ярышудан туктарга кирәк. Нәрсәдә үзегезне гаеплисез – шуны кәгазь битенә язып чыгыгыз. Кем белән булса да сөйләшегез, эчегезгә җыеп йөри күрмәгез берүк!

ӘНИЛӘРГӘ ДӘ ЯЛ КИРӘК! Әниләр ни өчен ара? Чөнки бар әйберне үзләре эшләп, бөтен әйберне контрольдә тотарга кирәк дип уйлыйлар, барысына да өлгерергә тырышалар, үзләренә вакыт бүлеп бирә белмиләр һәм балачактагы күңел яралары әни булган вакытта ачыла...

КИҢӘШ: Баланың гына түгел, үзегезнең дә йокыгызны саклагыз! Хуҗалык эшләрендә башкалардан ярдәм сорарга уңайсызланмагыз. Барлык мәшәкатьләр дә әнинеке генә булып калмасын! Телефонны сирәгрәк куллану да сезнең файдага булыр. Балаларыгызның елмаюыннан, алар белән уйнаудан, назлап-сөюдән энергия алырга өйрәнегез!

Әниләр! Әллә ни таләп итмичә, бәлки, бала белән күбрәк уйнарга, шатланырга, хәтта кушылып җырларгадыр?! Әниләр ярышыннан чыгып, форумнар, чатлар укудан туктап, бу ярыштан төшеп калып, тынычланыйк, үзебезне бәхетле итә торган әйберләр белән шөгыльләнә башлыйкмы әллә?

Ә балаларныңмы?! Балаларның – бары бала буласы килә. Туп тибәсе, күлдәвеккә кереп тәпиләрне юешләтәсе, кар көртеннән сикерәсе, әти белән футбол уйныйсы, койма башына менәсе, салкында туңдырма ашыйсы...

Шулай да балалар өчен без эшли алган иң зур эш ул – аларны ничек бар шулай кабул итү, матур итеп хыялланырга өйрәтү, теләкләренә терәк булу, зур һәм мәгънәле кеше булып үсәргә булышу. Моның өчен әллә ни күп әйбер дә соралмый. Бала белән күбрәк бергә булырга, уйларын дөрес якка юнәлдерергә һәм яратырга... Тәрбия турындагы китапларны читкәрәк этеп куеп, баланың киңәшчесенә, дустына, аның белән вакыт уздырырга иренмәгән чын дустына әйләнсәк, бәхет һәм уңыш тормышыбызга үзе килеп керәчәк әле!

Әниләрне балалар ничек бар, шулай ярата бит! Үзегез өчен дә яшәргә вакыт табыгыз, әниләр!

Фото: www.pixabay.com



ГАП-ГАДИ БӘХЕТ

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

«Рәхәтләнеп эшлибез, әле кичен концерт булса, клубка чыгарга да хәл кала. Авылларны бетә диләр, без аңламаган әллә нинди җилләр дә исештерде, Нәзилә кебекләр булганда, бетми ул авыл, гөрләтеп яшибез әле!» Түбән Кама районы Кызыл Чапчак авылы басу түрендә эшләгән өлкәннәр сөйли. Нәзилә тыйнак кына елмаеп басып тора. Авыл хуҗабикәсе әнә шундый булырга тиештер инде ул. Ярдәм кулы сузарга әзер булган, ипле, йөзеннән елмаю китмәгән, эштән курыкмаган, кирәк икән трактор да иярләгән, сәхнә идәннәрен сындырырлык итеп ут чәчеп бии дә белгән татар хатыны. Хәер, бу исемне быел район буенча үткән бәйгедә дә беренчелек алып раслап кайтты Нәзилә ТАИПОВА.

«Уңыш җыеп бетергәч, гармуннар белән җырлашып утырабыз...»

Өченче буын яшелчәчеләр

Кызыл Чапчак авылында фермерлар хәтсез. Кемдер җиләк үстерә, кемдер – икмәк, кайсылары – яшелчә. Таиповлар – өченче буын яшелчәчеләр. Нәзиләнең ире Искәндәрнең бабасы колхозлар таралганчы яшелчәчелектә эшләгән. Үз хуҗалыгында да кыяр-помидор үстереп саткан, авылдашларын да татар халкы өчен ят булган яшелчәләрне үстерү серенә өйрәткән. Оясында ни күрсә, очканында шул булыр, диләр. Улы Өлфәт тә атасы юлыннан китә. Туксанынчы еллар ахырында фермер булып теркәлә. Атасы янында кырда эшләп үскән Искәндәр дә авылда кала. Юк, җир эшенең нәрсә икәнен беләм мин, дип, Түбән Камага йөреп эшләп карый әле ул. Юлда булачак хатыны Нәзилә белән таныша. Зәй районы Аксар авылы кызы шәһәрдә педагогика көллиятендә укый. Авылына юл Кызыл Чапчак аша үтә. Автобуста таныша алар. Яшьләр эшне тиз тота. Берничә ай гына Аксарга сукмак сала да Искәндәр, кушылып та куялар. Икесенә дә 20 яшь – җир җимертеп эшләр чаклары. Җиң сызганып, бергәләшеп фермерлык эшен алып бара башлыйлар. Яшелчәләрне сакларга складлар төзиләр. Өч ел элек комбайн алып кайтканнар. Бәрәңге җыйганда кул да пычратмыйлар. Комбайн җыя да машина арбасына бушата.
Җир эшендә тәҗрибәле Өлфәт абый белән Гөлнур апа балаларына киңәшләре белән ярдәм итә. Юлын күрсәтеп, фермерлык серләрен өйрәтеп бетергәч, дилбегәне яшьләргә тапшыралар да, узган ел шәһәргә күченеп китәләр. Бер караңгыдан икенчесенә кадәр тир түгеп яшәгән авыл кешесе гомер көзендә булса да ял итәргә тиештер бит?!

Таиповлар алган уңышларын кая куярга белми аптырамыйлар. Йә шәһәрдәге заводларга тапшыралар, йә күрше районнан килеп алалар. 200 гектар җирләренә бөртеклеләргә дә урын җитә, печәнлекләре дә бар. Быел үзләре өчен яңа культура – борай да чәчкәннәр. Иң зур ярдәмчеләре – авыл кешеләре. Иртә яздан караңгы көзгә кадәр булышалар аларга. Фермерларга ярдәм итәләр Кызыл Чапчаклылар, бигрәк тә Нәзиләләргә. Ни өченме?

«Шау-гөр килеп эшлибез дә, бәйрәм дә итәбез»

Без килгәндә шәһәр ярминкәләренә алып китәр өчен кишер җыеп яталар иде. Трактор җир өстенә чыгарган тамыразыкларны җыеп, капчыкларга тутыралар. Әйтерсең эшләмиләр, ә күңел ачалар. Бер төркем өлкәннәр басу яңгыратып көлешә. Быелгы көзнең кояшлы килүе кәефләрне тагын да күтәргәндер, мөгаен. Яңгыр астында җыймыйлар бит. Хәер, андый вакытларда да эшлиләр, ташламыйлар. Иң өлкән ярдәмчеләре Асия апа Исхаковага 71 яшь!

– Нинди авыр булсын? Шушында кеше арасында эшләү үзе бер рәхәт, – ди Асия апа, олы яшьтә бил бөгү җиңел түгелдер инде дигән соравыма. – Өйдә көн буе болганып йөреп арып бетәм.
Ә монда эшләп кайтсам, икенче сулышым ачылган кебек була, өй эшләренә дә хәл кала. Пенсиягә чыкканнан соң кырдан кайтканым юк минем. Өлфәт һәм Гөлнур заманыннан ук эшлим. Күңеллелеге дә бар, тормыш та куша инде, җаный. Ярдәм иткәч, үзләре дә буш калдырмый: яшелчәсен, икмәген бирәләр. Җитмәсә, бик ярдәмчелләр. Беркөнне ком кирәк булды. Искәндәргә килдем инде: «Иртәгәгә бик кирәк иде», – дим. Кичке тугызда кайтарып түкте, рәхмәт яугыры. Сүз тыңламый калганнары юк, ничек булышмыйсың инде мондый кешеләргә. Җитмәсә, басуга алып баралар, төшереп куялар, җәяүләп йөрисе дә юк бит».









Фотолар: Анна Арахамия һәм гаилә архивыннан

Көндез кырда тир түксә, кичен клубта күңел ача авыл халкы.







Шуметова Фирдания апа белән Шәвәлиев Илсур абый Югары Чаллы авылыннан килеп эшлиләр. Илсур абый белән кушылганнарына әле өч кенә ел. Күрше авылга кияүгә китсә дә, онытмаган Нәзиләләрне. Тугыз ел буе эшләгән басуны ничек калдырмак кирәк! Ирен дә иярткән, авылдагы хатыннарны да җыеп алып төшә икән.

– Бигрәкләр дә яхшы кешеләр шул. Үзләре уңган, ярдәм сорасак, бервакытта да баш тартмыйлар. Нәрсә сорыйбыз, бөтенесен өйгә китереп бирәләр. Ул Нәзилә әллә гел йокламый инде. Бөтен нәрсәгә җитешә бит. Кайтып йөреп вакыт әрәм итмик әле дип, әбәт вакытында һәрвакыт кайнар ризык пешереп алып килә. Ашы, второе, кайнар чәе... («Салат та ясап алып килә әле», – дип кушыла бер абзый. – *авт.*) Авылны яшәтүче көч, тучны авыл хуҗабикәсе инде безнең Нәзилә.

– Уңышны җыеп бетергәч, сарык чалып, шашлык ясыйлар. Нәзилә каз бәлеше пешерә. Монысы инде традиция, – дип сүзгә кушыла Илсур абый. – Самавыр чәйләре эчеп, гармуннар белән җырлашып утырабыз. Элек кырда үткәргәннәр, хәзер складта утырабыз рәхәтләнеп. Бик кызык уза бәйрәм, күңелләр ачылып китә. Икесе бергә алып баралар алар тормышны. Бер-береңә ярдәм итмәсәң, тормыш гөрләп бармый шул ул.

Көндез Нәзилә белән бергә – кырда, кич клубта алар. Фирдания апа белән Илсур абыйны да шул клуб таныштырган. «Нәзиләләр оештырган концертта таныштык», – ди алар.

Авыл кайчан яши?

Кызыл Чапчакта мәдәният учагы гөрләп эшли. Авылга яшәү сулышы өрүче урын ул. Халык театры дигән исемнәре дә бар. Режиссер Галия апа Хатипова белән китапханәче Зөбәрҗәт апа Нургалиева ике дистә ел эшлиләр инде. Быел Нәзиләне клуб мөдире итеп билгеләгәннәр. Гармунчылары, сәнгать җитәкчеләре бар. Авылда яшьләр дә күп түгел. 400 кешелек салада нибары 9 бала – мәктәп укучысы. Өч катлы мәктәпләре ябылганнан соң, укырга күрше авылга йөриләр. Эшләп торган Картлар йорты, хастаханә ябылгач, халыкка хезмәт урыны калмаган. Шуңа күрә яшьләр дә эш эзләп шәһәргә чыгып китә. Тик җомга кичен үк авылга кайтып җитәләр икән. Ә балалары җәй буе да, каникулларда да авылда – әби-бабалары янында.

– Безгә балалар бакчасына йөргән кебек йөриләр. Алар белән мәш киләбез. Һәр елны балалар Сабан туе үткәрәбез. Ахырда каз





боткасы пешереп ашатабыз. Киләсе елга зурдан кубып үткәрергә планлаштырабыз. Төрле түгәрәкләр оештырабыз, балалар белән ай саен спектакль куябыз. Балалар белән бергә яңа биюләр өйрәнәбез. Нәзилә бик оста бии. Моряк биюләрен башкарганын күрсәгез әле сез аның, – ди Галия апа.

Китапханәдә «Сердәш» өлкәннәр клубы эшләп килә. «Бик яратып йөриләр, һәр чарада теләп катнашалар. Бәйрәм саен концерт оештырабыз. Әйтми калсак үпкәлиләр дә әле. Узган концертта җырлаган идем, монысында шигырь сөйлим әле дип кенә торалар», – дип сөенә-сөенә сөйли Зөбәрҗәт апа.

Үзләре сценарийлар төзеп, кызыклы итеп оештырган концертларын карарга бөтен авыл халкы килә. «Клуб шыгрым тулы була, басып алкышлыйлар, ә менә Казанның түләүле концертларына алай күп йөрмиләр», – дип горурланалар җирле мәдәният хезмәткәрләре.

Мәдәният йорты ишегалдыннан ук музей башлана. Килгән кешеләрне талдан үрелгән читән, шунда эленгән чүлмәкләр, чылбырлы кое, бодай көлтәләре каршы ала. Китапханәдә дә авыл тарихына багышланган кечкенә музей бар. Нәзилә мәдәният йортына килгәч, киңәшләшкәннәр дә, беренче эш итеп ябылган мәктәптә калган музей экспонатларын җыеп алып төшкәннәр. Фойеда ясалган күргәзмәдә хәзер мамонтның тешләренә кадәр бар. «Борынгы гадәт-йолаларны онытмас, авылны бетермәс өчен кирәк ул музей. Балалар авылның тамырын белеп үсәргә тиеш», – ди Нәзилә. Фантазиясе бай клуб мөдире: «Апалар, әйдәгез, оештырабыз», – дип кенә тора. Бергәләп спектакльләр әзерлиләр. Авыл халкы да, аптыратмагыз әле, дип тормый, бик теләп катнаша. Әле гастрольләргә дә йөриләр. «Спонсорыбыз бар безнең», – дип елмаялар Искәндәр ягына карап. Анысы машинага төяп күрше авылларга алып чыгып китә, фотога да төшерә.

Мәдәният йортын төзекләндерергә кирәк. Клуб мөдиренә шул уй тынгы бирми. Быел аз-азлап тотынганнар, тик шулай да капиталь ремонт таләп ителә. Республика программасы буенча ремонт берничә елдан соң гына ясалырга тиеш. «Безнекеннән дә начаррак клублар барын беләбез лә соң, үзебезнекен тизрәк матурлатасы килә», – ди Нәзилә. Гөрләп торган мәдәният учагын тагын да ялкынландырыр өчен кайчак җитәкчеләрнең бер сүзе җитә дә соң...

Икәү тартсаң, авыр түгел

– Мин ансыз ике кулсыз. Искәндәр – терәгем, – ди Нәзилә, бу кадәр эшкә ничек өлгерәсең җитешеп бетәсең соң дигән соравыма. – Киңәшләшеп яшәсәң, барысына җитешәсең ул.

Әле бит өйдә дүрт бала бар. Дөрес, алар үзләре дә ярдәмче. Уллары Илназ Түбән Кама нефтьхимия көллиятендә укый. Ялларда әтисе белән техника арасында кайнаша. 12 яшьлек Алия сеңелләрен караша, ашарга пешерә. 10 яшьлек Дилия – апасының ярдәмчесе. Ә менә 4 яшьлек Зәлия – өй хуҗасы. «Ул безне кубызга биетүче», – дип көлеп алалар кечкенәсе турында. Өйдә зур хуҗалык. Өч сыер сава Нәзилә, печән вакытларында ире белән тракторда да эшли. Басуга агу сибәргә ярамый дип, ярдәмгә килгән авыл халкы, мәктәп укучылары белән бергә 6 гектарлы кәбестә басуын кәтмәннәргә дә чыга. Тиз генә өенә кайтып, ашарга әзерләп килергә дә өлгерә.

– Тиздән кыш җитә, бераз иркенәеп ял итәрсез инде, – дим.

– Кыш көне Түбән Камада сату ноктабызны ачабыз. Анда үзебез үстергән яшелчәне сатарга йөрим, – ди Нәзилә.

Уңган авыл кешесе ял итә белми ул. Ел дәвамында эшләсәң генә нәтиҗәсе дә күренә, табыш та арта.

«Авылыбыз бик ярдәмчел», – дип сөенә Нәзилә. Таш атканнарга, аш белән җавап бирүчеләргә генә ярдәм итәргә ашкынып торалар бит. Таиповлар – әнә шундыйлардан. «Җир – ашатучы, гүзәллек тудыручы. Авыл – тирә-якны туендыручы», – ди Нәзилә.

Кешеләрне, җирне яратканнар гына авылны яшәтә шул...








Ярты миллионлы тираж белән бөтен СССРга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да... Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

МАЙОР АГЕЕВА




























Фото: Анна Арахамия

Рәисә Агеева:
Яшьлегемдә җырларга һәвәс идем. Институтта укыганда «безнең сандугач» дип атап йөрттеләр. Консерваториягә ничә чакырсалар да, әтинең рөхсәте булмагач, җөрьәт итмәдем. Ялгышым булдымы, язмышыммы...

Татарстанның Эчке эшләр министрлыгында зур җыелыш бара. «Агеева, тиз генә керегез әле», – дип чакыртып алалар аны. Өстәл тирәли таныш түгел берничә кеше утырышкан, бар да елмаеп аңа текәлгәннәр. Милиция хезмәткәрләре көне уңаеннан, «Азат хатын» журналының ноябрь саны тышлыгында аның фотосын бирергә телиләр икән.

Урамда – алтын көз. Аяк астындагы сары яфракларны кыштырдатып, фотога төшәргә матуррак урын һәм милиция машинасы эзләп китәләр. 1975 ел була бу. Соңыннан, журналның ул саны дөнья күргәч, аңа килеп-килеп әйтәчәкләр әле: «Рәисә Агеева! Бу бит сез! Без сезне танадык». Бер көндә әнә шулай билгеле кешегә әвереләчәк ул.

2019 ел. Октябрьнең соңгы көннәре. Рәисә ханымны фотога төшерү өчен күңелгә ятышлы урын эзләп, Казан урамнарын әйләнәбез. Тарих кабатлана.

Милициянең дежур бүлегенә эшкә урнашканда Айрат белән Ирекнең әниләре була инде Рәисә ханым. Бер тәүлек эшләсәм, ике көн балалар янында булырмын, дип уйлый Казан педагогика институтының тарих-филология факультетын тәмамлаган яшь белгеч. Әмма «балалар үстерү өчен уңайлырак эш» дигәненең бөтенләй киресе булып чыга бу хезмәт. Бәйрәмнәр җитсә, ял көнең белән исәпләшү юк, милиция хезмәткәрләренең бурычы – халык арасында тәртип саклау. Әле ярый балаларны (ә аның инде алар ул вакытта өчәү!) карашырга әнисе бар, әле ярый ире аңлый торган кеше. Яңа елларны да, Сабантуйларны, хәтта туган көннәрне дә аларга әниләреннән башка гына бәйрәм итәргә туры килә. Биш ел Эчке эшләр министрлыгының үзәк аппаратында эшләгәннән соң, милиция отличнигы, ул чакта капитан дәрәҗәсендәге Рәисә Агееваны Мәскәү районының Эчке эшләр идарәсенә махсус комендатурага инспектор итеп билгелиләр. Комендатура урынына төзәтү эшләре бүлеге ачылгач та, Рәисә Гобәйдулловна үз вазыйфасын ташламый. Дөресрәге, җибәрмиләр аны. Югыйсә бу эшеннән китәргә күпме талпына ул... Җинаятьчеләр белән эшләү, иртәнге биштән Казан базарларына патрульгә чыгу гына түгел, еллар буе формадан йөрү дә ялкыта икән. «Гомер буе эшкә матур күлмәк, биек үкчәле туфлиләр киеп килергә хыялландым. Бер вакыйга әле хәтеремдә, – дип искә ала Рәисә Гобәйдулловна. – Җәй челләсендә, баргач алыштырырмын дип, эшкә күлмәктән киттем. Ишектән дә уздырмадылар. Елап чыгып барганда шул еллардагы эчке эшләр министры Салих Япеев каршыма очрап, бүлмәсенә алып керде. «Мин бит шәһәр кызы, монда мине барысы да таный. Эшкә барганда гына булса да, күлмәк кияргә ярамыймы? Формадан бик эссе бит», – дидем. Ә ул минем җитәкчемне чакырып кертте дә: «Бу ни хәл, эсседә нинди форма ул?!» – дип ачуланып та ташлады».

Эше катлаулы булса да, Рәисә ханым бу өлкәдә 58 яшькәчә хезмәт куя. Җинаятьчеләр, тәртип бозучылар белән эшләсә дә, ул аларга иң элек кеше итеп карый. Дәү әнисенең әнисе сөйләгәннәр балачактан күңеленә сеңеп калган. «Кызым, булыша алганда, булыш», – ди ул аңа. Шуңа да ул тәртип бозучыларны төрмә җәзасыннан коткарып калуны үзенең олы максаты дип саный. Соңыннан аларның килеп әйткән рәхмәт сүзләре аның бу максатына ирешү дәлилләре түгелме?!

Лилия ГӘРӘЕВА

УТ УЧАКТА ГЫНА ЯХШЫ





Гөлнур
ХӘСӘНШИНА

Хатын-кызлар өчен «ярамый»лар аларның эш урынында шундый күп! Матур күлмәк, итәк кияргә ярамый. Чәчләрне таратырга. Колак алкасы тагарга, йөзек кияргә. Бизәнергә. Тырнакларны ачык төсләргә буярга. Үкчәле аяк киеменнән йөрергә! Йөзегез ничек үзгәргәнен сизеп торам... Ә алар елмая гына. «Гел формадан йөрергә беренче мәлләрдә генә авыр тоела, аннары күнәсең», – диләр. Үзләре сайлаган һөнәрнең холыкларын шактый кырысландыруын да яшермиләр. Аларга башкача ярамый да – ут белән шаярмыйлар.

Минем әңгәмәдәшем – Азнакай шәһәренең 24 нче янгын сүндерү частеның янгын куркынычсызлыгы буенча профилактика бүлеге инженеры Зөһрә Әхмәтҗанова. Үз эшенең үзенчәлекләре, нечкәлекләре турында сөйли ул.

– Турыдан-туры янгын сүндерүдә катнашучы хатын-кызларны Татарстанда эзләмәгез – тапмассыз. Элегрәк, сугыштан соңгы елларда, ир-атлар җитмәгән вакытларда очраштыргалаган – хатын-кызлар да янгын сүндерүче булып эшләгән. Ә хәзер алар Россиядә дә бармак белән санарлык. Бәлки, исегездәдер, Санкт-Петербургта янгын сүндерүче булып эшләүче 32 яшьлек Анна Шпенева исеме 2015 елда бөтен илгә яңгыраган иде. Ул көчле янгын вакытында ике хатынны коткарды һәм «Янгын вакытындагы батырлыгы өчен» медале белән бүләкләнде. Әмма тугыз ел эшләгәннән соң, узган ел Анна да бу эштән киткән. Үзенең башкалардан ким түгеллеген көн саен исбатлап тору ике бала анасына бик җиңел булмагандыр. Ни генә дисәк тә, янгын сүндерүче ир-ат һөнәре булып санала. Өсләренә кия торган киемнәре генә дә 38 (!) килограмм бит аларның. Әмма чит илләрдә, мәсәлән, Австралиядә, Көнбатыш Европада янгын сүндерү командасында хатын-кызлар да булуы гайре табигый күренеш түгел икән. Бездә исә хатын-кызлар янгын сүндерү частьларында күбрәк диспетчер, инженер вазыйфаларын башкара.

Янгын сүндерүчеләр сафында булырга беркайчан хыялланмадым. Очраклы рәвештә килеп урнаштым дисәм дә ярый. Аннан ошап китте! Бер ел сәркатип булып эшләгәч, диспетчер итеп күчерүләрен сорадым.

Читтән караганда телефон шалтыратуына гына җавап биреп утыручы диспетчер эше җиңел тоелырга мөмкин. Әмма тәүлек буе бүлмәдән чыкмыйча ут өстендә утырып кара әле син! Тоташ егерме дүрт сәгать дәвамында киеренкелектә торып кара! Игътибарың бер мизгелгә дә читкә китәргә тиеш түгел. Телефон һәр минутта шалтырарга мөмкин. Син гел шуны көтәсең, һәм бу көтүдән колаклар чыңлый башлый... Мин ул елларда өйдә телефон шалтыраса да, трубканы: «Янгын сүндерү часте!» – дип ала идем... Янгынны тизрәк сүндерү-сүндермәү диспетчерга да бик нык бәйле: «тревога» сигналына басуга, куркынычның ни дәрәҗәдә зурлыгын иң элек ул бәяли һәм күпме техника, никадәр кеше чыгарып җибәрергә икәнен хәл итә. Иң беренче сменамны хәтерлим... Объекттан ерак түгел газ җиһазлары төялгән УАЗ машинасына ут кабуын хәбәр иттеләр. Янгын булган урынга машина чыгарып җибәрүгә, без Әлмәттәге отряд белән элемтәгә керергә тиеш. Бу очракта син дөрес карар кабул иткәнме-юкмы – моны андагы диспетчер әйтә. Ул чакта яна торган машинаны бик тиз читкә алып киттеләр – зур янгын булмады.

Диспетчер итеп ир-егетләрне бик утыртмыйлар. Монда, әйткәнемчә, басылып утыру, түземлек кирәк, ә бу күбрәк хатын-кызларга гына хас сыйфат.

Өч елдан соң инде менә шушы бүлеккә күчтем. Без күбрәк «Азнакайнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе объектлары өчен җавап бирәбез, аларда эшләүчеләр белән янгынга каршы профилактика чараларын үткәрәбез. Нефть табу һәм эшкәртү цехы урнашкан Азнакай товар паркы, Павловка һәм Бирючевка резервуар парклары, Яшләү алдан су агызу җайланмасы... Иң зур һәм иң хәтәр объектлар шушы. Зур янгынга бер очкын да җитә...

Янгын сүндерү – ир-ат эше, ә без – хатын-кызлар янгынны булдырмас өчен тырышабыз.

Һәрбер участокка инженер яки инспектор беркетелгән: без кызлар белән шул объектларга йөрибез һәм аларның янгынга каршы торышларын тикшерәбез. Көн саен! Эшебез басуда инде безнең... Эш исә җитәрлек: бер промыселда гына 500–600 скважина! Минем карамакта – өченче участок. Скважиналар, нефть саклау резервуарлары һәм «Азнакайнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең өчәр катлы өч административ бинасы да (безнең телдә ул «халык күп була торган урын» дип атала) керә аңа. Башкалар кебек үк мин дә һәр көнне юлда. Бер көнне Бөгелмә ягына чыгып китәм – егермеләп скважинаны тикшереп кайтам, икенче көнне – районның икенче ягына барам. Бер айда үзем тикшерергә тиеш объектларның 70–80 процентын йөреп чыгам. Ел дәвамында һәр объектта, ким дигәндә, өч-дүрт тапкыр буласың.

Элек безнең бүлектә күбрәк ир-атлар эшли иде, ә хәзер башлыча хатын-кызлар гына. Моның сәбәбе бик гади: 2012 елда, федераль закон нигезендә, погоннарны салдырдылар. Хәрби булып саналудан туктагач, ташламалар бетте, хезмәт хакы да кимеде – ир-атлар башка өлкәләргә күчте. Мин үзем дә кайчандыр өлкән лейтенант идем... Без күзәтә торган объектлардагы эшләр катлаулы технология белән бәйле: югары техник белемең булмаса, аларга якын да килә алмыйсың. Безгә бик күп белергә кирәк! Нефть табу технологиясен дә, аны ничек эшкәрткәннәрен дә, электр энергиясе белән бәйле бар нәрсәне дә. Янгын сигнализациясе ничек эшләгәнен яки аның ни өчен эшләмәгәнен... Үзебез уенын-чынын кушып: «Һәрнәрсә турында бөтен нәрсәне дә», – дибез. Химик та булырга кирәк, физик та. Тырышабыз! Белемнәребезне арттырып, квалификацияне һаман күтәреп торабыз. Кагыйдәләр туктаусыз үзгәрә, таләпләр алышына – син боларның һәрберсеннән хәбәрдар булырга тиеш.

Инженер итеп күчерүгә, мине дә иң беренче көнне үк укырга җибәрделәр. Казанда өч ай белемемне арттырып кайттым. 900 ир-ат арасында берүзем идем! Кайтуга начальнигыбыз Александр Викторович Никулин миңа: «Зөһрә, син хәзер бөтен нәрсәне дә беләсең. Иртәгә идарә җитәкчеләре белән бергә объектка комиссия белән чыгасың», – диде. «Ничек чыгам, мин бит бернәрсә дә белмим?!» – дип уйлыйм. Урынга баргач, имтихандагы кебек барысы да искә төшә башлады: моны укыган идем, моны күптән беләм, бу шулай булырга тиеш...

Объектларда нефтьчеләр ут белән бәйле эшләрне һәрдаим башкара: скважиналар ремонтлана, электр-газ эретеп ябыштыру эшләре адым саен чыгып тора... Барлык саклык чаралары күрелгәнме-юкмы икәнен тикшергәч кенә, без аларга бу эшләрне башкарырга рөхсәт бирәбез. Төрле очраклар була: кемдер нәрсәнедер карап бетерми, көтелмәгән берәр хәл килеп чыга һәм ут каба...

Фото: Анна Арахамия

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

Без һәр иртәне: «Бүген нәрсә кияргә?» – дип баш ватмыйбыз.



Соңгы вакытта, шөкер, зур янгыннар булганы юк. Мин эшкә урнашканчы, әле сиксәненче елларда ук Яшләүдә резервуар янганны менә хәзергә кадәр сөйлиләр. Биш мең кубометр нефть саклана торган зур резервуар була ул. Күз алдына китерү дә куркыныч... Ә хәзер андый янгыннарны ел саен үткәрелә торган өйрәнүләр вакытында гына күрәбез.

«Янабыз!» – дигән хәбәр алсак, безнең егетләр объектка өч минут эчендә барып җитәргә тиеш. Бу – якында урнашканнарына. Ә ерактагыларга – ярты сәгать эчендә. Янгын деполарын төзегәндә барысын да исәпкә алалар. Беренчедән, кайда куркыныч объект күбрәк, алар шунда ачыла. Икенчедән, ерак дип саналган ноктага да янгын сүндерүчеләр ярты сәгать эчендә барып җитәргә тиеш.

Без рөхсәт итмәсәк, объектлар ниләр эшли алмыйммы? Гомумән, ут белән бәйле барлык эшләрне туктата алабыз. Җитди сәбәп табылганда хәтта объектны тулысынча туктатырга да хокукыбыз бар. Дөрес, андый хәлләр булганы юк анысы. Безнең янгын сүндерү частена быел инде 60 ел була: таләпләребезгә күптән күнделәр.

Теләсә кайсы эш кешенең холкына тәэсир итми калмыйдыр инде ул. Безнеке менә гүзәл затлар дип аяп тормый – кырыслык өсти. Моны үзебез дә сизәбез. Хатын-кыз булсаң да, шактый каты гына әйтергә туры килгән чаклар бар. Бигрәк тә хәзер – иңнәрдән погоннарны салгач. (Аерманы сизәм – мин бит погон белән дә эшләдем, погонсыз да инде шактый эшлим.) Ир-ат дип тә тормыйсың, начальник дип тә. «Сездән янгын куркынычсызлыгын таләп итү – минем эшем», – дип, кайчак цех җитәкчеләренә дә әйтәсең. Кирәк икән, «Азнакайнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе начальнигына да хат юллыйсың: «Янгын куркынычсызлыгын бозуның шундый-шундый очраклары бар, шушы вакыт арасында аларны төзәтүне сорыйбыз», – дисең. Бер сүз дә юктан гына язылмый: махсус кагыйдәләргә таяныла. Әйтик, нефть түгелгән икән, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәсен саклауның кайсы пункты бозылганы төгәл күрсәтелә. Алар безнең таләпләрне үтәргә тиеш. Үтәмәгән очракта штраф санкцияләре кулланыла. Әйе, безнең кызлар җитәкчеләр өчен янгынның үзе кебек үк куркыныч.

Кырыс булмый ярамый: ялгышырга хакыбыз юк. Матди байлыклар турында гына түгел, кеше гомерләре турында да сүз бара бит. Мин үзем нефть табу һәм эшкәртү объектларына караганда, җәен пионер лагерьларе өчен күбрәк борчылам. Смена саен ике-өч тапкыр барып, тикшереп торабыз. Махсус журнал бар: һәр көнне кич шалтыратып, бүген төнлә лагерьда ничә кеше йоклаячагын безгә хәбәр итәләр. Ут-күз чыкса, күпме баланы коткарырга кирәген белергә тиешбез. Лагерьлар ябылгач кына тыныч йоклый башлыйм...

Уттан бөтен кеше куркадыр. Мин дә куркам! Күзгә-күз диярлек очрашканым булды. Яшүсмер чагым иде әле. Кыш иде, кичке як. Урамда 30 градус салкын. Әни төнге сменада эштә. Өйдә без – абый, аның хатыны һәм яңа туган балалары. Кинәт каяндыр төтен исе керә башлады. Үзебездә телефон юк иде – күршеләргә йөгердек. Янгын сүндерүчеләргә хәбәр итеп өлгергәннәр – подвал яна икән. Абыйлар: «Ваннага су тутыр, идән яна башласа, сибәрсең, без туганнарга барабыз», – дип чыгып киттеләр. Ваннага су тутырдым, идәндәге паласларны җыйдым. Ул арада ут сүнде. Суларга авыр була башлагач, башымны форточкадан тыгып сулап киләм... Сөйләгәндә генә озак, болар чынлыкта бик тиз булды. «Өйдә нишләп утырасың, төтенгә тончыгасың бит, урамга чык тизрәк», – дип янгын сүндерүчеләр кермәсә, ахыры ни белән беткән булыр иде, белмим. Янгынның утыннан бигрәк төтене куркыныч бит – халык шуны аңламый...

Эшкә урнашканда комиссия узганым истә. Табиб миңа: «Әхмәтҗанова, бездә бит мондый кыска буйлы кешеләр эшләми», – дигән иде. «Үсәм әле мин, үсәм!» – дип җавап биргән идем. Әллә ни үсеп булмады... «Сезнең кебек кыска буйлыларга кием текмиләр бездә», – дип әйтергә теләдеме икән ул? Унбиш ел эшлим һәм һаман кием мәсьәләсе миндә: яңасын алган саен кыскартырга, тарайтырга, кечерәйтергә туры килә. Кышка керсәк, өстебездә сырган чалбар, бушлат, бүрек, итекләр менә. (Куркынычсызлык саклау кагыйдәләре буенча объектларда җәй көне дә үкчәле туфлиләрдән йөрергә ярамый безгә. Резервуарга биек үкчә белән ничек менеп булсын инде?!) Хатын-кыз матурлыгын яшерсә дә, эштә болардан да җайлы кием юк: кышкы суыкларга тимер салкынлыгы да өстәлә бит...

...Нефтьне комплекслы әзерләү цехына ут капкан. Иң куркыныч объект – нефть иң күп тупланган урын бу... «Хәзер нәрсә була инде?» – дип өзгәләнеп уйлыйсың. Һәм... чәчрәп уянып китәсең. Без кызлар белән мондый төшләрне еш күрәбез. «Төштә янгын күрү нәрсәгә икән?» – дип юраган юк. Эшеңне яратканга, әлбәттә!

«ТАТАР РАДИОСЫ»НА – 18! КОТЛЫЙБЫЗ!



«Татар радиосы» оешуының 18 еллыгын Пирамидада бәйрәм итте. Бу вакыт эчендә никадәр уңышлар яуланды! Татарстан Республикасында һәм Россиянең төрле төбәкләрендә радиостанцияләр ачылды, күпме тамашалар уздырылды!









18 еллык тарихны биредә язып бетереп булмаса да, шуны истә тотарга кирәк – «Татар радиосы» эфирга беренче тапкыр 2001 елның 24 августында чыкты. Радионы булдыру идеясен «Барс-Медиа» компанияләр төркеме уйлап таба. Хыялны чынга ашыру өчен күп кенә еллар үз «курсын» табарга һәм көч куярга туры килә. Бүгенге көндә радио ешлыкларында заманча татар эстрада җырлары һәм күптән таныш алтын хитлар яңгырый, күп кенә кызыклы тапшырулар чыга башлады. «Уян, Татар!», «Менә мондый кич», «Хәерле иртә, Австралия!»... Болар барысы бергә радиостанцияне тамашачыларыбыз өчен тагын да кызыклы яктан ача.

18 ел дәвамында «Татар радиосы» студиясендә бик күп абруйлы кунаклар чыгыш ясады. Алар арасында җырчылар, актерлар, иҗат төркемнәре, сәясәтчеләр, бизнесменнар, төрле өлкәләрдәге экспертлар бар иде. Һәрберсе радио тарихына үз өлешен кертте. 2017 ел радио өчен аеруча истәлекле. Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов студиягә килде, эфирга чыгып, радиотыңлаучыларга хәерле көннәр теләде.

Җитәкчеләр, диджейлар, төрле белгечләр алмаша барды, һәм аларның һәрберсе радио тормышына, аның динамикасына үз өлешен кертте. Алардан башка «Татар радиосы» бүгенге югарылыгында була алмас иде.

«Җәйге ачык студия», 5 көнлек «Автопробег. Казан–Кырым–Казан» кебек бик күп креатив проектлар барлыкка килде. Бу проектлар вакытында туры эфирга чыгуны һәр тыңлаучы күтәреп алды. «ТМА» дискотекасы, «Шәһәр көне» концертлары, «Музыкаль десант», «Музыкаль Каймак», «Изге Вәли», «Татар җыры» – болар барысы да «Татар радиосы» ярдәмендә эшләнә торган проектлар. Беренче татар дискотекалары һәм кичәләре, татарларга гына хас атмосфералы фестивальләр – барысы да «Татар радиосы» белән бәйле.

«Татар радиосы»ның Пирамидада узган концерты – күпьеллык хезмәтнең җимеше. «Татар радиосы» бу кичтә тыңлаучыларга күп сюрпризлар әзерләде: Казанның танылган кавер-группасы «Блэк-джек» башкаруында инструменталь музыка, «on air» радиоэфир атмосферасы, тере тавыш, легендар хитлар һәм алып баручыларның оста импровизациясе. «Татар радиосы» бәйрәм атмосферасын булдырды, тамашачыга позитив якты кичә бүләк итте. Радиостанциягә 18 яшь тулды! Киләсе туган көннәрен тагын да колачлырак бәйрәм итәргә вәгъдә итте «Татар радиосы».

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА



PRESSA

АСЫЛ ИКӘНЕҢНЕ ОНЫТМА!

Гөлнур САФИУЛЛИНА

– Лилия Камилова! Үзбәкстан!
«Татар кызы-2019» исеменә кем лаек икәне, ниһаять, билгеле! Җиңүче таҗы һәм «Лада Гранта» автомобиле ачкычы да аңа! Удмуртиянең П. И. Чайковский исемендәге дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсе чәчәкләргә күмелә... Оештыручылар (Татарстан Республикасы хөкүмәте, Бөтендөнья татар конгрессы): «Татар кызы» – матурлык бәйгесе генә түгел, ул сәләтлелек һәм милли традицияләр бәйрәме дә», – диләр. Әйе, ул башка бәйгеләрдән нык аерыла! Язмадагы менә бу мизгелләр нәкъ шул хакта сөйли дә.











Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте. Әлифба музее. Төрле илләрнең азбука, букварь һәм әлифбаларын туплаган дөньядагы бердәнбер музей! 265 әлифба янына тиздән тагын берсе өстәләчәк: **Александра Соловьева** (Карелия Республикасы) музейга кареллар өчен чыгарылган әлифбаны бүләк итеп җибәрергә вәгъдә итте. Бәйгегә килгән ике кыз гына чәчләренә чулпы таккан иде. Шуларның берсе – Александра. (Кайлардан тапкан ул чулпыны?!) Әтисе карел аның. «Әти туган телендә сөйләшми, ә мин өйрәндем, – ди ул. – Кеше үз нәселе тарихын, әби-бабаларының телен белергә тиеш дип саныйм. Тамырсыз хәтта чүп үләне дә үсми... Телсез халык та була алмый! Ел ярым элек үзебездә, Петрозаводск шәһәрендә репетитор таптым – татар телен өйрәнергә миңа ул булыша...»

***

Болгардагы Ак мәчет каршына «Татар кызы-2019» дип язылган автобус килеп туктады. Мәчет алдындагы мәйдан бер мәлгә тын калды... Кызларга төбәлгән күзләрдә – соклану, гаҗәпләнү, горурлану! Матурлык ул менә нинди була икән! Тыйнаклык, сафлык, миллилек... «Сез кемнәр? Сез кайдан?» – шәһре Болгарда кызларга иң күп бирелгән сорау шушы булды. (Кем нинди телдә дәште – кызлар шул телдә җавап бирде!) Алар белән бергә фотога төштеләр – татар кызларының сөйкемле елмаюы Кореяга, Малайзиягә, Һиндстанга китте.

***

Изге Болгар җирендә озын-озак бер көн уздырып, кайтыр юлга кузгалдык. Янымдагы урындыкта – Милана Сайдаева (Кыргызстан).

– Минем тизрәк өйгә кайтасым, мамага «әни» дип дәшәсем килә! Әби вафат булганнан соң, өйдә күбрәк русча аралаштык шул... Бер нәрсәне аңладым: ата-ана туган телендә сөйләшсә генә балалар аны беләчәк. Минекеләр, һичшиксез, татарча сөйләшәчәк! Кызларым булуын телим: берсе – Фатыйма, икенчесе – Әминә... Матур исемнәр бит, әйеме? Безнең Бишкәк шәһәрендә Каюм Насыйри институты үзәге эшли. Кайтуга шул үзәккә татар теле өйрәнергә барачакмын. Үзем кебек яшьләрне җыячакмын...

***

Илсөяр Гомәрова – Оренбург өлкәсенең атаклы Татар Каргалысы авылыннан. Бәйгедә катнашучы кызлар арасыннан аны тануы, табуы бик җиңел иде – иңнәрендә һәрвакыт ап-ак оренбург шәле булды.

– Проектта җырлый башладым! Моңарчы миңа үз-үземә ышаныч җитмәгән, күрәсең... Ә монда укытучылар: "Тавышың матур!» – дибеләр. Үзем өчен дә яңалык булды бу. Тиздән Оренбургта «Татар кызчыклары» дигән бәйге үтәчәк. «Ак калфак» оешмасы үткәрә аны. Оештыручыларның берсе мин булачакмын. Бәйгедә катнашып кайтканнан соң, кызларга тагын да күбрәк өйрәтә алачакмын. Татар милли киеме буенча үз брендымны булдыру, ателье ачу турындагы хыялым да бәйге вакытында ныгыды гына.

***

Александра Соловьева сөйли:

– «Татарча инде әйбәтрәк сөйләшәсең», – диләр кызлар. Үзем дә сизәм... Инсаф абый миңа яңа исем кушты. Сания мин хәзер... Үземә ошый! Халыкара «Татар кызы» бәйгесенең Дирекция җитәкчесе Лена Рәфыйковна: «Беренче татар операсы да «Сания» дип атала», – диде... Карелиядән, «Чулпан» татар иҗтимагый үзәгеннән шалтыраталар. «Киләсе елга бәйгегә кемне җибәрербез икән, ул синең кебек булырга тиеш», – диләр. Бергә эзләрбез инде... Кайткач, Петрозаводскида «Ак калфак» оешмасын төзисем килә.

***

– Сөтле чәй яратам. Группадашларым моны күрүгә: «Син – татар кызыдыр», – диделәр. – **Лилия Куштанова** (Ленинград өлкәсе) рәхәтләнеп көлә. – Чаллыда туып-үстем, Санкт-Петербургта исә инде алты ел яшим. Чит-ят мохиттә туган телеңне саклау җиңел түгел. «Татарча диктант» Халыкара акциясендә катнашырга мөмкин икәнен белдем дә, эзләп киттем. Туган телемне онытмадыммы икән, дип үземне тикшереп карарга теләдем. «Питер буйлары» оешмасы әгъзалары белән шунда таныштым. Бәйгедә катнашуым да үз-үземне сынау.

***

Миләүшә Шәехова – Свердлау өлкәсе Биккинә авылы кызы. Инстаграмын татарча алып бара ул! Нур Баян, Фаил Шәфигуллин шигырьләрен ярата, «Тукайны, Җәлилне ятлап үстем», – ди. Медицина көллиятендә белем ала: булачак шәфкать туташы аның кебек йомшак күңелле булырга тиештер...

– Сәнгатькә мәхәббәтне миндә авылыбыз клубында мөдир булып эшләүче әнием тәрбияләде, – ди ул. – Гаилә ансамблебез бар: кечкенәдән шунда җырлап, биеп үстем. Баянда уйныйм. Сәхнә – минеке! Бәлки шуңадыр, «Татар кызы»нда иң ошаганы репетицияләр булды... Буш вакытны бушка уздырмаска кирәк, дигән яңа кагыйдә алып кайтып китәм үземә.

***

– «Һәрвакыт кеше булып калырга кирәк!» Безне бәйгегә әзерләүчеләр бу хакта еш кабатлады. Финалга узган бер кызыбыз икенче көнне үк аягын авырттырып кайтып китте. Аның өчен борчылып елап беттек...

Динә Афиетулловага (Ульяновск өлкәсе) әбисе гел: «Иң мөһиме – сайлаган кешең татар малае булсын», – дигән. «Ә минем башка төрле уем юк та!» – дип балкып елмая ул.

***

Чит илдә, чит мохиттә үскән кешегә бу бәйгедә катнашу җиңел түгел, әлбәттә. **Юлия Фәтхуллина** (Швеция) моны яшерми.

– Килгәндә туган телемне белү дәрәҗәсен, әйтик, 5 балл белән бәяләсәк, ул хәзер 10–15 кә күтәрелгәндер. Юк, 20 гә! Шомарганымны үзем дә сизәм... Проектта катнашу миңа яңа тәҗрибә, яңа белемнәр бирде. Тамырларым, тарихи Ватаным шу-

шында икәнен аңлатты. Иң зур ачыш: тавышым татар көйләренә ятып тора икән бит! Күптән җырлыйм, әмма тавыш тембрым шведныкына да, башка халыкның җырларына да туры килеп бетми. Хәзер татар көйләрен башкарганда тавышымның үз юлы буйлап йөгерүен сизәм. Рәхәт! Бөтен барлыгым белән татарныкымын – шуны аңлап китәм. Мин, чынлап та – татар кызы! Үз-үземне, күңелемнең нурын ачтым...

Балаларым миңа кем дип дәшәр? Шундый авыр сорау... Барысы да юлымда кемне очратуыма бәйле-дер... Юк, барыбер «әни» дип дәшәрләр! Соңгы көннәрдә әни белән телефоннан сөйләшкәндә аңа үземнең дә күбрәк татарча эндәшәсем килә.

***

Кызлар белән иң беренче танышуда ук **Лилия Камилованың** (Үзбәкстан) татарча иркен сөйләшүенә игътибар иттек (татар баласының туган телен белүе гаҗәп булырга тиеш түгел дә бит, тик...):

– Балалар бакчасына йөрмәдем, мине нәнәй белән бабай тәрбияләде, – диде ул. – Бездә татар мәктәпләре юк, татарча укымадым. Бабай бу мәсьәләдә бик кырыс иде: «Мәктәптә рус телен өйрәнегез, урамда үзбәкчә аралашыгыз, ә өйдә татарча гына сөйләшегез!» – дия иде. Ул гаиләбездә иң баш кеше, без аның сүзен тыңладык...

***

– Проект мине нык үзгәртте, – ди **Айсылу Мирхафизхан** (Мәскәү өлкәсе). – Эчке дөньям турында әйтәм әле. Ул мине үз-үземә кайтарды, тамырларымны кабат искә төшерде. Мәскәүдә глобализация көчле, анда тел дә, максатлар да башка. Югала язган булганмын...

«Татар кызы» бәйгесенең нигезендә дуслык ята, дип безгә гел әйтеп тордылар. Чыннан да шулай ул! Бәйгенең иң беренче көне. «Иртәгә милли костюмнарыгызны киегез», – диделәр. Төнге сәгать унике иде инде, ә безгә иртән җидедә юлга кузгалырга – Арчага, Тукай туган төбәккә барырга тиешбез. Үзем белән милли костюмым юк иде, дөресрәге, аны алырга өлгермәдем. Нишләргә? Кызлардан да сорарга уңайсызланам: әле яңа таныштык кына. Әмма бүлмәләр буенча китми чарам юк иде. Әле кемнең кайда торганын да ныклап белмим – иң беренче бүлмәгә шакыдым. Оренбургтан Илсөяр ишек ачты. Үтенечемне әйттем... Илсөяр үзе тегә икән – аның күлмәге берничә булып чыкты. Сөенеп бирде ул аны миңа! Илсөяр башлаган шушы киң күңеллелек дулкыны барыбызга таралды... Юк, матурлык бәйгесе генә түгел бу! Аның максатлары башка. Иң беренче чиратта – милли аңны үстерү. Татарлыкны саклау буенча бүген яңгырый торган сүзләрне «Татар кызы» кызларча, матур итеп кенә эшләп куя. Мин генә түгел, моннан бөтен кызлар да үзгәреп кайтып китә.

***

– Башымда әллә никадәр яңа идея, проектлар! Әстерханга кайткач, җиң сызганып эшкә тотыначакмын... Кечкенәдән татар дөньясында кайнап үстем. «Дуслык» татар җәмгыятенең активисты саналам. Быел Сабантуйны алып бардым. Бабама рәхмәт – татарча сөйләшергә ул өйрәтте. Әмма туган телемне тагын да камилрәк беләсем килә. «Ана теле» онлайн-мәктәбенә дә шуңа язылдым.

«Татар кызы-2019» бәйгесенең җырчы сандугачы – **Камилә Калиева** (Әстерхан) сөйли боларны. Сез аның татар халык көе «Илкәем»не ничек башкарганын ишетсәгез иде?!

***

– Мин – татар кызы! Бәйгегә әзерләнгән көннәрдә безнең барыбызның да күңелендә шундый горурлык туды, – ди **Дилия Харисова** (Ижевск). – Кая гына барсак та игътибар үзәгендә булдык. Шушы хисне югалтмыйча саклыйсы иде... Гомергә истә калырлык вакыйга булды бу безнең тормышта. Балаларыбызга, оныкларга сөйләрлек...

...Бәйге тәмам. Хәер, юк, ул дәвам итә. Айсылу Мирхафизхан дөрес әйтә, «Татар кызы» – бәйге генә түгел, ул – яшәү рәвеше.



«СИН БИТ ТАТАР КЫЗЫ!»

– Татар кызы булу зур җаваплылык, минемчә, – ди **Алия ӘХМӘТОВА** (Казан). – Татарча сөйләшү генә түгел әле бу. Әби-бабаларың, әти-әниең салган тәрбияне, гореф-гадәтләрне, милли моңнарны киләчәккә тапшыру бурычы да йөкләнгән сиңа. Боларның барысын сакламыйсың икән – чылбыр өзеләчәк... Мин үзем Яшел Үзән шәһәрендә туып-үстем, рус мәктәбендә белем алдым. Әмма мәхәббәтемнең берсе математика булса, икенчесе татар



Тулысынча сайтыбызда укыгыз.

теле һәм әдәбияты иде. Җаныма татар рухы сеңдергән өчен иң беренче чиратта дәү әти-дәү әниләремә рәхмәтлемен. «Син бит татар кызы!» – дигән сүзне дәү әни миңа адым саен кабатлады: «Ипи кискәч, өстәлдә валчыгын калдырма, син бит татар кызы», «Өлкәннәр белән исәнләш, син бит татар кызы...»... Гел шулай булды! Әнием үскән төп йорт күршесендә – татар халкының олы мәгърифәтчесе, галим Каюм Насыйриның әбисе нигезе. Минем кебек ул да Бакырчыга кунакка килеп йөргәндер... Маһруй әбием – мулла кызы. Ул дүрт телдә сөйләшкән, Коръәнне яттан белгән. Бабай имән кебек нык, көчле кеше булган, тик аны сугыш аямаган... Әбием биш баласын үзе генә аякка бастырган. Тәрбиялелеге, уңганлыгы, укымышлылыгы, зыялы булуы ярдәм иткән аңа. Телләргә мәхәббәтем, белемгә омтылуым, бәлки, Маһруй әбиемнәндер дә?! Казан дәүләт икътисад университетын тәмамладым: берьюлы ике һөнәр алдым – мин икътисадчы да, тәрҗемәче дә.

Теләк булса, барысына да вакыт җиткерәсең! Студент чагымда «Сәләт»нең бик күп проектларында катнаштым. «Сәләт» белән «Татар кызы» бәйгесе арасында турыдантуры бәйләнеш бар кебек тоям... Безнең җәйләр гел авылда узды, шуңа күрә сәлкеш булырга бер тапкыр гына өлгердем. Аның каравы, университетка укырга кергәч иң беренче эш итеп «Сәләт»не эзләп киттем. Бу агымга мин бик теләп кушылдым! Татар теленең ни дәрәҗәдә популяр булу-булмавы бездән торуын шул вакытта ук аңладым. «Сәләт»тәге дуслар белән һәркайда – аланнарда, кафе, киноларда очрашканда үзара гел татарча аралашабыз. «Сәләт»нең максаты да – балаларда туган телдә сөйләшергә омтылыш уяту. Мин үзем шуны күз алдында тотып эшләдем. Ә «Сәләт-Монреаль» аланына әйдаман булып баргач (мин аңа зур конкурс узып эләктем!), тагын бер нәрсәне аңлап кайттым: читтә яшәгән милләттәшләр татар теленең кадерен күбрәк белә. Хәтта балаларына да шуны сеңдерергә өлгергәннәр. Мин моны «Татар кызы» бәйгесе вакытында да тойдым. Швециядә үскән Юлия: «Казанга килү минем өчен үзе бәхет!» – диде. Ә Саша гел: «Карелиядә татар мохите юк шул, миңа сезнең янда шундый рәхәт», – дип кабатлады.

Ә бәйге... Бәйге барыбыз өчен дә тормыш мәктәбе булды. Килүгә оештыручылар: «Татар кызы» – матурлык бәйгесе генә түгел, аның рухы башка», – диделәр. Безнең арада көндәшлек булмады! Иң зур җиңү – үз-үзеңне җиңү, бу – шушы иде. Дуслаштык, бер гаиләгә әйләндек! Бергә яшәдек, репетицияләргә, очрашуларга йөрдек. Сөйләшеп сүзләр бетмәде: йокламадык та бугай. Җир шарының төрле почмакларыннан җыелып тагын кайчан шулай аралаша алырбыз? Мондый мөмкинлекнең бары бер генә тапкыр бирелүен барыбыз да аңладык һәм бергә чакның кадерен белергә тырыштык. Җиңүче таҗын кигән Лилия өчен сөенгәндә без барыбыз да ихлас идек!

Бәйгегә әзерлек көннәрендә гел милли костюмнардан йөрдек. Кая гына барсак та халыкның күзе бездә иде. Килеп дәшүчеләр булды. Шундый зур хөрмәт белән! Кешенең игътибарын ябык киемнәр белән күбрәк тә җәлеп итеп була икән. Гомумән, киемдәге берәр милли бизәк тә татарлыкны сакларга булыша дип саныйм. Әйтик, кулымдагы милли орнаментлар чигелгән сумка. Аның белән урамга чыгуга мин игътибар үзәгендә калам. Тирә-юньдәгеләр өчен татар кызына әйләнәм!

«Татар кызы» бәйгесе тәмамланганнан бирле гел бер нәрсә турында хыялланам. Чын татар кызы булыр өчен ниләр эшләргә, нәрсәләр белергә кирәген өйрәтә торган бер мәктәп ачасы иде. (Австриянең «Школа леди» кебек мәктәбе нигә татарларда да булмаска тиеш әле?!) Ә чын татар егете булыр өчен нишләргә кирәк? Ир-егетләр тәрбияләү тагын да кыенрак бугай. («Татар кызы» бәйгесе тәмамлангач, энем Азат миннән: «Ә ни өчен егетләр өчен дә андый бәйге юк? Мин катнашып карар идем», – диде. Күбрәк русча сүзләр кушып сөйләшергә яраткан энемне алыштырдылар да куйдылар. Ә аңарга бәйгенең этапларын да үтәргә туры килсә?!) Юк, алай гына да түгел, гаилә мәктәбе булсын иде ул. Яшь әти-әниләр дә курслар узсын иде анда. Бездә үзен татар дип санаучылар бик күп, әмма, кызганыч, балалары аларга «мама» дип дәшә. Татар мохитенә эләксәләр, «әни» дип әйткәннәрен сизми дә калырлар иде... Бу хыялым чынга ашачагына, мондый мохитне тудыра алачагыма бик өметләнәм.

Мөстәкыйльлеккә, тормышта максатлар куеп яшәргә мине әни өйрәтә. Иң якын кешем, дустым – ул! «Мин сине аңламыйм», дигән чагы юк аның. Инглиз теле өйрәнергә теләвемне иң элек әни хуплады. Төрле проектларда катнашырга гел ул өндәп тора. Магистратураны чит илдә үтәргә теләвемне белә: әти: «Ерак», – дип икеләнә, ә әни: «Бар!» – ди. Ул миңа бөтен яктан үрнәк! 45 яшендә икенче югары белем алды. Энем Азатны хоккейга йөртергә кирәк булгач, рульгә утырды. Әле курсларга язылды – инглиз теле өйрәнә.

Икътисадчы һәм тәрҗемәче белгечләренең икесен берьюлы кайда кулланырмын икән дип уйлаган идем, таптым андый урынны: «Бала-Сити» халыкара кембридж мәктәбендә эшлим. Мин аны «эш түгел – хыял» дип атыйм... Анда әле күптән түгелмен, әмма инде тәҗрибәм артуын, җаваплылык үсүен, дөньяга карашым үзгәрүен сизәм. Бездә чаралар инглиз телендә уза. Чит илдән килгән укытучылар, балалар белән дә бары тик инглиз телендә сөйләшәбез. Чит илдән килгән хезмәттәшләрем өчен «Татар кызы» бәйгесендә катнашуым бер вакыйгага әйләнде. Иң күп сорауны алар яудырды. Матурлык бәйгесендә су коену костюмыннан дефиле булырга тиеш дип беләләр бит. Юк икәнен ишеткәч, башта гаҗәпләнделәр, аннан сокландылар. «Менә нинди халык икән сез!» – диделәр. Бу сүзләрне ишеткәндә, мин дә горурландым: «Татар кызы» татарны дөньяга таныта!

Тышлыкта Алия Әхмәтова «Александр Богданов» бренды киемнәреннән.

PRESSA



Роза КАМАЛЕТДИНОВА

МӘСРУРӘ КЫЗЫ ӘНИСӘ

Бер бүлмәле җыйнак, курчак өе кебек ямьле, пөхтә фатирда көләч йөз белән каршылаган Әнисә апаны кочаклап аласы килә. Ягымлы да, әллә кайчангы таныш, үз кеше сыман ачык та. Сүзгә кесәгә керүне белми торган үткен-җор телле, якты чырайлы ханым белән сөйләшеп, әңгәмә корып утыру исә җан рәхәте.

– Заман – кәнди, вакыт – хәтти, дия иде әни. Хәттин ашкан вакыт диюе булгандырмы... Дәүләтле дә булдык, юклык, кайгы-хәсрәтне дә күп күрдек. Әниебез Саҗидә кызы Мәсрурә – иң изге күңелле ана: безгә дә, үз әниләре яшьләй үлгән Өммегөлсем ападан калган ул-кызларына да мәрхәмәтле, кайгыртучан әни булды, беркемне дә үги итмәде, – дип сөйли Әнисә апа. – Яшьтән үк авыр эшләргә җигелә авыл кызы. Бала-чага ишле булгач, әти дә үлгәч, бигрәк ачы шул язмыш. Мин 1934 елда туганмын. «Безгә дигән кияүләр мич алдында күмер ашый», – дип көлә идек. Сугыш йоткан шул безгә дигән асыл ярларны. Күрше әби димләп, Пошалым авылына кияүгә бирделәр. Кайнана-кайната: «Әллә кайчан өйләндерәсе булган, өч атна инде, авызына да капканы юк», – дип бик куанганнар иде дә... Шуннан артыкка җитмәде түземлеге. Җитмәсә, авырым төште. Китәргә кирәк, дигән уй керде башка. Мәктәп директоры гаиләсендә бала караучы булып бераз яшәдем. Алар ярдәм итте, Казанга килдем. Кем көтеп тора монда авыл баласын? Стройка – төзелеш инде безгә язганы. Җир казучы – землекоп та, ташчы, түбә ябучы да булдым, аннан штукатур-маляр һөнәрен үзләштердем. Эшкә нык бит безнең халык. Рәхмәтләр дә күп ишеттем, шөкер, Мактау кәгазьләре дә бирделәр. «Бик тырыш син, газетага мактап языйк әле», – диләр бервакыт. «Юк, юк, энә, яшьрәкләр бар ич, аларны мактагыз», – дим. Рәсемгә төшәсем дә килмәгән иде, бригада белән, барыгызны бергә төшерәбез, дигәч, ризалаштым. Шуннан аерып алып Мактау тактасына элгәннәр сурәтемне. Шул рәсем «Төзелештә» газетасында да чыкты. 50 яшькә җиткәч, зур түрәбез чакырып алды да: «Бер бүлмәле фатир бар, бик өстә – тугызынчы катта. Барасыңмы?» – дип сорый. «Күкнең җиденче катында булса да барам. Кояшка, айга якынрак булыр», – дим. И шул чакта шатлануларым! Юыну бүлмәсенә кафель ябыштырам, үзем елыйм, кемгә кала бу дөнья җәннәте, дим. Ходай гомер насыйп иткәч, 85 яшьне тутырып киләм менә.

Мәсрурә исемле иде безнең әни. Үсеп буйга җитүгә яшь туташны, димләп, йоласына туры китереп кияүгә бирү гадәте бар бит инде. Авылда укытучы булып эшли башлаган яшь-яшь кызны, ни хикмәттер, хатыны үлеп тол калган Габдулла Зәбировка – Орнашбашы авылы имамына димлиләр. Борынгыдан килгән йола – мулла-мунтагайга кәләшне үз даирәсеннән – динле гаиләдән эзлиләр. Безнекеләрнең ата-бабалары әллә ничә буын дин әһелләре булганга, ә бәлки, иманлы, итагатьле бала икәнлеге йөзенә язылгандыр, безгә әти, аңа ир буласы насыйбыннан моңа яучылар килә. Хәлле, заманасы өчен тормышы җитеш дип кызыктырулары хак булганмы, әлеге дә баягы гореф-гадәтне санга сукмау хәрам дип уйлаганмы, белгән юк. Үзеннән күпкә олы ирнең биш бала атасы икәнен белгертмиләр. Кыз өчен сер була бу. Башта ятим нарасыйларның тик икесен генә – иң кечкенәләрен күрсәтәләр аңа. Күзләре яшьле сабыйларны кызгангандыр да. Ә бәлки, әнисенең: «Уйла, балам, ятимлекне берәү дә

теләп алмый. Әгәр үги ана йөген өстеңә алсаң, олы йөрәкле икәнеңне расларга туры киләчәк. Сынауларны уза алсаң, савабы үзеңә булыр», – дигәне күңеленә кергәнме, тол иргә кияүгә чыгарга ризалык бирә ул. Еллар үткәч тә: «Тәвәккәл икәнсең, биш бала өстенә килергә... ничекләр җөрьәт иттең?» – дип кызыксынучылар булгалады. «Әни сүзенә каршы төшәргә базмаганмындыр», – дигәне хәтергә уелган. Ипле, миһербанлы, йомшак күңелле иде ул. Бу адымы өчен үкенүен сиздермәде, ни генә күрсә дә, зарланмады язмышыннан. Әтиебез дә начар холыклы яки эшлексез кеше түгел иде, – дип көрсенеп куя Әнисә апа. – Ихтимал, димчеләргә ризалык биргәндә дәү әни, абруйлы хәзрәт хозурында тамаклары тук булыр, дип тә фикер йөрткәндер. Ачлык заманы бит. Ә әти тырыш, булдыклы: йортҗирләре таза-төзек, зур гына алма бакчабыз да бар иде.

Гаилә ишәя, Мәсрурә апаның бер-бер артлы дүрт баласы дөнья күрә. Әмма иң беренче көннән үзенекеләр итеп кабул иткән, кочагына сыендырган үгиләрен – Кәшфруй, Кәримә, Зәйнәп, Әхәт, Самат атлы балаларны, үзе тапкан Суфиясы, Мәсгут, Фоат, Әнисәсе белән бертигез күреп тәрбия итә ул. Яшьтән үк күңел салган мөгаллимлеге дә эзсез узмагандыр, аннан да бигрәк олы җанлы, киң күңелле булуы ярдәм иткәндер, һәркайсын үз күреп, аң-белем, тәрбия бирергә, эшкә өйрәтергә тырыша. Еллар узгач, инде олыгайгач, үги кызларын, улларын барлап: «Яшьлегем, тәҗрибәсезлегем белән ялгыш үпкәләткән, рәнҗеткән чакларым булмадымы? Хаталарым булса, кичерә күрегез, зинһар», – дип, хәл белешеп, һәркайсына бүләк, күчтәнәчләр өләшеп, килеп йөргәнен үгие Зәйнәп ханым кызы Нәзиһә дә хәтерли. Әйе, олы җанлы аналар җилкәсендә бара тормыш. Игелеклелек анадан балаларга күчә. Ә әтиләр дөнья тоткасы булса, бу бәхетле гаилә инде. Матур яши алар.

Тик дөньясы гына кинәт үзгәрә. Инкыйлаб җилләре исеп, яңа тормыш төзибез дип искене вату-җимерү сәясәте башлана. Хәзрәтне авылдан сөрмиләр сөрүен, әмма мал-туарын, зур йортларын тартып алалар, колхоз идарәсе итәләр. Зәбировларның ишле гаиләсе кулак дип Себергә сөрелгән берәүләрнең мал абзарына күченергә мәҗбүр. Хәзрәтне үзе утыртып үстергән алма бакчасына каравылчы итеп куялар. Эчтән сызса, йөрәккәе янса да, кул көчләре кергән, җан җылысы сеңгән агачларны хәсиятләп каравын, тәрбияләвен дәвам итә ул.

Үлеме дә шунда, алмагач күләгәсендә була.

– Картлыктан, дип язганнар дөнья белән хушлашу сәбәбен, – ди Әнисә апа. – Аңа ул чакта 63 яшь тә тулмаган бит әле. Пенсия яшен дә хәзер күбрәккә озайттылар, пенсиягә чыгарга да өлгермәгән, дип фаразласак та ярый. Әтидән калгач, тормышыбыз мәхшәргә әйләнде, дисәң дә арттыру булмас. Әле кайчан гына «Хәзрәт, хәзрәт» дип киңәшкә йөргән кайбер адәмнәр «мулла калдыгы» дип кимсетергә, җәберләргә дә тайчынмады. Әле дә ярый, өзелергә җиткән гомерләрне ялгап җибәрергә әнинең бирнәсе – дәү әни биргән тегү машинасы, яшереп асраган бер кәҗә бар иде. «Облава» – тентү гел булып торганга кан калтырап яшәсәк тә, шулар ярады.

Үги сүзе ят бу гаиләгә.
Чөнки ана җылысы, шәфкать, миһербан дигән олы хисләр генә изге санала.

Андый-мондый тикшерү-мазар килүен сизенсәк, тегү машинасын яшерергә, иң кыены: кәҗәне тизрәк качырырга тырыша идек. Үзебез күршеләрнең өйалды астына кереп посабыз. Әни әтинең чалмасын башына урап саклап калган. Чалмадан абыйга күлмәк тегеп кигезгәне истә. Берчак, әле әти исән чагында, мулла гаиләсе бик интегеп яши дипме, дога өмет итепме, берсе акмай китергән. Шул май кисәге «тегеләр» кергәндә өстәлдә тора икән. Балалар авызыннан өзеп, шул майны алып чыгып китүләре тетрәтмиме, йә? Өебездән куып чыгарганда, «Партия, хөкүмәт шулай куша, безгә рәнҗемәгез», – дип акланган сыман кыланулар да онытылмаган. Әти ягы да, әнинең нәсел-нәсәбе дә ничә буын муллалар иде шул.

Дәү әниебез Сәҗидә абыстай ачык йөзле, укымышлы, ярдәмчел булып хәтеремдә саклана, – ди Әнисә апа. – Энесе Габдулла язган хатларны ул иң кадерле истәлек итеп гомер буе саклады. Шагыйрь, яше җитеп, Җаектан туган якка армиягә каралырга кайткач, Сәҗидә апасы янына килә, тормыш-көнкүреше белән таныша. Әнием дә аны күреп-белеп, аралашып калган. Шул еллар истәлеген күп мәртәбә ишеткәнгә, күңелләрдә якты эз калдырган шагыйрьнең минем хәтергә дә мәңгелеккә тере булып, берегеп калуы гаҗәп түгел.

Укучым төшенгәндер, нәни Апуш күңелендә шәфкатьле «Ак фәрештә» булып гомере буе сакланачак Сәҗидә абыстай – Әнисә апаның дәү әнисе бит.

Заманында Каенсар авылы егете, шул карьядә имам булачак Әхмәтсафа Хәбибуллинга ярәшкәндә Зиннәтулла кызы Сәҗидәгә 16 яшь кенә тула. 17 яше тулмаган кызга никах укырга мулла риза түгел. Туй мәшәкатьләрен читкә куеп, никахны бер елга чигерергә туры килә. Мәхәббәтләре сыналып, бер кавышкач, яшәүнең кадерен белә: тату, матур гаилә корып яши яшьләр. Сәҗидә абыстай бер-бер артлы сигез бала таба. Әнисә апаның әнкәсе Мәсрурә ханым – ике ир баладан соң туган өченче сабый, аларның олы кызлары.

«Сәҗидә апайның үги әбидән яшереп кенә мине җуатканын вә сөйгәнен... һаман хәтеремдә саклыйм. Шул вакыттан бирле ул апа минем күңелемә фәрештә булып утырган да калган. Күңелем аны уйлый башлады исә, хәзер күземә ап-ак саф бер фәрештә күренә», – 1909 елның 29 сентябрендә Тукай каләменнән төшкән «Исемдә калганнар» исемле биографик әсәрдән бу өзек.

Үги әбисенең алты күгәрчене арасында бер чәүкә булгандырмы ул, әллә дүрт ай ярым чакта әтисез, дүрт яшь ярымда әнисез дә калган, күзе гел яшьле ятим: «җыласам – юатучы, иркәләним дисәм – сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә кызганучы булмаган, мине эткәннәр дә төрткәннәр», дип әрнүен, язмышның мәрхәмәтсезлеген (бәлки, үпкәсен!) белдергәндерме, әйтүе кыен.

Нәсел-нәсәбебез руханиларга тоташканга җәбер-золымны күп күрдек, әмма авырлыкларга бирешмәдек.

Чөнки 1890 ел – Идел буенда аяусыз корылык, ә 1891 ел рәхимсез ачлык еллары булып тарихка кергән. Исеменнән күренгәнчә, бәләкәй генә Өчиле авылы имамы Зиннәтулла хәзрәтнең төп шөгыле борынгы сирәк китаплар күчереп язу гына булганга кереме бик аз, намуслы, ярлы имамның ишле гаиләсе фәкыйрьлек һәм авырлык белән көн күрүе сер түгел. Габдуллаҗан йомшак күңелле һәм шәфкатьле Саҗидә апасына 1902 һәм 1903 елларда Җаектан язган хатларында «изгелекле җизнәбезгә, кадерле һәм хөрмәтле сеңлебез Бибимәсрурә белән энебез Габделваһабка, хөрмәтле атабыз урынында булган бабамызга, хөрмәтле гаиләләрен дә кертеп, чиксез күп теләк һәм сәлам» юллый. «Мөшфика апаем! Синең сабый вакытымда һәм хәзер дә иткән изгелекләреңне кабердә ятсам да онытмам... Анам үлгәч, бабайлар өендә миңа мәрхәмәт күзе белән караучы... син бар идең. ...сезнең җибәргән чиккән аяк чолгавыгызны, апай төсе дип, кадерләп кенә тотамын», дип язган хатларын ничә укысам да, еламый түзә алмыйм. Ятимлек... Ни хикмәттер, бала тапканда яисә баладан өзлегеп ананың вафат булуы гадәти саналган заманнар да булган бит. Хатын-кызның иртә үлеп, сабыйлары үксез калуы Тукайлар нәселенә генә хас күренеш түгел, әлбәттә. Әмма уйландыра... Тукайның әнкәсе Мәмдүдәнең анасы Камилә абыстай да, Зиннәтулла хәзрәтнең беренче хатыны – бала тапканда үлә. Ятим үскән Мәмдүдә дә, Габдуллаҗанын калдырып, бик иртә – 25 яшендә гүр иясе була.

– Без – мулла Габдулла балалары, дип әйтергә дә куркып тора идек. Дин дәресләрен мин Нәзә апамнан алдым. «Мулла нәселе белән элемтәдә» дип гаепләүдән куркып, безнекеләрнең хәл-әхвәлен белешергә, күрешергә Зәйнәп апалар ат җигеп төнлә, кеше-кара күрмәгәндә килеп йөриләр, җизни: «Зәйнәбемнең ата-анасын, туганнарын үземнекеләрдән дә ныграк яратам, якын итәм, ахры. Алар – мулла нәселе, гыйлемгә тартылучан, зирәк, акыллы», – дип көндәлегенә дә язып куйган. Бәхеткә, төпчекләре Нәзиһә күрше йортта гына тора. Ярдәмчем дә, киңәшчем, якын сердәшем дә ул минем. Үзләрендә җиде бала булса да, Нәгыйм җизни белән Зәйнәп апа Суфияны да үз балалары янына сыендырган, тәрбияләгән, укыткан бит. Ни үкенеч, бер ата балалары – Мәсрурә кызы Суфияны да, Өммегөлсем улы Әхәтне дә яман чир аямый. Икесе дә бер үк көнне шул зәхмәттән китеп бара.

«Газизләремнең берсен җир куенына салып килдем, икенчесен озатырга соңгарам, ахры, дип ашыккан идем, өлгердем, шөкер», – дип, җеназа мәрәсименә килеп җиткән Мәсрурә ханымның кайгысын нинди үлчәү белән кем үлчәгән? Ә бу нәселгә Ходай насыйп иткән сабырлык, түземлелек үлчәү тәлинкәсенә сыяр микән?

– Саҗидә ханымның кызы Әкълимә апаның торыр җире булмавын Зәкия апа Рәсүлова бик ачынып язган иде, – дим, «Тукай эзләреннән» җыентыгын истә тотып.

– Окоп казырга җибәргәннәр аны, бетләп, чирләп качып кайтырга чыккач, бәкегә төшкән. Шыкырдап каткан бозлы киемнәрен сөйрәп, фатирга кайтып егылган. Эзләп килгәннәр. Качкан өчен хөкем итәрләр дип куркып, фатир хуҗасы ничә килсәләр дә: «Кайтмады. Ул юк», дип җавап биргән. Бәкегә батуын күрүчеләр булган, үлеләр исемлегенә теркәп куйганнар үзен. Бер документсыз, яшәр урының булмаган килеш ничек яшәргә кирәк? Бик авыр тормышка дучар булган Әкълимә апа. Пенсиясе дә юк. Кешедә бала карап көн күргән. Игелекле адәмнәр бар бит ул. Зәкия Рәсүлова артыннан йөреп, Гариф Ахунов ярдәм итеп Нурдидә апа белән икесенә Язучылар берлеге бер бүлмәле фатир алып биргән.

Әнисә апа җәй эссесендә Арчада яши. Беркайчан да ялгызы, үз күңелен күреп, үзе өчен генә яшәмәгән ул. Фоат абыйсының уллары Газинур, Айрат, Азат аның кайгыртуын, ярдәмен тоеп үскән. Хәзер үзе дә алардан игелек күреп яши. Азатның кызы Ильмиралар йортында үзенә аерым бүлмә бар. Гаиләдә кадерле әби ул. Оныклар Раян белән Фидан: «Алмапай, Матур апа», дип өзелеп тора. Яраталар әбиләрен. Ә бу бәхет бит!

Даһиларның гомере еллар исәбе белән түгел, халык хәтере белән исәпләнә. Халкыбызның вөҗдан авазы, намусы, тугры Тукае кара төнне ярып, яшендәй ялтырап, янып, ять-яшь көе сүнсә дә, еллар, чорлар шагыйрьне бездән ераклаштырмый. Иҗаты, рухы, милләт өчен җан атулары якыная гына. Туган телне, татар җанын, милләтне саклыйм дисәң, шагыйрь мирасын, Тукай рухын саклау мөһим. Йокымсырый башлаган күңелләрне уятыр өчен безгә Ул кирәк! Туганы белән очрашу күңел кылларын зыңгылдатып уйландырды.



Саҗидә апа кызлары: Нурдидә, Әкълимә, Мәсрурә *(уртада)*, аның алдында – кызы Әнисә.



Тулысынча сайтыбызда: www.syuyumbike.ru



Гүзәл
ХӨСНЕТДИНОВА.
Мәскәү.

«Бәхетле балачак – тормышның иң авыр вакытларында барып сыеныр бер утрау ул», – дигән кемдер. Һичшиксез, дөрес әйткән...

Әнкәй

Әниемнең әти-әнисенә нигәдер безнен яктагыча «нәнәй» яки «картәтәй» дип түгел, олылар артыннан без, оныклар да, «әткәй», «әнкәй» дип үстек. Хатирәләр, әнкәйнең мин яраткан кып-кызыл төстәге муенсасының төймәләре кебек, бер-берсенә янәшә тезелгән...

...Без, бала-чага, өйгә килеп керү белән, сервантгагы конфет савытын карыйбыз. Анда һәрвакыт безгә дип әзерләнгән берәр тәмле нәрсә була. Бер генә тапкыр кәеф төште: кичә кунаклар килгәч, матур савытка шикәр салганнар да бушатырга онытканнар...

Мин әнкәй белән йоклыйм. Кич саен ул әкият сөйли. Күбесенең эчтәлеге бер: кыю егет каядыр сәяхәткә китеп барганда көтмәгәндә алдына Аждаһа чыга – өч башлы! «Юк, җиде башлы!» – дип төзәтәм әнкәйне. «Әйе, җиде башлы!» – дип дәвам итә ул. Аждаһа куркынычрак булса да ярый: башлары берәм-берәм киселеп, азакта Батырдан барыбер җиңелачәк бит ул. Әкиятнең икенчеләре дә бар: «Борын-борын заманда бер абзый булган. Ял көнне ул Мәкәрҗәгә киткән...» «Әнкәй, Мәкәрҗә нәрсә ул?» Ә-ә, ярминкә икән...

Йокы алдыннан әнкәй догалар укый: «Балам, син дә кабатлап ят: тыныч йокларсың, начар төшләр кермәс». Сервантта торган шәмаилгә күрсәтеп, өйрәтә: «Менә монысы Аятелкөрси – иң бөек, иң файдалы дога». Әнкәйнең Аллаһ турындагы хикәятләре дә әкият кебек кызыклы. Аны күктә утырган ак ыштанлы, яшел халатлы, шәрыктагы кебек очлы борынлы



чүәк киеп, өстән барысын күреп торган бер акыллы абый итеп күз алдыма китерәм. Бер тапкыр уйлап-нитеп тормыйча: «Әнкәй, мәктәптә Аллаһ юк диделәр бит, ә син аңа һаман ышанасыңмы?» – дип көлмәкче иттем. «Балам, син әлегә Аллаһ бар дип тә, юк дип тә әйтмә. Үскәч, үзең карарсың ни диярга икәнен», – дип җаваплады әнкәй. Нинди акыллы сузләр!.. Өйрәтүләре дә юкка булмаган: күп еллар узгач, «Ихлас» догасын ишетеп: «Әнкәй бит моны укый торган иде!» – дип искә төшердем һәм аның истәлеге өчен булсын дип ятладым: хәзер үзенең рухына багышлап укыйм...

...Әткәй бәйләгән каен себеркесе белән мунча керәбез. Мич алдындагы иске чуеннан хуш ис бөркелә: коенганда кушарга дип әнкәй кырдан мөтлек (бөтнекне бездә шулай диләр) җыеп салган... Кичен зур бүлмәдә җыелып, тәмле авыл ашы ашыйбыз: өстәл түрендә аерым савытта ит, бәрәңге, кишер, тәлинкәдәге шулпада әнкәй йә әни кискән куе токмач...

Кайвакыт өйгә керү белән үк эссе бөркелә. Әнкәй ипи пешерә! Мичтә «калган камырдан» ясалган кабартмалар кызара. Яңа пешкән ипигә каймак белән бал ягып, аны урамга алып чыгып ашаулар! Ә иң яратканым – әнкәй коймагы! Түп-түгәрәк булып, бер яктан «челтәрләнеп», тишекләнеп пешә ул. Катыкка сап-сары йомыркалар, он, тагын ниләрдер салып болгаткач, ярты сәгатьләп тотарга куша әнкәй, аннары ике яктан майларга өйрәтә... «Әнкәй, әйдә инде, үзең дә утыр», – дибез. «Сез ашасагыз, мин тук, бәбекәччәем!» Ә юка камыр эченә мул итеп алма туралган гап-гади, әмма искиткеч тәмле бәлешләр! Мин аларны хәзер үзем ясыйм, тик әнкәйнеке барыбер тәмлерәк иде...

Кичләрен, эшләр беткәч, әнкәйгә ул инде күп еллар буе алдырып барган «Азат хатын» журналларын укыйм. Кызыклар булса, әнкәй көлеп кенә туктамый: «И-и, аннан нишләде икән инде, мескен?» – дип, мәзәк хәлгә тарыган кешене кызганып куя.

...Үсмер чакта әнкәйнең теге матур муенсасына сокланганымны күргәч: «Ал, балам», – дип, ул аны миңа бүләк итте. Кызганыч, андый әйберләрнең кадерен белә торган яшьтә булмаганмын. Муенса өзелде, төймәләре таралып югалды. Истәлеккә ник берсе калса соң... Әнкәйнең бу дөньядан киткәненә инде уналты ел. Әмма аның иң кыйммәтле бүләге – күңел җылысы йөрәгемдә мәңге сакланыр...

Рәсемдә: Саира Ямаева.

АП-АК АШЪЯУЛЫК, ТАТАР КӨЕ...



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Лина АРИФУЛЛИНА – Россиядәге концерт-тамашаларны куючы танылган режиссерларның берсе. Эстрада йолдызлары белә: үзгәрергә кирәк икән, Лина ханымга мөрәҗәгать итәргә вакыт. Валерий Леонтьев, Филипп Киркоров, Алла Пугачева кебек популяр йолдызларны яңа иҗади яктан ачкан режиссер ул. Федераль каналларның берсендә эфирга чыккан «Йолдызлар фабрикасы» телевизион проекты исә аңа бөтен ил буенча танылу алып килде. 17 ел элек яңа талантлар ачуны максат итеп куйган әлеге проектта, катнашучылардан бигрәк аның директоры Лина Арифулинага сокланып караганыбызны әле дә булса хәтерлибез. Таланты гына түгел, андагы зәвык, зыялылыкка мөкиббән идек бугай. Татар каны ага бит анда дип горурландык. Проектта катнашкан үсмерләргә сәхнәгә юл ярды ул. Һәм бу эшен әлегә кадәр дәвам итә. Димәк, ул аның җирдәге миссиясе.
Әлеге остаз-режиссер белән эшләү бәхете Татарстан артистлары өлешенә дә тиде. «Барс-Рекордс» компаниясе Лина Арифулинаны XX халыкара «Татар җыры» эстрада фестиваленең режиссеры итеп чакырды. Бу уңайдан без Лина ханым белән әңгәмә кордык.

Лина ханым, ялгышмасам, сезнең тамырларыгыз Нижгарга барып тоташа. Әңгәмәләрегездә җәйге каникулларны әби-бабай янында үткәрүегезне еш искә аласыз. Димәк, татарча өйрәнми калмагансыздыр. Туган телегезне хәтерлисезме?

– Әйе, балачагым авылда узды. Анда татарча сөйләшергә өйрәндем, телемне онытмадым. Хәзер инде кызым Айна белән өйдә татарча сөйләшәбез. Кызым догалар да белә. Безнең бик яхшы апаларыбыз бар. Алар безгә һәрвакыт ярдәм итә. Кызым догаларны алардан өйрәнде.

Татар телен белгәч, сезгә татар моңнары да бик якындыр...

– Татар көе – минем балачагым хатирәләре. Аларны тыңлаганда өебезгә әби-бабайлар җыелуы, ап-ак ашъ-

яулык, балачакның сихри бер мохите күз алдыма килеп баса.

Сез – «йолдызлар» буенча зур белгеч. Федераль каналларның «Йолдызлар фабрикасы», «СТС йолдызлар яндыра» проектларын карамаган, белмәгән кеше юктыр. Сез бик күп җырчыларны үстердегез. Миңа калса, теләсә кемнән «йолдыз» ясый аласыз кебек.

– *(Көлеп.)* Әлбәттә, теләсә кемнән «йолдыз» ясарга мөмкин... *(Җитди тонга күчеп.)* Ә җитдирәк сөйләшсәк, йолдыз сүзенә тирән мәгънә салынган. Ул – күктә, ә артистлар – җирдә. Шуңа да аларны «йолдыз» дип атауны яратып бетермим. Бөтен кеше яраткан һәм тыңлаган артист булу өчен, әлбәттә, талант кирәк. Башкарган эшеңне яратырга да тиешсең, бик зур ихтыяр көче булу да мөһим. Талант ачылмый калырга да мөмкин. Ә менә ихтыяр көче – артистны алга алып баручы, үстерүче мотор ул. Кешелек сыйфатлары булу шарт. Монысы үтә мөһим! Барлык мөнәсәбәтләрдә дә артист саф күңелле булып калырга тиеш.

«Йолдыз чире» тияргә мөмкин дип әйтәсегез киләме?

– Артист янында кем була инде. Әкиятләрдән белгәнегезчә, патшалар янында һәрвакыт шамакайлар йөргән. Алар уен-көлке аша дөреслекне дә, тәнкыйтьне дә әйтә белгән. «Йолдыз чире» әнә шул кешелек сыйфатларының тотрыклы булмавыннан килеп чыга да инде. Әмма, икенче яктан, бу чир белән «чирләргә» кирәк. Бер тапкыр «чирләгәннән» соң, башка вакытта нишләргә кирәген аңлыйсың инде. «Йолдыз авыруы» үз гомереңдә бер тапкыр булса да килми калмый. Аны үтеп, үзеңне тыя белергә өйрәнү мөһим.

Әгәр дә тыелып кала алмыйсың икән, бу бетү дигән сүзме?

– Мин һәрвакыт, димәк, шулай кирәк булган дип әйтәм. Димәк, әлеге артистка шундый юлны узарга язган, ә менә алга таба нишләячәге бары тик үзеннән генә тора. Түбән тәгәрәү тиз ул, ә кабат аякка басып, алга таба атлый белү бик авыр. Эчтән көчле кеше генә авырлыкны җиңеп торып басачак. Беркайчан да соң түгел!

Сезне быел XX халыкара «Татар җыры» фестиваленең режиссеры итеп чакырдылар. Исемегез һәрвакыт инновацион проектлар, уникаль идеяләр белән ассоциацияләнә. Кайсы җырчыга шоу ясасагыз да, аны яңа яктан ачтыгыз. Ә татар җыры фестивалена планнарыгыз нинди?

– «Татар җыры» фестиваленең билгеле бер концепциясе бар инде. Ул бик кызыклы. Кунакка барганда хуҗаларның үзенчәлеген исәпкә алмый калмыйбыз, шулай бит? Монда да татар җыры бәйрәменә киләбез. «Татар җыры» дигән бренд бар, шуңа күрә кардиналь үзгәрешләр ясау урынсыз булачак. Артистларның образын да тамырдан үзгәртергә ярамый. Бу җәһәттән дә революцион адымнар ясарга уйламыйм. Юкса артист өчен дә, тамашачылар өчен дә уңайсызлык кына тудырачак. Чөнки артистның билгеле бер харизмасы бар. Ул тамашачыларга таныш. Алар артистның нәкъ шул образынаияләшкән. Бераз гына экспериментлар ясарга уйлыйбыз. Беләсезме, кайчак бер кечкенә деталь дә бөтенләй яңача үзенчәлекләрне ачып җибәрергә мөмкин. Җырчылар белән очрашып, киңәшләремне бирәчәкмен, әлбәттә. Үзеңне читтән карау бик мөһим бит ул. Ә теләсә кем дөрес һәм кызыклы итеп әйтеп бирә алмый.

Фестиваль серен әз генә булса да беләсе килә бит инде. Шулай да нәрсәгә күбрәк өстенлек бирәчәксез?

– Барысына да! Әкренләп кенә барысын да тәртипкә китереп, кызыклы итеп ясаячакбыз. Тамашачыларның фестиваль атмосферасын тоюларын телим. Концертка килү генә түгел, җыр дөньясына чумып утырып, зур тәэсирләр алып кайтып китсеннәр иде. Һәм ул кичерешләрнең әле бик озакка исләрендә калуын телим.

Сез финал-феерия ясау остасы. «Татар җыры» фестивалендә дә үз фишкагызны кулланачаксызмы?

– Әлбәттә! Барлык серләрне дә ачып бетермим. Финал, һичшиксез, матур булачак...

Хәзерге татар җыры үзгәрешләр кичерә, ул эзләнүдә. Ничек уйлыйсыз, хәзерге татар эстрадасында гармун, халык инструментлары куллану татар җырына үсәргә комачаулыймы, әллә ул аның йөзек кашы булырга тиешме?

– Традицион булган бар нәрсәне: уен коралларын да, татар җырының борылышларын да заманча эстрадада кулланырга мөмкин. Шул ук вакытта дөньяның алга барганын да онытмаска кирәк. Яңалык барлыкка килеп кенә тора. Менә безнең буын бөтенләй башка музыка тыңлый иде, ләкин тора-бара башкасын да кабул иттек. Яшь буынга традицияләрне бозмыйча гына яңа якларны ачу хакында уйланырга кирәк. Алтын урталык бар бит ул. Алар милли мәдәниятне онытмасыннар, шул ук вакытта йөрәкләре кушканча да эшләсеннәр... Миңа калса, яңа технологияләр хакында да, традицияләрне дә онытмаска кирәк. Менә шулар икесе дә кушылса, бик яхшы булачак. Башка мәдәниятләрдә шундый тандем саклана. Милли борылышларда ниндидер бер яңалык бар икән, ул бик яхшы яңгыраш ала.

Хәзерге татар эстрадасына бәя бирсәк...

– Татар эстрадасын күпмедер белсәм дә, әлегә миңа бәя бирергә авыр. Артистлар белән эшли башлагач, билгеле бер күзаллау булыр дип уйлыйм, бу темага шул вакытта сөйләшергә мөмкин булачак.

Тарихи Ватаныгызга еш киләсезме?

– Соңгы тапкыр Казанга 2014 елда Turkvision-2014 II халыкара музыкаль бәйгесенең финал өлешен оештырганда килгән идем. Шушы еллар эчендә генә дә Казан бик үзгәргән. Дөрес, мин рәхәтләнеп җәяүләп йөреп карый алмадым. Бары тик концерт залы тәрәзәсе аша гына бәяләдем. Шәһәрнең үзгәрүе үзе үк кызыклы. Аның кунакчыллыгы, җанлы шәһәр булуы беркайчан да үзгәрмәс.

PRESSA

Әнкәйләргә сәждә кылыгыз!

ЗӨЛФӘТ

Әни

Уң кулында урак сабы эзе,
Сул кулында учма җылысы.
Нечкә иләк була бу кулларда,
Уклау була, җиләк тырысы.
Чигү чигә күлмәк изүенә,
Я кер чайкый буа буенда.
Бохар чикләвеге сала безнең
Кесәләргә сабан туенда.
...Кулларыңны хәтерлим мин, әни.
Мин аларга яшим елышып,
Уң кулында урак сабы эзе,
Сул кулында учма җылысы.
Аналарның уртак дине була,
Уртак кодексы, законы;
Шул законны бары кабул иттең
Син, оялчан татар хатыны.
Бер хикәят минем хәтеремдә
Борынгы моң булып яңара:
Сөйгәненнән фәрман алган егет
Әнисенең башын чабарга:
– Мине сөйсәң, әниеңнең башын
Сараема китер, и егет!
...Килгән чакта сарай баскычында
Егылган, ди, гашыйк, сөрлегеп.

* * *

Баш тәгәрәп киткән таш идәнгә –
Якты мәрмәр сарай идәне! –
Ана телгә килгән шул чагында:
– Саграк, улым, тәнең имгәнер...
...Хәтеремдә минем шул хикәят –
Аналарның уртак законы,
Шушы дингә ничек табындың син,
Оялчан бер татар хатыны!
Кулларыңны хәтерлим мин, әни!
Маңгаемны куеп учыңа,
Мин гыйбадәт бүген кылыр идем
Кешелекне юатучыга!
Яки тынар идем бер мизгелгә
Синең йөрәгеңә елышып...
Уң кулында – урак сабы эзе...
Сул кулында – учма җылысы...

Роберт МИҢНУЛЛИН

Әнкәйләр

Әнкәйләргә Аллаһ ярдәм бирсен!
Аларгадыр бөтен авырлык.
Әнкәйләргә безнең
Йолдызлардан
Я кояштан һәйкәл салырлык...

Давылларга каршы китәбез без,
Утлар-сулар күпме кичелә!
Туган өйгә юлны онытабыз –
Ә әнкәйләр барсын кичерә.

Якын дуслар ташлап китә безне,
Хыялларын күпләр югалта.
Әнкәйләргә кайтып егылабыз –
Ә әнкәйләр безне юата.

Алар гына безне онытмыйлар,
Алар гына чынлап ярата.
Синең белән бергә сөенә дә,
Кайгыларың булса – тарата.

Җан җылысын тоя күңелебез,
Әнкәй көчен тоя кулыбыз...
Безгә бер дә үпкәләмәсеннәр,
Әнкәйләргә сәҗдә кылыгыз!

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ

Балам, бәгърем, диеп

Толымыңны яраттым да,
Агарттым да, әнкәем...
Адашмаган кеше юл эзләми,
Юл табылмый әле тиз генә...
Ялгышларым белән җирдән китсәм,
Үз ялгышым калсын үземә.
Яман юлда йөр, дип, начар бул дип
Үстермәгән мине әнкәем;
Байрак итеп йөртәм: «Халык юлы –
Иң изге юл», – диеп әйткәнен.

Бу язмышым гел ялгыштан торса,
Әнкәм әрнеп искә төшерер:
Балам, бәгърем, диеп каргар да ул,
Балам, бәгърем, диеп кичерер.

Фәннур САФИН

Әнкәй

(Бер көндәлектән)

Үз илем бар, рәхмәт, әнкәй!
Үз телем бар, рәхмәт, әнкәй!

Дөньялардан ямьнәр табып,
дулкынланып, ярсып-янып
яшәү шундый рәхәт, әнкәй, –
барсы өчен рәхмәт, әнкәй!

Ризык биргән, гомереннән
өзеп биргән син үк, әнкәй...
Ләкин бөтен рәхмәтләрне
ничек әйтим? –
Син юк, әнкәй...

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА

* * *

Кочак тулы җылы утын белән
Кышкы суык
Йөгерә-йөгерә керә ишектән.
– Хәзер җылыныр өй...
Мин әнкәйне
Йокы аша гына ишетәм.

Шартлап-чәчрәп кузлар яна мичтә,
Кышкы суык
Адашкан да өйдә югалган...
Мин юрганны тарта төшеп ябам,
Изрәп китеп рәхәт уйлардан.
Өйдә җылы! Шулкадәр дә тансык,
Кышкы суык
Йөгереп кергән ул мәл ишектән.
Миңа рәхәт! Чөнки мин әнкәйнең
Аяк тавышларын ишетәм...

Инде җанны өтеп алыр кебек
Кышкы суык,
Калган чакта төрле хәлләрдә...

Хәтер һаман шул кузларны саклый,
Җылынасы килгән мәлләрдә.

Илсөяр ИКСАНОВА

Мин әни булдым, әни!..

Син мине уйлаганымнан
Күбрәк сөйгән икән.
Син дә аңламыйсың дисәм,
Син мине хәтта үземнән
Күбрәк белгән икән.

Күзләрем ник сары дисәм,
Синең сагыштан икән.
Җанга ник ут капты дисәм,
Хисләр табышкан икән.

Мин дә бүген синең кебек
Гамьнәргә тулдым, әни.
Мин сине яңа аңладым –
Мин әни булдым, әни!..

Салисә ГӘРӘЕВА

Вәгъдәләр

Тәпи басып, бераз тел ачылгач,
Әниләрнең карап күзенә,
Без әйтәбез: – Әни, үсеп җиткәч,
Тәти күлмәк алам үзеңә!

Тәмле конфет, лимон-әфлисуннар
Әниләргә вәгъдә итәбез.
Вәгъдә итәбез дә, үсеп җиткәч,
Өйне ташлап читкә китәбез.

Онытыла биргән вәгъдәләр дә.
(Бала хәтере – җәйге күбәләк!)
Әниләргә берни кирәк түгел,
Сагынып язган хатлар – зур бүләк!

Көч-куәте беткәч, әти-әни
Игелек көтә бала-чагадан.
Сабый чакта биргән вәгъдәләрне
Искә төшер шулчак яңадан:

Тәмле конфет, лимон-әфлисуннар,
Оренбурның йомшак шәлләре!
Һәркемгә дә, озак көттермичә,
Килеп җитә картлык хәлләре.

Чәчләр белән идән себерсәк тә,
Бурычыбыз бетмәс түләнеп!
...Тормыш бүләк иткән ата-анаңа
Якты йөзең булсын бүләгең!

Наис ГАМБӘР

Әнкәй төше

Төш күргәнсең, әнкәй...
Юратырга
Син кергәнсең күрше карчыкка.
(Тышта җилдер, әнкәй, иңнәреңә
Мамык шәлең бөркәнми чыкма!)

Төшең рас килер. Төшләреңдә
Агымсу күргәнсең – юл төше;
Тагын... ялгыз агач: бусы, бәлкем,
Юлда ялгыз калган бер кеше.

Тагын кыр күргәнсең –
дулкынлы кыр...
Бусы, бәлкем, йөгрек кылгандыр.
(Гөл чүлмәгең тулы кылган белән,
Бәлкем, төштә күргән кырдандыр.)

Кылганнарны «әби чәче» диләр,
Ул нәкъ синең чәч кебек, әнкәй,
Ак һәм йомшак; сулыш җиле белән
Тибрәнергә тора бит, әнкәй.

Күңелең дә кылган кыры кебек –
Җил дә исмәс борын тирбәлә;
Балаларың олыгайган саен
Кайгың олыгая.
Олы бала, имеш, зур бәла.

Төш күргәнсең, әнкәй,
Бер юл төше –
Кайтыр идем, юлым бүленгән;
Миннән хәбәр булып бара торсын,
Хат булса да сәлам бүгеннән.

Нурия ИЗМАЙЛОВА

Нәнәйгә хат

Миңа, нәнәй, һаман бер төш керә.
Ул төштән соң мин гел моңаям. –
Гомеремдәге иң беренче өйнең
Идәннәрен сагынып уянам.

Сүттеләр шул инде, яктылар шул
Сабый чакның назлы бишеген!
Шунда гына җәйрәп йокладым мин,
Шунда гына рәхәт кичердем.
Калган гомер саташу булгандыр,
Сезне сагынып, сары такталар!
Сезгә инде аяк басмадым мин,
Төш булмады ләкин кайтмаган...

Нәнәй, нәнәй! Туган ил ул нәрсә?
Мин исергән нинди хис белән?
Минем илем үткән гомерем мәллә?
Исләремә төшсә, төш күрәм.
И нәнекәй! Мин шул төшләремдә
Газиз булу бәхетен кичерәм.
Минем илем шигъри
бер моң мәллә?
Төшләремә керсә, яшь түгәм.
И нәнекәй!
Ул яшь шундый кайнар!
Җан җылыну бәхетен кичерәм.

Әнгам АТНАБАЕВ

Әнкәемә

Мин синең кулларыңа мохтаҗмын.
Бик күп куллар күрдем:
Кочагына салган кулларны да,
Пычагына алган кулларны да;
Кайсылары түргә күтәрде,
Кайсылары түбән этәрде...
Бик күп куллар күрдем,
Ләкин, әнкәй,
Синең куллардан да
гадел куллар юк!

Мин синең карашыңа мохтаҗмын.
Күп карашлар күрдем:
Иркәләүче назлы карашларны,
Оятсыз һәм азгын карашларны;
Күрдем карашларның ялкынын,
Бозга туңдырырлык салкынын...
Күп карашлар күрдем,
Ләкин, әнкәй,
Синең караштан да
гадел караш юк!

Мин синең киңәшеңә мохтаҗмын.
Күпләр киңәш бирде:
Бирәүләре «куян бул» диделәр,
Икенчеләр «уяу бул» диделәр...
«Борыныңны җилгә борып бар»...
«Чәчмәсәң дә тизрәк урып кал»...
Күпләр киңәш бирде...
Ләкин, әнкәй,
Синең киңәштән дә
гадел киңәш юк:
– Улым, үзең булып кал!





Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА

КАРЛЫГАННАР ӨЛГЕРГӘН ЧАК

(хикәя)

Бакчада кара карлыганнар өлгерде. Кара төннең үзеннән дә кара карлыганнар. Татлы да үзе, әчкелтем дә. Табигатьтә гел шулай: иң бәрәкәтле, иң шифалы сые – әче җимешендә...

– Витамин оясы бит ул! Җәен карлыган ашаган кышын чирләми, салкын тиюнең ни икәнен дә белми, – ди иде кайнанасы.

Инешкә кадәр сузылган бәрәңге бакчасында егерме төп карлыган үстерүче авылда ул гына иде.

– Ниемә сиңа шулхәтле? – дип аптыратучыларга җавабы кыска булды:

– Карлыган дым ярата, шундый уңдырышлы җирне ник әрәм итим?!

Юмарт, киң күңелле иде кайнанасы. Хәзинәне үз кызыдай якын күрде. Ятлардан түгел, хәтта улыннан да кыек сүз әйттермәде. Җәй җитте исә ахирәт кызлар сыман көлешә-сөйләшә бергәләп карлыган җыярлар иде. Үзләренә җитәрлек кайнатма ясар иде дә кайнанасы, артыгын ятим-мохтаҗларга хәер итеп таратыр иде. «Бирергә язсын, соранып йөрергә калдырмасын Раббем!» – дип, башкаларга ярдәм итә алуына сөенер иде үзе. И изге җан, иртәрәк китте шул якты дөньядан. Рәхәтләнеп оныкларын да сөя алмый калды. Ул исән булса, мөгаен, барысы да башкача булыр иде, гел башкача... Хәзинә теләгәнчә, ул исәпләгәнчә булыр иде, бәлки.

Карлыган өлгергән чор аның өчен үтә дә мәшәкатьле вакыт. Ярый әле укытучының ялы җәй көне, югыйсә ялгызың ничекләр өлгереп бетәр идең. Әле бит башка эшләр дә баштан ашкан: бәрәңгесен-чөгендерен эшкәртәсе, чүп-чарын утыйсы бар, аяз җылы көннәрдә йорт-җирне тәртипкә китереп каласы...

Алар да кайтасы бар... Һәр елны шул вакытта кайталар. Карлыганнар каралып тулышуга җыярга, кайнатмасын алып китәргә дип махсус кайталар.

Шулай итеп, Хәзинә зур кунаклар каршыларга әзерләнә. Шәһәр кешеләре янында сынатырга ярамый. Авыл халкын кимсетә торган чорлар үтте инде. Кигән киемнәре дә ялт иткән, табыннары төрледәнтөрле ризыктан сыгылып тора. Өйләрендә шундый ук заманча җиһаз, түрдә тәкәббер түрә сыман кукыраеп төсле телевизор утыра.

Сынатмаска кирәк!

Кунакларны якты йөз белән генә каршылау аз, өең балкып, суыткычың ташып торсын. Шуңа күрә әзерлек алдан ук башланды: дус-ишләре белән өмә оештырып, өйне арулап чыкты, пәрдә-чаршауларны юып элде, урын-җирләрне алмаштырды...

Сынатмаска кирәк!

Балаларның өс-башы яңартылды. Адәм күрке – чүпрәк. Үзен дә өлешсез калдырмады, кала базарына барып, сирень чәчәкләре сибелгән ачык сары төстәге бик нәфис җәйге күлмәк алып кайтты. Авыл дигәч тә... Юк, без дә төшеп калганнардан түгел! Көзгедәге чибәр хатыннан бик канәгать булып, аның каршында шактый бөтерелде Хәзинә. Шулаен шулай да, тик күңелне кимсенү хисе барыбер тырный шул. Ялгызлык сагышы кимерә аның җанын. Җиләктәй матур-татлы чаклары үзенә үзе сокланып үтә инде. Юк бит кырында «Их, хатын!» дип иркәләп-чеметеп алучысы...

Кунаклар машина белән кайтты. Үзләренеке. Сөлек кебек ялтырап торган кап-кара машина. Соңгы модель, имеш. Хәзинә аларны барыбер аермый инде. Машина тек, машина. Ә Наил белән Раилгә кызык, шуның тирәсендә әйләнеп «У-у-у!» итенәләр.

Әмирхан белән Айсылу пардан киенгән, икесенең дә өстендә шикәр кебек ап-ак футболка, зәңгәрсу джинсы чалбар. Чибәр инде үзләре, гел сокланып карап торырсың... Бигрәк тә Әмирханга... Кызлар кебек сылу гәүдәле, җитмәсә, үсмерләрчә киенгән Айсылу кулында имчәк бала күрү сәер дә хәтта. Сабыен бик җайсыз тоткан, күкрәгенә назлап кысмыйча, җансыз уенчыктай култык астына кыстырган. Өзелеп теләгәннән, тансыклаганнан түгел, башка чарасы булмаганнан гына тапты шул баласын. Имеш, авырга узуын белми калган, төшерергә соңарган... Улы тугач та, билем юаная, фигурам бозыла дип, тизрәк диетага утырды, сабыена кибет порошогы ашатты... Матурлыгын, яшьлеген күз карасыдай саклый Айсылу, үзен бик саклый. Баһадир гәүдәле Әмирханы янында мәктәптә укып йөрүче кыз бала сыман гына күренә. Машинадан төшүгә, баланы Хәзинә кулына тоттырып:

– Юл буе йокламады, җәфа, – дип зарланып алды.

Әмирхан Хәзинә белән баш кагып, тыенкы гына исәнләште, игезәкләрнең кулын ирләрчә кысып, чәчләреннән иркәләп алды. Аннары машина багажнигын ачып, аннан ике капчык шикәр комы тартып чыгарды. Һәр елны шулай, ике капчык писук алып кайталар. Берсе үзләренә, икенчесе Хәзинәгә. Хәзинәгә ул хәтле кирәк тә түгел югыйсә, әле былтыргысы да шул килеш тора. Алып кайтканнар икән, рәхмәт, берәрсенә сатар. Бераз акча керер. Югыйсә кунаклар каршылыйм дип, җәйге ялы өчен бирелгән ике айлык хезмәт хакын туздырып бетерде бит. Сер бирмим дигәч тә... Юрган турында уйлау юк, аякны иркенләп сузды.

Кара машинадан шактый күчтәнәч-бүләк чыкты. Юмарт инде үзләре. Һәр елны шулай төянеп кайталар. Ике малайга да уенчык автомат, спорт костюмы, кроссовкилар, Хәзинәгә мамык кебек йомшак нәфис халат, зур сөлге тоттырдылар. Ә конфет-печенье, җимеш ише күчтәнәчне санап та торасы юк, аларны бушаткач, өстәлдә алма төшәр урын калмады.

Бергәләп чәй эчеп алгач, Хәзинә кунакларны мунчага өнди башлады:

– Суынганчы юынып кайтыгыз әле, йокыгыз тәмле булыр.

– Барабыз, барабыз! – дип күңелле гөрелдәде Айсылу.

Аның шундый җилбәзәк, шылтыравык булуы ярап куя үзе. Югыйсә ике арадагы тартыну-киеренкелекне кем йомшартыр иде? Табын артында да гел Айсылу тавышы гына яңгырап торды. «Ярамый-килешмиләр» белән исәпләшеп тормаучыларга бу дөньяда яшәүләре күпкә җиңелдер. Артык җитди булды шул Хәзинә, үз хыялына таба бер адым атлаганчы кырык тапкыр баш вата, ишә-сүтә. Җиде түгел, җитмеш тапкыр үлчи. Күп уйлаган күп икеләнә, әкрен барадыр шул. Ә җилбәзәкләр җил кебек алга ыргыла...

Менә Айсылу аны иңнәреннән кочып алды:

– Хәзинә апа, әйдә, мунчаны икәү генә керик әле. Аулакта рәхәтләнеп серләшербез, гөрләшербез. Бу албастыны күреп туйган инде!

Чынлап сөйләшмәве сизелеп тора, Хәзинә сукыр түгел ләса. Бәясен күтәреп кылануы гына, әнә бит авызын ерып иренә күз кыса.

Әмирхан хатынының арт ягына сугып алды:

– Син туйса, мин туймаган! Кирегә сөйли башладың әле син, карчык. Кайбер җирләреңне яхшылап чәбәклисе бар.

– Синнән котылып булмас инде, туймас җан, – диде Айсылу. – Хәзинә апа, бер ярты сәгатьтән Иректе алып килерсең әле.

– Әле йокыга китте генә ич. Ничек кызганмый уятыйм? Йокласын, соңрак үзем юындырырмын, – диде Хәзинә.

Айсылу сөенеп кул чәбәкләде:

– Ой, рәхмәт яугыры, бигрәк тә яхшы булыр! Яратмыйм бала белән мунча керергә, бөтен хәлне ала.

Әмирханнан ун яшькә кече бу хатында бала кайгысы түгел, һаман үзенә кызык-рәхәт эзли. Ә тегесе, сакаллы дивана, бар теләген үтәргә әзер булып, шул чикерткә каршында биеп тора. Әй бу ир-атлар, гомер-



лек бала-чага, тыштан ялтыраганга кызыгалар шул. Башкалар каршында, менә минеке нинди матур, дип мактаныр өчендер инде.

Хәзинә өйгә керде, караватта таралып йоклап яткан сабыйга күз салды. Гөнаһысына кереп булмый, суйган да каплаган Әмирхан инде бу бала. Рәхәтләнеп сулый торган киң борыннарына хәтле аныкы, күз тимәсен.

Ерак юлдан кайткан кунаклар мунчадан соң урынга тәгәрәү җаен карар дип, Хәзинә алгы бүлмәгә керде. Кайчандыр Рубис, ә хәзер инде мендәр белән кочаклашып яткан ике кешелек киң карават кырына килеп басты. Кунаклар хөрмәтенә чигүле ап-ак күлмәк кигән йомшак мендәрләрне кабарткан булды, җәймәне сыпыргалады. Әмирхан кочагында иркәләнеп төн чыгачак Айсылудан көнләшеп, сагышка бирелде.

Хәзинәнең бәхетле кичләре аз булды шул, 32 яшендә ялгыз калды. Яшь сәламәт тәне юкка гына сулкылдап-ыңгырашып ир-ат назы көтте. Ялгызларның төне салкын, озын. Йокының тәме юк. Шулай да, Рубисы киткәннән соң беркемне үзенә якын китермәде Хәзинә. Үзен ташлап киткән иргә тугрылык саклаудан түгел, балаларыннан ояла иде. Аннары алай якын, үз итәрдәй кешесе дә очрамады.

Айсылу кайткач та, телефоннан сөйләшкәндә дә үртәп куя:

– Хәзинә апа, квартирант кертмәдеңме әле? Йоклап йөрмә, эләктер берәрсен!

Мондый тозсыз сүзләргә ачуы килә Хәзинәнең, шуңа аларны җавапсыз калдыра. Айсылу – шәһәр кызы, әрсезлеге, чаялыгы чамадан ашкан, ир-ат алдында чытлыкланырга ярата. Бәлки, Әмирханга гына карап та ятмыйдыр, тел төбеннән шулайрак сизелә. Янында бөтерелүче ир затлары хакында мактанып-масаеп сөйләргә ярата. Шулай бит ул, миргә яраган иргә дә ярый...

...Икенче көнне бергәләп эшкә керештеләр. Әмирхан белән Айсылу, аларга ияреп малайлар да карлыган җыярга чыгып китте, ә Хәзинә Ирекккә күз-колак булып өйдә калды. Эшче халкын ашатуэчертү дә аның өстендә иде. Шул арада тәрәзәдән бакча ягына да күз салгалады. Ачык тәрәзә аша Айсылуның кычкырып көлгәне, Әмирханның шаян гөрелдәве, малайларның чыркылдашуы ишетелеп торды. Бакчадагыларның кәефе шәп иде. Менә бер чиләк карлыган күтәреп улы Раил керде, аны бергәләп чистартып кайнатырга куйдылар. Җыйган уңайга кайнатсаң гына, шифа-тәмен, хуш исен югалтмый, ди иде кайнанасы.

Берара Әмирхан да өйгә кагылып чыкты. Әйрән сорап эчте. Кызыксынып түгел, сүз булмаганнан сүз булсын дигәндәй генә:

– Синең хәлләр ничек соң? – дип сораган булды.

– Ярый инде... – диде Хәзинә карашын аска яшереп. Әмирхан дип дәшергә тәки теле әйләнми, үзе дә ят, исеме дә...

Төшке аштан соң Әмирхан утын ярасы итте. Өйләренә газ кергән булса да, исе-һавасы тәмле була дип мунчаны утын белән ягалар. Малайлар да Әмирхан янында бөтерелде, ярылган утынны сарайга ташып өеп тордылар. Аннары, берүземә күңелсез, дип, Айсылу авыз салып өйгә кереп утырды да тозсыз сүзләре белән тагын Хәзинәнең җанын кимерергә кереште...

Карлыган җыелып бетмәде.

– Безгә җитә, сез үзегезгә иркенләп башка вакытта җыярсыз әле, – диде Айсылу. Аннары Әмирханны китәргә үгетли башлады.

Шулай итеп, кинәт кенә җыендылар да киттеләр. Кайнатмалары суынып та өлгермәгән иде...

Игезәкләрнең кәефе кырылды. Тузаннар туздырып кузгалып киткән кара машина артыннан моңаеп карап калдылар...

– Барыгыз, балакайлар, өйгә керегез, эсседә тормагыз, – диде Хәзинә.

Үзе турыларындагы эскәмиягә килеп утырды. Чынлап та, бик күңелсез иде. Кунаклар киткәннән соң күңелгә ягылып кала торган сагышлы бушлык кына түгел бу. Үртәлү. Кимсенү. Чарасызлык. Барысы бергә. Күңелсез... Бу авыр халәтне үзеңне аңлардай кеше белән уртаклашасы, күңел бушанганчы иркенләп сөйләшәсе килә. Мондый чакта ялгызлык дошманга әйләнә. Мондый чакта йөрәк яшьсез елый... Кан юллары буйлап, күңелнең бөтен нечкә кылларын йолка-җимерә, авыр ташлар тәгәри кебек...

...Тәрәзәдән күргәнме, койма ярыгыннан күзәтеп торганмы, каршы йорт капкасыннан үрдәк кебек атлап Җәмилә килеп чыкты. Уфылдап Хәзинә кырына килеп утырды. Сер бүлешердәй, күңел юатырдай кеше түгел дә инде, булмаганда ул да ярап куяр... Һәрхәлдә, япа-ялгызың моңаеп утыру булмас.

Җәмиләнең кайнар чыгышы бер гөнаһсыз сүздән башланып китте:

– Киттеләрме?

– Киттеләр...

– Тәки кайталар, ә?! Ел саен бит, малакаем! Бусагаңа бал сөртеп куйганмыни! Мин оялыр идем, бакчи.

– Ник оялсын, үз йорты, туган нигезе бит.

– Аңа хәзер бу нигез пычагымамы соң? Синең хәерче йортыңа калганмы әллә?! Таш катиждә яши, мыллиунлап акча аладыр әле.

– Карлыган җыярга кайталар...

– Ату инде! Кит сәнә, кеше көлдермә! Казан базарында карлыган беткән ди! Монда хәтле өстерәлеп кайтмасалар...

Җәмиләнең гел шулай. Хәтер саклап торыш юк, турыдан бәрә. Баштарак аның холкына ияләшә алмый аптыраган иде Хәзинә, сүз катырга куркып урап уза иде. Аннары күнде тагын, һәр кешенең үз холкы. Җәмилә кешене гүя үтәли күрә, чем-кара кысык күзләре белән бер генә сынап карый, күңел төбендә

агу чәчеп утырган чуаныңны табып та ала, юан бармагы белән шунда китереп тә баса... Түзсәң түз, түзмәсәң ела. Бәлки, шулай булуы хәерледәдер. Ни дип сакларга ул чуанны? Вакытында сытылсын, үтен чыгарсын. Файдалы ризык әче була ул...

Хәзинә Җәмиләне бүлдермәде, сүз үрчетмәде. Җаваплары аның белән килешеп, фикерен хуплаган шикеллерәк килеп чыкты. Соңрак алар янына сул як күрше Фәния килеп басты. Әйтер сүзләрен йомарлап килгән, килә-килешкә куенындагы йомгагын Хәзинә белән Җәмилә алдында тәгәрәтеп тә җибәрде:

– Карап-карап торам да, тагын бер уйлап куям, кызлар. Үзгәргән күрше, үзгәргән... Бакчагызда ни кыландылар. Артист дигәч тә... Туарылганнар чисти! Аларда гына мәхәббәт, инде харап! Кыланмышларына косасылар килә. Кәнтәе кубызына бии-бии, исеменә хәтле үзгәртте бит. Әмирхан, имеш! Әмир дә, хан да булсын, түлке кешечә генә булмасын. Атасы кушкан исем ярамаган.

– Ярамагандыр инде... Үзгәртергә кушканнар бит... – диде Хәзинә.

– Нәрсә кушмаслар? Ыштаныңны сал, дисәләр, анысын да салып атармы? – дип ярсып китте Фәния. – Юу-у-ук, мин булсам оялыр идем, валлаһи! Кеше күзенә күренеп тә йөрмәс идем. Артист дигәч тә... Алар да күктән төшмәгән. Кемнең кем икәнен би-и-ик яхшы беләбез! Синең урында булсам, капкама якын да китермәс идем боларны. Валлаһи, китермәс идем! Җебегән шул син, Хәзинә, артык сабыр. Үзеңне шулхәтле мыскыл иттермәсәң соң. Идән чүпрәге булма инде!

– Мин дә шуны әйтәм бит. Ятсыннар, мәйтәм, үзләренең Казаннарында! – дип болай да дөрләп янган учакка икенче яктан ут өстәде Җәмилә. – Анда артистның чуты юк, бар да шунда җыелып ята. Ату авылда гына җырларга ярамый, әбизәтелне Казан кирәк... Менә укыт син аны, малакаем... Шәһәр кәнтәе схуду эләктереп тә алды, бозауга әйләндереп тә куйды. Сәлам дә бирми хәзер, кайсы тишектән чыкканын оныткан.


Хәзинә Казан кунагын яклыйсы итте:

– Онытмаган бит, кайта...

– Кайтып соң! Болай кайтканчы, лутчы кайтмасын! Мыскыл итеп... Мин булсаммы... артларына ут төртеп куар идем! Ату!

Күршеләренең дулый-дулый акыл өйрәтүе Хәзинәгә кызык булып китте. Әремдәй ачы, кычыткандай зәһәр сүзләре белән ике яктан камчылый-камчылый, йөрәген дәвалыйлар түгелме соң? Чынлап, күңелдәге төерләр тарала төште кебек.

– Кайтсын. Балаларның атасы бит... Безнең өчен барыбер былтыргы Рубис инде ул... – диде ул тыныч кына. – Кеше тикшереп гөнаһ җыеп утырганчы, әйдәгез, лутчы бергәләп карлыган җыйыйк! Кышка витамин булыр...



Рәсем: Наталья Васильева



БАЛАЛАР КИТАПХАНӘСЕ ӘКИЯТ ИЛЕН ХӘТЕРЛӘТСЕН УЛ...

Эльмира ЗАКИРОВА

Әйе, нәкъ шулай! Анда бөтен кешегә дә рәхәт. Анда балаларны яраталар! Аларга шәхес итеп карыйлар! Уйнарга, хыялланырга, күп нәрсәләр белергә, яраткан геройларың белән сөйләшергә була онытылып... Балалар китапханәсе – серле, мавыктыргыч, тылсымлы дөнья ул. Дөньяның барлык балалар китапханәләрендә дә шулайдыр.

Казан шәһәренең Хөсәен Ямашев проспектында урнашкан Республика балалар китапханәсенә килеп кергәч, ихтыярсыз, шундый уйларга биреләсең. 1999 елда Президент Минтимер Шәймиев булышлыгы белән ачылган бу ике катлы бина чынлап та балаларның яраткан урыны, балалар китаплары тупланган зур китап йорты. Мәдәният, мәгариф, белем бирү, иҗат, туган якны өйрәнү үзәге ул. Милләтара һәм мәдәниятара диалоглар мәйданы. Киштәләргә тезелгән матур рәсемле китаплар каршылый сине. Төсле шарлар, гөлләр, картиналар... Тәрәзәләрдән кызыл миләшләр, алтын-сары яфраклы агачлар, кояш елмая... Китапханәче апалар елмая...

– Китапханәгә килеп керүгә үк елмая башлыйбыз без, – дип балкып каршылый республика балалар китапханәсе директоры МӨХӘММӘТГӘРӘЕВА Ирина Дамир кызы. – Иҗат итәсе, яхшылык эшлисе, башкаларны сөендерәсе килә...

Ирина ханым китапханә заллары буйлап алып китә. Андерсен, Перро, бертуган Гриммнар әкиятләре, «Робинзон Крузо», «Дон Кихот»лар безне озата бара. «Күңелләрен сафландырыр, бәгырьләрне йомшартыр, күзләрен яшь белән чылатыр өчен булса да Экзюпериның «Нәни принц»ын, Барриның «Питер Пэн»ын, Януш Корчакның «Король Матиуш»ын, Марк Твенның «Том Сойер маҗаралары»н укытасы иде шуларга», – ди директор. Ул янып тора. Үзе яшь, үзе тынгысыз, гел яңалыкка, алга омтыла. Класслары белән китапханәгә килгән балалар белән дә сөйләшеп ала, аларга аеруча ошаган буктрейлерларны да сораштыра, китапханәдә ел саен республика күләмендә уздырыла торган рәсем конкурслары, Балалар китап атналыгы бәйрәме хакында, татар балалар язучылары белән очрашулар турында илһамланып сөйли. Балаларның яраткан язучысы Андрей Усачев күптән түгел үзе килгән кунакка! Тиздән «Китап укучы балалар» марафоны узачак, Кытай балалар китабы күргәзмәсе ачылачак...

2019 елда Республика балалар китапханәсенең 2019–2021 елларга Үсеш концепциясе төзелгән. Концепциянең бер юнәлеше – фестивальләр үткәрү. «Китап укучы бала – китап укучы республика» фестивале, мәсәлән. Аның проекты әзер инде. Казаныбызда парк-скверлар күп. Җәй айларында шундагы мәйданчыкларга балаларны әти-әниләре, әбибабалары белән чакырырга уйлыйлар. Эшне Язучылар берлеге, Татарстан китап нәшрияты, театрлар, мәктәпләр, балалар бакчалары, музейлар, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы белән бергәләп оештырачаклар... Ә елның иң зур вакыйгасы, әлбәттә, Республика балалар китапханәсенең 100 еллык юбилее булгандыр!

– 2018 елның 29 ноябрендә мине Республика балалар китапханәсенә директор итеп билгеләделәр. Ә май аенда китапханәнең 100 еллык юбилее иде. «Уздырырга кирәк!» – диделәр. Алны-ялны белми юбилейга әзерләнә башладык. Коллективка ияләшергә, документлар белән танышып чыгарга, киләчәккә планнар төзеп утырырга вакыт та калмады, – дип көлеп искә төшерә Ирина Дамировна.

Ә ничек барысын да җиңеп чыктыгыз?

– Коллектив, янәшәмдә эшләүчеләр бик яхшы. Мин аларга таяндым. Дәүләт хезмәтендә актив эшкә күнеккән идем инде, шул тәҗрибә бик ярдәм итте. (*Ирина Мөхәммәтгәрәева Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында 7 ел эшли, 2014–2018 елларда министрлыкның эшләр белән идарә итүче вазыйфасын башкара* – **Э. З.**).

Минтимер Шәриповичның бик акыллы сүзләре бар: «Хөкүмәт эшендә, бюджет учреждениеләрендә стрессларга түзем кешеләр генә эшли ала». Бу хакта миңа әнием дә, ирем дә һәрчак искә төшереп торалар. Эшкә кайчак юмор белән дә карарга өйрәнергә кирәк!

Март ахырында Италиягә балалар китапханәләре житәкчеләре конференциясенә бардым. Анда уздырылган түгәрәк өстәлләр, тәҗрибә уртаклашулар бик ярдәм итте миңа. Китапханәнең 100 еллыгына без дә ерак һәм якын чит илләрдән, Мәскәүдән, Россия төбәкләреннән, күрше республикалардан бик күп кунаклар чакырдык. Мәдәният

Китап укуга иялəштереп,
балага рəхəт мизгеллəр бүлəк итəбез.



министрлыгы белəн бəйрəмне үткəрү датасын 14 июньгə планлаштырдык. Казан Ратушасында балалар китапханəсе бəйрəме гөрлəде!

Балалар китапханəсе тарихын искə төшерсəк...

Республика балалар китапханəсенең тарихы 1918 елның 17 маеннан башлана. Республикада мөстəкыйль балалар китапханəсе оештыру буенча дəүлəт программасын тормышка ашыру максатыннан балалар китапханəсен ачуга язучы Екатерина Николаевна Нелидова зур өлеш кертə, беренче директор була. (*Шкафтан Е. Н. Нелидова китабын кулына ала.*) Безнең китапханə башта Некрасов урамында ачыла, аннары Карл Маркс, Дзержинский урамнарына күчерелə. Восстание урамындагы, Киров районындагы биналар да китапханə хезмəтен үти... Рус һəм татар теллəрендə эшлəүче əдəби түгəреклəр турында бөтен Казан белə! Татар секциясенə язучылар Абдулла Алиш, Фатих Хөсни, Сибгат Хəким, Идрис Туктар килə. Булачак балалар язучысы Җəвад Тəрҗемановның таланты нəкъ менə шушы түгəреклəрдə ачыла...

Бик кызык! Никадəр шəхеслəргə юл ачкан китапханə!.. Ə минем Ратушадагы юбилей тантанасына кабат əйлəнеп кайтасым килə...

– (*Җанланып.*) Башкалабызның затлы бинасында искиткеч матур бəйрəм булды ул! «Детское чтение как национальное достояние» дип аталган төбəкара фəнни-гамəли конференциягə 20 дəн артык төбəктəн кунаклар килде. Конференция эшендə 150 дəн артык кеше катнашты. Россия Федерациясенең 16 субъектыннан, Татарстанның 43 муниципаль районнарыннан... Россия дəүлəт балалар китапханəсе директоры Мария Александровна Веденяпина зур бəя бирде. Форумның рəсми өлеше Россия дəүлəт балалар китапханəсе һəм Татарстан Республикасы балалар китапханəсе



Кечкенә баланың хыялы, теләге шулкадәр мөһим безнең өчен!

арасында фәнни-методик, фәнни-тикшеренү һәм мәгълүмати эшчәнлек буенча хезмәттәшлек килешүенә кул кую белән тәмамланды. Аннары инде әкияткә тиң мавыктыргыч күңелле бәйрәм дәвам итте.

Ирина Дамировна, сез үзегез дә әкиятләр укып, матурлыкка мөкиббән булып үскәнсез, ахры?

– (*Онытылып.*) Әйе, мин әкиятләр ярата идем. Шул дөньяда тормышны да әкият кебек кабул итеп үстем. Чын шәхес булып җитешсен өчен, һәр бала гаиләдә үзенә якын, аны яраткан кешеләр арасында, мәхәббәт һәм җылы мөнәсәбәтләр атмосферасында үсәргә тиеш дип уйлыйм. Мин үзем яратуга, назга коенып үстем. Балачагым мәдәни, иҗади яктан бик актив узды. Түгәрәкләр, сәнгать мәктәпләре, цирк мәктәбе, гимнастика, йөзү... Барысына да йөри идем. Әти белән әни көне буе эштә булгач, әби-бабаларым, туганнарым чиратлап йөртте. Мин барысы өчен дә кадерле бала идем. Беренче онык, беренче турун...

Балалар китапханәсе директоры балачакта нинди кыз булды икән?

– Тумышым белән мин Чаллыдан. Әни физика-математика укытучысы иде, аннары тәрбия эшләре буенча завуч булды. Әтием – төзүче. Әни ягыннан әби-бабам Белгород яклавыннан КАМАЗ төзелешенә килеп урнашкан. Бабам 40 ел буе КАМАЗның Кузнечный заводында цех начальнигы булып эшләде. Ул Үзбәкстанда хезмәт иткән, әнием Сәмәркандта туган. Әти ягыннан бабам – кабардин, Нальчик шәһәреннән. Асламбек исемле иде. Әбием Шәмсеямал – Баулыныкы. Менә шундый интернациональ гаилә! (*Көлә.*) Җәйге каникулларым Баулыда үтте. Әбием русча начар сөйләшә иде, татарча сөйләшергә өйрәндем! 7 яшьтә балалар сәнгать мәктәбенең хореография бүлегендә укый башладым. Әни мәдәният-мәгариф өлкәсендә билгеле кеше: ул оештырган «Цирковая мозаика» номеры «Созвездие» фестивальләрен, Сабантуйларны бизи. Хореографияне дә, музыканы да, цирк жанрын да берләштергән шул программада катнаштым. Чаллыда В. Я. Ураков җитәкчелегендә «Болгар» татар хореография ансамбленә йөрдем. Профессионаллар белән берлектә чыгыш ясау үзе бер өйрәнү мәктәбе булган! 1996 елда Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясенә укырга кердем. Без Чаллыдан өч дус кыз килдек, өчебез дә кердек. Ул чакта ректор Рәис Беляев иде. Чаллы балаларын аеруча якын итә. Без имтихан тапшырганда да кереп утырды ул. Нинель Даутовна Юлтыева имтихан кабул итте. Мин «Ахирәтләр» дигән шаян бию башкардым. Безнең 263 нче группа бик дус, тату булды. Атаклы Нинель Юлтыева шәкертләре булуыбыз белән бик горурлана идек. Студент елларында «Салават» театры, Рәсим Низамов, Алсу Әбелхановалар белән чыгышлар ясап йөрдек. Районнарда, Мәскәүдә дә... Укып бетергәч, группадашларның күбесе үз ансамбльләрен оештырды, музыка мәктәпләре ачты. Без берничә кеше генә башка юнәлештән киттек.

...?!

– Мин укуымны алга таба да дәвам иттем... Казан финанс-икътисад институтының «Бухучет. Анализ һәм аудит» факультетына укырга кердем. Мәдәният академиясеннән хореограф белгечлеге белән безгә укырга килүчене беренче күрүебез, дип, бик гаҗәпләнделәр! (*Көлә.*) Ул белемнәр тормышта бик кирәк булды.

Тәфсиллләбрәк сөйләгез әле!

– Мәдәният өлкәсенә шундук бармадым әле. Хезмәт хакы бик кечкенә иде, ул мине канәгатьләндермәде. Әти дә вафат булды. Акча табу, фатир сатып алу турында уйларга кирәк иде. Әни Казанга күчеп килде, үз бизнесын ачып җибәрде. Мин дә кереп киттем шунда. Нинель Даутовна безнең кибеткә дә килде. «Кайчан син мәдәнияткә киләсең инде!» – диде ул. «Башта фатир, машина өчен эшлим, барысын да нульдән баш-



■ «Аңлы, тәрбияле балалар – безнең киләчәгебез», – ди Республика балалар китапханәсе директорының урынбасары Гөлнар Харис кызы Иксанова. Бер генә чара да аның зирәк оештыру осталыгыннан башка узмый! Ә тормышы гел мәктәп, мәгариф, мәдәният дөньясында кайнап бара. Гомерен балалар укытуга багышлаган югары дәрәҗәле укытучы, Мәдәният министрлыгының алыштыргысыз хезмәткәре, китапханәнең алтын баганасы, өч булган кызның әнисе, диләр аның турында. Республика күләмендә уздырган мәдәни чараларын, ачык дәресләрен әле дә үрнәк итеп сөйлиләр. Мәдәниятне иң чиста, иң матур, кешене рухи яктан тәрбияләүче иң көчле өлкә дип саный ул һәм һәрвакыт яңалыкка омтылып яши.

ларга кирәк. Финанс ягы җайлангач, яраткан эшемә кайтам», – дидем. Бер апам киңәше белән резюмемны кадрлар бүлегенә җибәрдем – ул мәдәният өлкәсендә эшләвемне тели иде. Берничә көннән чакырып алдылар. Шактый зур тәҗрибә тупладым анда...

...Һәм әзерлекле җитәкче булып китапханәгә килдегез! Укучыларыгыз нindirәк?

– Иң төп максатларның берсе – баланы китап укуга җәлеп итү. Безнең китапханәгә 0 дән 14 яшькәчә балалар йөри. Бер яшьлекләре – коляскада, 3-4 яшьлекләре – әти-әниләре белән... Еш кына бәби көтүче авырлы ханымнар килә. Аларны бала тәрбияләүгә багышланган китаплар кызыксындыра. Бер баласы коляскада йоклый, тәпи йөри башлаганын җитәкләгән, туасысы – әле карынында... Менә шундый матур күренеш. Ә балалар өчен әдәбият күп бездә, ул гел яңарып тора. Матур рәсемнәр белән бизәлгән китаплар, музыкаль китаплар, 3 D китаплар... Фондны гел яңартырга тырышабыз. Яшь үзенчәлекләрен, мәктәп программасын истә тотабыз. Безнең укучылар өч төркемгә бүленә: 3 яшькә кадәр балалар, мәктәп яшендәгеләр, үсмерләр.

Китап укуның үз тәме, рәхәте бар бит аның! Китапның үзенә хас исе бар... Өйдә кич утырганда кычкырып китап уку йә әниең, әбиең укыганны тыңлау...

Класслары белән килүчеләр дә шактый. Без ул очрашуларга язучыларны, актерларны чакырабыз. Бала китапка бөтенләй башка күз белән карый башлый. Китап укып үскән баланың офыклары киңәя, ул кызыксынучан, аралашучан булып үсә.

Ирина ханым, сез чит илләрдә еш буласыз. Һәм, әлбәттә, китапханәләрен дә күрми кайтмыйсыз. Кайларда нинди яңалыклар шаккаттырды? Хыялыгыздагы китапханә нинди ул?

– Италиядә китапханәләр гаилә клубы кебек. Әти-әниләр балалары белән йөри анда. Үзебездә дә менә шуны кертәсем килә. Китапханәдә бөтенесе зоналарга бүленгән. Әти кеше – компьютер артында, әни кеше чигү чигеп утыра, ә балалар белән аерым залларда шөгыльләнәләр. Анда балаларның исемнәре язылган үз носкилары бар хәтта! Шуларны киеп, китапханә эчендә көннәр буе йөриләр, чыкмыйлар да. Кафе да бар шунда, уйнап алырга да була, кино да карыйсың... Инфраструктура истә калырлык, әлбәттә. Алар китапханәдән башка яши алмый кебек. Өйдәгечә җылы, рәхәт дөнья. Без дә менә шуңа омтылабыз. Кая барсам да, балалар китапханәләренә ашыгам. Аларда ничек? Безгә ниләр алып була? Рухы, җаны белән Россия балалар китапханәсе бик якын миңа. Шәп команда! Ниләр генә оештырмыйлар! Түләүле хезмәт күрсәтү дә бар Мәскәүләрдә. Балалар анда дусларын чакырып туган көннәрен уздыра. Пирожныйлар, китаплар, квестлар белән... Китаплар ачыла башлый, андагы бөтен әйбер җанлана: песиләр мияулый, күбәләкләр оча... Шундый кызык! Мин дә кызыгам шулай эшләргә! Бөтенесе канәгать калачак, күңелле һәм файдалы ял булачак! Безнең яраткан урын – үзебезнең китапханә ул! Безгә монда бик ошый! Балаларның канәгать китүе кәефне күтәрә. Ул инде яшәү мәгънәбезгә әйләнгән. Бала – төп герой бездә. Һәм бөтенебез аның тирәсендә бөтерелә...



Фото: Анна Арахамия



Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Авылымнан киткәнгә инде 67 ел, ә мин һаман әле туган җирне сагынып яшим. Анда гомер итә торган туганнарыбыз да юк инде. Әмма мин барыбер ел саен кайтып җиләкле яланнарда аунап, матур күлебезне күреп киләм. Кызганыч, авылыбыз гына бетү ягына бара. Ә күпме истәлекләр, матур хатирә бәйле аның белән!

...Мин әниемнең җиденче баласы булып дөньяга килгәнмен. Бу хөрмәткә әниемә медаль тапшырганда бер сарык белән бер капчык он да биргәннәр. Күп балалы гаилә өчен бу бик зур шатлык булган, әлбәттә.

1942 елда сугышка киткән әти кире әйләнеп кайта алмый. Җиде бала һәм карт әби белән калган әнигә бер дә җиңелләрдән булмагандыр. Шулай да, тормыш сынауларына бирешмичә, 86 яшенә кадәр яшәде ул. Ә мин авылда дүртенче классны тәмамлагач, зур апа белән районга күчеп, унынчы классны тәмамладым. Аннары фельдшерлык һөнәрен үзләштереп, авылда эшләдем. Хатын-кыз бәхетем хәрби кеше белән бәйле булып чыкты. Офицерга кияүгә чыгып, бик матур тормыш кичердек. Шөкер, инде хәзер онык-оныкчыкларыбызның кадерле дәү әти-дәү әниләре булып яшибез. Дәү әтиебез генә менә инсульт кичереп, дүрт ел инде урын өстендә ята. Ә мин әле бирешмим! Авылымны яратып, тормышта булганына сөенеп, балаларым һәм тормыш иптәшемә терәк булып яши бирәм. Аллага шөкер.

Мөнирә ЛАТЫЙПОВА.
Казан шәһәре.

Мин көн саен эшкә 15 нче автобуска утырып йөрим. Кондуктор транспортның визит карточкасы булырга тиештер бит инде. Менә шундый уйларга этәргән бер сәбәп булмаса, бу хатны язмас та идем...

Җәй көне булды бу. Гадәттәгечә, иртән автобуска кереп утырдым. Бер тукталыш узуга ук, кондукторның үз-үзен тотышы кәефне кыра башлады. Ташламалы юл йөрү билетымны бер билгеләп китте бит инде. Икенче тукталышта тагын яныма килеп, чәнечкеле генә итеп: «Ә кем билет ала?!» – димәсенме! Кабат сумкамнан билетымны чыгарып күрсәттем.

Юл сумкалары тоткан бер ханым итагатьле генә итеп автобусның «Тандем»га барамыюкмы икәне белән кызыксынды. Күренеп тора: безнең шәһәрнеке түгел бу ханым. Кондуктор кыз аңа тупас итеп: «Бара!» – дип кычкырды. Мин кондуктор җавабы өчен оялып куйдым. Ике апа сөйләшеп утыра иде. Кондукторның кәефе юклыкны чамалап, тиз генә «проездной»ларын сузарга ашыктылар. Ә тегесе әйләнеп тә карамыйча алгарак үтте. Кабат әйләнеп килде дә билет алуларын таләп итә башлады. Апалар, аклангандай: «Менә бит, без әле генә сезгә әйттек...» – дип сүз башлауга, «Ничек телим, шулай эшлим! Өйрәтмәгез! Ачыклыйсы бар әле: картагыз үзегезнеке микән!» – дип шик белдерде. Кирәк бит нәкъ шул чакта, теге сумкалар күтәргән ханым тагын: «Гафу итегез, ә автобус «Кәҗә бистәсе»нә дә барамы?» – дип сорап куйды. Аяз көнне яшен суктымыни: кондукторның ачы тавышы бөтен салонга яңгыратты: «Син нәрсә? Күктән төштеңме әллә? «Тандем» белән «Кәҗә бистәсе» бер юнәлештә, сарык!» Бу инде баш түбәсенә кундырудан бер дә ким түгел иде! Казанга читтән килгән кеше безнең халык турында ниләр уйлагандыр...

Яңадан ул кондукторны башка бер тапкыр да очратмадым. Әллә туры килмәде, әллә инде җибәргәннәр, әллә үзе киткән...

Ә менә башка бер троллейбус кондукторына сокланганым истә. «Хәерле иртә, хөрмәтле пассажирлар!» – дип, һәр тукталыш саен

юлчыларны елмаеп сәламли иде ул. Өлкәннәргә, балалы пассажирларга җайлырак урын тәкъдим итте. Хәерле юллар теләде. Шундук кәефләр күтәрелеп китте. Транспорттагылар да елмая башлады. Кешегә күп кирәкми шул! Шагыйрь Әнгам Атнабаевның шигырь юллары искә төште:

Бу кешегә ифрат аз җитә:
Бер җылы сүз –
Күңел эретерлек наз җитә...

Альбина СӘЛАХОВА.
Казан.

Шәһәрдәге зур сәүдә үзәкләренә барган саен, балалар шау-гөр килеп торган уен мәйданчыкларын гаҗәпләнеп күзәтәм. Балаларның үз дөньясы монда, әниләр дә сулыш алып, бераз тынычланып утыралар. Әмма никадәр файдалы икән соң заманча ясалган уен мәйданчыклары?!

Әйе, оештыручыларга шактый керемледер инде, ул турыда сүз дә юк. Акча түләп баласын уен мәйданчыгына алып килгән әниләр ни уйлый?! Тузаны да, инфекция, төрле бактерияләре дә җитәрлек бит инде монда. Җилләндерү юллары да начар эшләнгән, ә инфекцияләр ябык җирлектә тизрәк үрчеп тарала. Төрле җәрәхәтләр дә алырга мөмкиннәр. Балаларны карап-күзәтеп торучы яшь кенә егетләр-кызлар ни дәрәҗәдә әзерлекле?! Җиңеллек эзләүме икән инде бу, әллә замана шаукымымы?! Аңламассың... Аннары балалар еш авырый, шәһәрдә иммунитет түбән дип зарланалар. Баланы табигатьтән аермаска кирәк! Бөтен сер дә шунда дип уйлыйм. Табигать ул – авыл дигән сүз генә түгел бит. Шәһәр уртасында да бик матур парклар, урманнар бар. Шәһәрдән ерак китмичә генә дә табигать кочагына чыгарга була. Бала белән табигать бәйлелеге бик мөһим ул. Юкка гына кичләрен йоклар алдыннан тынычланыр өчен балаларга су, кошлар, урман тавышы язмаларын тыңлатырга кушмыйлардыр. Табигатькә, кошкортларга сакчыл караш та кечкенә чактан ук тәрбияләнә. Балалар табигатьтә үзләрен иркенрәк, рәхәтрәк хис итәләр.

Шуны онытмасагыз иде, яшь әти-әниләр! Алда кыш, вирус, инфекцияләр чоры. Даруханәгә чиратка тезелгәнче балалар белән урманнарга, табигатькә чыгыгыз! Файдасын күрерсез!

Әминә ГАЛИУЛЛИНА.
Чаллы шәһәре.



Томск шәһәрендә «Татар шәһәр бистәсе. Үткәне, бүгенгесе һәм үсеш перспективалары» дигән темага Бөтенроссия форумы оештырылган иде. Әлеге форум ТАССР төзелүгә 100 ел тулу уңаеннан ике төбәкнең сәүдә, икътисадый, фәнни-техник, социаль мәдәни хезмәттәшлек кысаларында узды.

Адлер–Барнаул поездына утырып килгән төбәкне өйрәнүче бер төркем журналист һәм галимнәрне Новосибирск шәһәрендә өлкәнең татар мәдәнияте үзәге директоры Рауза Тихомирова каршы алды. Ул татарлар белән бәйле тарихи урыннарда йөртте. Бу төбәктә милләттәшләребез VIII гасырда ук яшәгән. Йорт-Оры дигән татар авылына да бардык. Авыл кешеләренең милли гореф-гадәтләрне кадерләп яшәвен күреп бик сөендек. Шулай да безнең белән очрашуга калфаклар киеп килгән 93 яшьлек Гөлҗиһан апа Шиһабетдинова, 85 яшьлек Рәйсә апа Сәфәргалиева, 75 яшьлек Фәйрүзә апа Кинҗәголова күзләрендә сагыш иде. Бар тормышлары монда узса да, туган якны сагына иде алар. «Безнең әниләр бирегә Идел буендагы ачлык заманында Күгәй дигән авылдан күчеп килгән», – дип сөйләде апаларның берсе.
Ә Новосибирск мәчетен җитәкләгән Рафаэль хәзрәт Сөләйманов: «Бәйрәмнәрдә җыелган 800 мөселманның дистәгә якыны гына татар», – дип ачынып куйды. Бирердәге милләттәшләребез белән аралашып, кызыклы язмышларны барлап, сәяхәтебезне Томск шәһәренә таба дәвам иттек.

Томскидагы форумга бик күп галимнәр, күренекле кешеләр җыелган иде. Төрле кызыклы лекцияләр, мәдәни мирасны саклау буенча тирәнтен чыгышлар булды. Форум тәмамланганнан соң да әле күңелле очрашулар дәвам итте. Кайтыр юлда Екатеринбург шәһәре белән танышып чыктык. Юлыбыз Сакко һәм Ванцетти урамында татар сәүдәгәрләре Агафуровлар салып калдырган йортка – Татарстан Республикасының Урал төбәгендәге даими вәкиллегенә ялганды. Бирердәге милләттәшләребезнең тарихи үткәне һәм бүгенгесе белән таныштык.
Бер төркем тарихчылар шәһәр читендәге 1879 елда ачылган татар зиратына бардылар.
Бу сәяхәт барышында Себердә, Уралда соклану уяткан, кайчандыр сәүдәләре белән гөрләп торган татар бистәләре яңадан кайтсын иде дип хыялландым.
Туган телебездә каршы алып, безгә кадер-хөрмәт күрсәткән милләттәшләребезгә рәхмәтләремне җиткерәм!

Равилә МӨБАРӘКШИНА.
Казан.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан,
Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

«КЫЗЫМ-ЙОЛДЫЗЫМ...»

Бу язманы мин башкача күз алдына китергән идем. Галия ханым (исемнәр мәгълүм сәбәпләр аркасында үзгәртелде) сүзләреннән соң юрист комментарие торырга тиеш иде. Соңгы минутта кире уйладым. Кешелек кыйммәтләре дигән нәрсә бар тормышта. Намус бар. Алар барысыннан да өстен! Моның шулай икәнен тормыш, бүген булмаса, иртәгә раслаячак.

Гөлнур САФИУЛЛИНА



«Соңгы вакытта гел бер нәрсәдән куркам – акылымны җуюдан... Сезгә мөрәҗәгать итүем дә, ярдәм-киңәш көтүдән бигрәк, азрак күңелемне бушатырга теләвемдер. Бер ел элек 28 яшьлек кызын җир куенына салган ананы аңларсыз дип өметләнәм.

Кеше үзенә кайчан, нинди хәсрәт киләсен белми. Әле ярый белми... Миндә дә алдан берниндн сизенү булмады.

Якутиядән Казанга күчеп кайтуыма әле биш кенә ел. Беренче иремнән бала белән аерылгач, очраклы рәвештә генә бер ир-ат белән таныштым. Озакламый ул Нерюнгри шәһәренә эшкә китте һәм безне дә үзе янына чакырды. Гомернең күп өлеше, шулай итеп, Якутиядә узды. Алтын табу приискаларының берсендә озак еллар бухгалтер булып эшләдем. Зур предприятие иде: мин анда өлкән бухгалтер вазыйфасына кадәр күтәрелдем.

Икенче кызым – Алиям Якутиядә туды. Әтисенең аны ничекләр өзелеп яратканын аңлата алырмынмы икән?! Безнең татар ирләренә баланы үлеп ярату хас түгел бит ул. Ә бу?! Кызым – аның 37 яшендә генә кулына алган беренче баласы иде. Ул хәтта төннәрен бала елагач, мине торгызмады, һәрвакыт: «Үзем!» – диде... Теләчедә йорт алган идек. Шунда кайткач, мунчада ис тиеп, көтмәгәндә үлеп китте ул. Кызыма бу вакытта 10 яшь иде. Мин ул чакта гел бер нәрсәдән курыктым: «Шулкадәр яраткан кызын үзеннән калдырмас инде бу», – дидем. Адым саен күңелемнән мәрхүм иремә ялынып йөрдем: «Алма инде, баламны, алма, кызган мине...»

50 яшем тулып, пенсиягә чыгуга, Татарстанга күчендем. Алия бездән алданрак кайтып киткән иде инде. Ул монда колледж тәмамлады, аннан эшкә урнашты. Үзем эшләп йөргәндә үк, 2008 елда аңа Казанда фатир алып куйдым, ремонт өчен акчасын җибәрдем. «Әни, минем фатирым шундый матур!» – дип сөенде. Миңа да шатлык: кызым ипотека түләми, аталы балалардан ким яшәми. 2014 елдан башлап ул бу фатирда үзе генә торды.

Булачак ире белән интернет аша таныштылар алар. Пермь краеның Барда районында туып-үскән, Казанда янгын сүндерү депосында эшли иде ул егет. Озак очрашып йөрмәделәр, кавыштылар. Әниләре кыз сорарга килгәч, фатир турында да сүз чыкты. Мин аны башта ук кызым исеменә яздырган идем: безнең нәсел кыска гомерле, ул-бу килеп чыкса, кызларым фатир аркасында ачуланышмасын, кеше көлдермәсен дип уйладым. Кем белә, бер ата балалары да кайчак төрле була... «Безнекенең бернәрсәсе юк инде, хезмәт хакының яртысын фатирга түләп тора», – диде булачак кодагый.

Никах укыттык, яшәп киттеләр. (Сүз уңаеннан, никах, туй чыгымнарын барын да үзем күтәрдем.) Сизәм – төрле вакытлары була. Кулымнан килгән кадәр булыштым: яшьләр бит, киенәселәре килә, хезмәт хаклары аз.

Алия авырый башлагач, үземне авырлы дип төштә күргән идем. «Димәк, балам тугыз айдан китә икән», – дип ачынып уйладым. Шулай булды да...

Алиягә башта «неразвивающаяся беременность» дигән диагноз куйдылар. Бераздан кабат балага узды. Тик анысы «внематочная беременность» булды. «Бала таба алмас, ахрысы, тәрбиягә алырлар», – дип уйладым. Иренә бала кирәген әйтмәсәләр дә, сизә идем. Үстерә алырлармы дип кенә борчылдым: мин гел ярдәм итә алмам бит.

2018 елның февралендә кызым: «Әни, минем бер күкрәгем авырта», – дип килде. Табибка беренче баруында ук диагнозы билгеле иде инде: яман шеш, 3 нче стадия. Шул көннән башлап – 2018 елның 18 февраленнән мин инде яшәмим...

Хастаханәгә йөгердем: табибларны таптым, сөйләштем. Ул юлларны узган кеше мине аңлар, белмәгәннәргә исә күрергә язмасын...

Сигез химия алды Алия. Ире берсенә дә бармады, янында гел үзем булдым.

Дүрт химия кызыл төстә – аларына түзәргә була әле. Ак төстәгеләре яман. Анысыннан соң аяк-куллары берәр атна йөрми. Һәр химиядән соң үземә алып кайттым, азрак рәтләнгәч кенә өйләренә җибәрдем. Рәхмәт, эшемнән бик булыштылар ул чакта, кайчан килсәм-китсәм дә сүз әйтмәделәр... Операция көне җитте. Кияү ялга әнисенә кайтып китте. Китәр алдыннан кызыма 50 меңгә кредит алдырганын соңыннан гына белдем. Үз исеменә ала алмагандыр инде. Авылдагы өйләренә газ керткән. Әнисенә булышуына һич каршы түгелмен анысы. Тик мин бу хакта болар кредитны түли алмыйча, пени үсә башлагач кына белдем. Тагын акча бирдем, җәлләп әйтүем түгел – кызым өчен тырыштым.

Операцияне ясадылар, әйбәт кенә узды шикелле. Әмма артыннан ук начар хәбәр дә килеп җитте: анализлары начар – метастаза башланган, лимфа төерләре аша инде таралырга өлгергән. Кызыма боларның барысын да белгертмәскә кайдан көч таптым икән ул чакта, белмим... Таныш табибым: «Әзерлән, озак тормый, башына китәчәк», – диде. Шулай булды да. Операциядән соң бер ай үтүгә, аның башы авырта башлады. Ашый алмый. МРТ ясаттык, тик ул бернинди дә шеш күрсәтмәде. Невропатолог: «Борчылмагыз, химия тәэсире, ул шулай чыга», – диде. Кабат нурланыш ала башладык. Кызның хәле көннән-көн начарлана бара... Эшли дә идем бит әле. «Болай ике арада бәргәләнеп булмый», – дип, барып гариза яздым, эштән киттем.

Фото: www.pixabay.com

«И-и кызым, эчемдәге бөтен органымны сиңа бирер идем, булмый бит», – дия идем өзгәләнеп.

Тагын тикшертергә керештем. Башында, чынлап та шеш таптылар, әмма: «Операция ясый торган урында түгел», – диделәр. Өмет бар бит – бер табибтан икенчесенә йөгерәм. «Юк», – диләр... Бу сүзне нейрохирург әйтсә, чынлап та, булмый икән инде ул. Озак тормаячагын аңлый башладым. Ачыктан-ачык берсе дә әйтмәде – кызганганнардыр инде... «Әни, үзем генә тора алмыйм», – дигәч, кызымны өйгә алып кайттым. Бездә дә иркен түгел, билгеле: ике бүлмәле фатир булса да, олы кызым, онык белән бергә яшибез. Чәчләре коела башлагач, чәчтарашханәгә алып барып, чәчен бөтенләй алдырдык. Кызларга рәхмәт, кемдер килеп кереп күрмәсен, аңа авыр булмасын, дип, ишекне бикләп тордылар...

Бу чирне кичергәннәр белә: сырхауханә юлыннан кайтып кермисең. Әле бер табибка күренергә кирәк, әле икенчесенә. Анализ арты анализ тапшырасың. Һәм күп очракта түләп тапшырасың. Башкача булмый, чөнки вакыт сине көтми. Һәр көн генә түгел, һәр сәгать исәптә. Бу юлда түккән акчамны үзем генә беләм... Жәлләп әйтүем түгел. Кызым өчен бернәрсәм дә жәл түгел иде миңа. Ире боларның берсен дә белмәде, кызыксынмады дип кенә әйтәсем килә.

Ул арада иренең юбилее җитте – 30 яшь тулды. «Хатыныңның хәле әйбәт түгел бит, әллә үткәрмисеңме?» – дип әйтеп карадым. Аның фатирында иренең туган көнен уздырып ятканын Алия белде, әлбәттә. Бөтен инстаграмны фото белән тутырды бит... Ә минем кызның ике кулында да система. Миңа белгертмәскә тырыша, ә үзе елый. «Әни, мин аның белән аерылышам», – ди. «Терелгәч, бала алам, син миңа булышырсыңмы?» – ди. «Бала да таба алмыйсың, мин сине ташлыйм», – дип, гел битәрләп торган ире.

Туган көнгә кодагый да килгән, икенче көнне бик тизгә генә безгә дә кереп чыкты. Миңа: «Картаеп киткәнсең», – диде...

Октябрь ахырында безгә «паллиатив ярдәм» килеп йөри башлады. Дүрт сәгать саен укол кадап китәләр. Булышмый... Тирә-юньдәге кайсы даруханәгә керсәм дә, мине таныйлар – баламның хәлен җиңеләйтү өчен нинди генә дару алып карамадым?! Алиянең хәле бөтенләй начарлангач, ире дә килде. Мин инде ул көннәрдә мулланы да чакырта башлаган идем. Кызым инде йөри алмый, күрми, сөйләшми, әйтәсе сүзен яза гына... Соңгы көн якынлашканын бөтен күзәнәкләрем белән тоям, барысын да аңлыйм, әмма ышанасым килми! 7 ноябрь көнне «паллиатив ярдәм» табибына: «Тагын ниләр эшләп карыйм икән?» – дим. «Ярамый дип торма, җаның нәрсә куша – шуны эшлә», – диде. Ә үзенең күзендә яшь...

Иртәгәсен без аны җирләдек. Әтисе янәшәсенә... Җеназа белән бәйле барлык чыгымнарны үзем күтәрдем, рәхмәт, элеккеге хезмәттәшләрем дә булышты, әтисенең энесе дә бик ярдәм итте. Ире исә: «Менә эштән акча бирделәр», – диде дә кире кесәсенә тыгып куйды...

Икенче көнне килеп, кияү фатирның документларын калдырып китте. «Хәзер поезд белән әниләр килә, аларны каршы алам», – диде. Кодагый миңа бер кызы белән керде.

– Киленнең өчесен үзебез уздырып китәбез, – диде.

–Ярар... – дип калдым.

Төш белән өн арасында йөргән чагым. Авыр, ләкин әле ул авырлыкның ни дәрәҗәдә икәнен аңлап бетермәгән көннәр...

Кичке сигездә кияүнең апасы шалтыратты: «Энем кан тамырларын кискән, бөтен фатир канда», – ди. Миннән кайткач, сөйләшеп утырганнар. «Менә бернәрсәсез урамда калдың, фатирың да юк», – дигәннәр һәм үзләре шәһәр карарга чыгып киткәннәр... «Шундый вакытта ничек инде аны ялгызын калдыра алдыгыз?» – дип апасын ачуландым һәм: «Кияү анда юк икән, фатирны җыештырыгыз да, бушатыгыз. Өчесен үзем уздырам», – дидем. Кодагыйның сеңлесе яши Казанда – барыр урыннары барын белә идем.

Кияүгә шалтыратып хәлен белештем – ул хастаханәдә озак ятмады, чыкты. Шуннан соң аның белән күрешкән булмады.

Кызымның вафатыннан соң ярты ел үткәч, фатир документлары артыннан нотариуска бардым. Анда миңа аяктан егарлык хәбәр җиткерделәр: «Киявегез үз өлешен бүлеп алырга тели», – диделәр. Шалтыратып сөйләшерлек хәлем булмады. «Сиңа нәрсә кирәк?» – дип язып кына җибәрдем. «Я тебе мстить буду», – дип җавап бирде. Имеш, мин аның әнисен фатирдан куып чыгарганмын...

Фатирны югалту – баланы югалту түгел. Мин анда барыбер яши алмыйм, сатарга дип ниятләп куйган идем. Бергә өч ел гына яшәп калсалар да, кияүгә дә өлеш чыгарырмын дигән уем да бар иде. Ә хәзер... Эшләр судта безнең: суд ничек хәл итә – шулай булыр. Тиздән китәсен белсәм дә, Алиягә: «Әйдә, фатирны минем исемгә күчерик әле», – дия ала идеммени?! Аны уйлый алдыммени мин ул чакта?! Кодагыйга гына аптырыйм: нигә бер акыллы киңәш бирми икән улына? Нигә бер тапкыр да миннән: «Хәлләрең ничек?» – дип сорамый икән? Ул да бит дүрт бала анасы...

Үзем рәнҗемәскә тырышсам да, җаным рәнҗи шул...



Илнар хәзрәт
ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым»
мәчете
имам-хатыйбы

САРАНЛЫК

Нәрсәне без саранлык дип атыйбыз?

Саранлык – юмартлыкның капма-каршы ягы. Кеше әйбер җыярга ярата һәм шул җыйганны югалтудан курку саранлыкка керә. Бу – шайтаннан. «Бирсәгез, үзегезгә калмый», – ди ул. Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә 99 урында: «Мин сезне баетырмын, мин юмарт», – ди. Бер генә урында: «Шайтан сезгә фәкыйрь булырсыз дип әйтә», – ди. Кеше Аллаһы Тәгаләнең 99 сүзен калдырып, шайтанның бер сүзенә ышана. Димәк, саранлык – Аллаһы Тәгаләнең сүзенә ышанмау дигән сүз. Пәйгамбәребез: «Сәдака малны киметми», – ди. Ничек инде, бер төргәк акчадан аз гына алсаң да, ул кими бит диярләр. Физика законы буенча шулай. Әмма кимеми! Чөнки физикада тагын бер закон – энергияне саклау законы бар. Йә син кемгәдер биргән мал башка җирдән әйләнеп кайта, йә калган малыңның бәрәкәте арта... Менә шуңа күрә дә Аллаһы Тәгалә: «Сез юмарт булсагыз, мин арттырып бирермен», – дип вәгъдә итә. Ә саран кеше моңа ышанмый. Менә ни өчен аларның хәлләре бик авыр. Начар кешеләрне сыйфатлаганда Аллаһы Тәгалә аларны саранлык белән сыйфатлый. Фәкыйрьләргә, мескеннәргә булышмау тәмугка керүгә бер сәбәп булып тора.

Саранлыкны дәвалап буламы?

– Иман белән дәваласаң гына... Моны Аллаһы Тәгалә үзе дә дәвалый. Саран кешенең малы үзеннән-үзе кими торган була. Аллаһы Тәгалә аны киметүнең сәбәпләрен чыгарып кына тора: йә нәрсәседер ватыла, йә штраф салалар, йә салым килеп төшә... Кеше аңларга тиеш: гел кәтмәгәндә чыгымнарга очрап торсаң, димәк, сәдака бирергә кирәк. Аллаһы Тәгалә шул очракта гына сынауларны киметә.

Саран кешегә иман, яхшылык, әҗер-савап турында күбрәк сөйләргә кирәк. Ул боларны аңламаса, дәвалау кыенрак. Ислам дәүләтендә зәкят бирергә теләмәгән кешедән аны тартып алалар – сорап тормыйлар. Бу аның өчен файда гына. Саранлык – бик авыр халәт, хәтта үлемгә дә китерергә мөмкин. Бер кеше бик күп ашаган һәм эче күпкән. Табиблар: «Ашказанын юдыртабыз», – дигәч, «Юк, күп акча түләп ашадым, әрәм итә алмыйм», – дигән. Һәм үлеп киткән. Үзеңә дару алырга акча жәлләп тә үлеп китәргә мөмкин.

Мөселман кешесе дә үзенчә саран. Ул да тупларга ярата, әмма дөнья малы җыю урынына әҗер-савап туплый. Җәннәттәге дәрәҗәгә омтыла.

Нәрсәдә саран булу иң зур гөнаһ санала?

– Иң зур гөнаһ – ул гыйбадәт кылмау. Әйе, бу да саранлык һәм иң зурысы. Син Аллаһы Тәгаләгә вакытыңны багышларга жәллисең. Ул моңа лаек була торып та. Аллаһы Тәгаләгә синең малың кирәкми. Телевизор карарга, театрга барырга, дуслар белән утырырга вакыт жәлләмисең, ә Аллаһы Тәгаләгә тәүлеккә бер сәгатеңне кызганасың. Күпләр: «Намазны пенсиягә чыккач укыйм», – диләр. Димәк, син яшьлегеңне дөнья матурлыгына багышлыйсың, Аллаһы Тәгалә өчен жәллисең. Ә беркемгә дә кирәк булмаган картлыгыңны аңа дип калдырасың... Кыямәт көнендә иң беренче итеп намаз турында сорарлар. Тәмугка эләгүчеләр дә: «Без намаз укымадык шул», – диярләр. Аллаһы Тәгалә безгә үзе биргәннең бик азын гына кире сорый: 24 сәгатьнең – 1 сәгатен, 12 айның – берсен, Рамазанны.

Пәйгамбәребез берсендә өйгә кайткач, хатыны Гайшәдән: «Бүген иртән калдырып киткән ит кисәген бирмәссеңме?» – дип сорый. Хатыны: «Мин аны бер теләнчегә биреп җибәрдем шул. Сиңа башка өлеше калды», – ди. Пәйгамбәребез: «Әнә шул биреп җибәргәне минем өлеш инде аның. Калганы, өйдәгесе минеке түгел. Сәдака итеп биргән өлешнең савабы ахирәткә күчте. Ул анда мине көтеп торачак», – ди. Кем беләндер бүлешкәне генә синеке! Моны аңлаган кеше бу дөньяда әйбер калдырырга тырышмый. Замана байлары, әйтик, нигә акчаларын чит илдә саклый? Чөнки алар киләчәктә шунда китәргә җыена. Мөселман кешесе дә шулай: бөтен активларын – байлыгын ахирәткә күчерергә тырыша. Аның өчен «офшора» – ул ахирәт. Барасы җиргә урынны алдан әзерләү акыллы гамәл шул. Шуңа күрә бу дөньяда байлыгы күп булган кеше – ул әле бай түгел, ә менә теге дөньяга күчереп өлгерсә – ул бай. Аннан, теге дөньяга күчергәндә байлыкның күләме дә мөһим түгел. Иң мөһиме – аның күпме өлешен күчерәсең. Мәсәлән, миллиардер бер миллион сәдака бирде ди. Малының меңнән бер өлеше була бу. Ә фәкыйрь кешенең 10 меңе бар һәм ул аның 1 меңең бирә. Алган кеше, әлбәттә, рәхмәтләрен миллиардерга яудыра. Әмма Аллаһы Тәгалә каршында фәкыйрьнең мең сумы зуррак, чөнки ул малының уннан бер өлешен бирде.

Тагын шунысы бар: Аллаһы Тәгалә кешенең изгелеген ала да аны үстерә башлый. Кеше ахирәткә күчкәч, аңа: «Менә синең савапларың», – диләр. «Мин моның кадәр кылмадым», – ди ул. «Ә синең кечкенә генә савапларың менә шулай үсте», – диләр аңа. Мөселман кешесенең бизнесы шундый.

Дөнья малы – дуңгыз каны, дип юкка гына әйтмиләр. Бүген аңа – син, ә иртәгә башка кеше хуҗа. Бер генә мисал. Биш тонна алтыныгыз бар ди. Тау кадәр байлык! Ул сезнеке – документы, бөтен кәгазе бар. Шуның өстендә утырып торасыз. Ә аннан бер көн килә – вафат буласыз. Сезне алтын тавы өстеннән төшерәләр дә, икенче көнне үк анда башка кеше менеп утыра... Дөньядагы байлыкка Аллаһы Тәгаләдән кала беркем дә хуҗа түгел.

PRESSA



«КЫЗ БИБИ» ЯКИ ҖӘННӘТ ӘНИЛӘРНЕҢ АЯК АСТЫНДА



Рәмзия КАШАПОВА

Дөньяда бик күптөрле илләр бар, ә мин менә Үзбәкстанны яратам! Ул һәрчак кунакчыл, шәһәрләре искиткеч гүзәл. Биредә йөрәккә ләззәт, җанга дәва аласың. Соңгы икмәкне һәм күңел җылысын үзбәкләр белән бергә бүлешеп, татарлар да күпләп яшәде биредә. Мин дә шуларның бер газиз баласымын: Ташкентта тудым. Минем дә монда туганнарым калды… Җай чыккан саен, Үзбәкстанга барырга тырышам. Бу юлы Кокандка исә Татарстан делегациясе составында зур Халыкара фестивальгә килдем.

Коканд цитаделе (аны «урда» яки Худояр хан сарае дип тә йөртәләр) – Кокандның тарихи истәлекле урыннарыннан берсе. Коканд ханлыгына 1709 елда, ягъни Фирганә үзәненең көнбатыш өлешендә Шейбанид Шахрух II ирекле биләмәләре барлыкка килгәч, нигез салына. Ул Кокандта ныгытма төзи, шәһәр ханлыкның мәркәзенә әйләнә. Чынлыкта Коканд – чагыштырмача шактый борынгы кала. X гасырдагы гарәп сәяхәтчеләре Истахри белән Иби-Хаукаль Шаш (Сырдәрья) һәм Асхы елгаларыннан билгеле бер ераклыкка урнашкан Хоканд шәһәрен телгә алалар. Хәзерге Кокандка бик туры килеп тора ул.

Шул заманнарда ук көчле дәүләт саналган. Аның җирләре Пакъстаннан Казакъстангача, Кыргызстанның таулы өлкәләреннән Әфганстан чикләренәчә сузылган. Һөнәрмәндләр фестивален Үзбәкстан Президенты Шәүкәт Мирзиёев катнашында Худояр Хан сарае фонында уздыру Коканд өчен генә түгел, бөтен Үзбәкстан өчен олы вакыйга булды. Ханлык тарихы белән кызыксыну уятты ул. Ә Татарстан павильонында традицион милли әйберләр генә түгел, заманча эшләр дә куелган иде.

Сүз уңаеннан, безнең делегациягә булган зур игътибары һәм булышлыгы өчен Үзбәкстанның Генераль консулы Насриев Фәриддин Бәдретдин улына аерым рәхмәт әйтәсе килә.

Катнашучыларның барысына да кунакханәләрдә урын җитәрлек булмау сәбәпле (ә без берәү-икәү генә түгел, җәмгысы сигез идек!), Кокандта безне шәхси секторга урнаштырдылар. Сөендек кенә бу хәлгә. Кокандлыларның гадәти тормышын кайчан якыннан күрер идек әле! Кайсыдыр илгә барып, аның тарихы, архитектурасы һәм мәдәнияте белән танышып, атаклы урыннарын карап, үз җаеңа гына ял итеп йөрү – бер нәрсә. Ә бит андагы халыкның көнкүреше һәм яшәү рәвеше җиде йозак астында кала гадәттә.

Рәшитнең ике катлы йорты – периметры 20 сутый зурлыгындагы колачы, 4 метрлы биек түшәмнәре, бөтен уңайлыклары белән хәйран калдырды.

Бу ханлык талантлы һөнәрмәндләре һәм рәхимсез ханнары белән дан алган.

Шәрыкта бөтенесенең дә ишегаллары төрле каралтылар белән уратып алынган, эчке ишегалдында бакчалар, фонтаннар, җәйге беседкалар урнашкан. Шәрык үзенең традицияләре белән көчле. Өйгә кунак килүне әллә каян, югарыдан иңдерелгән бүләк кебек кабул итәләр. Кунак белән бергә өйгә бәрәкәт иңә. Кичәләрнең берсендә Рәшит иң яхшы музыкантларны чакырып, бәйрәм табыны ясарга җыенуларын әйтте. Ничек бармый каласың инде! Җылы бер сентябрь кичендә без җәйге верандага җыелып, учакта пылау пешерү буенча мастер-класс алдык. Без кайтышка инде Рәшит дусларын гаиләләре белән һәм артистларны чакырып куйган иде. Үзбәк җырлары җаннарны иркәләде.

Рәшитләр гаиләсендәге дустанә мөнәсәбәтне, берберсенә карата ихтирамны, тәрбиялелекне, эшләрне үзара бүлешүләрен күреп сокландык. Иртүк кече кызлары, «Әссәламуәләйкүм» дип, балкып кереп, безне уята. Олы кызлары исә бу вакытта табын әзерләп, иртәнге чәйгә көтә. Үзбәкстанда егетләр кызларны үзләре сайламый, ә менә яучылар оештырган очрашуга барыргамы-бармаскамы икәнен егет үзе хәл итә. Үзбәкстанда күп гасырлардан килгән гадәт буенча киләшне кайнана сайлый һәм чын яучылар эзләп таба. Бәлки, шуңа да гаиләләр ныклыдыр анда. Димләп өйләнешү гадәте бүген дә яши Үзбәкстанда. Рәшит тә традицияләрне саклап өйләнгән, һәм менә 20 ел инде хатыны Марифат белән яратышып, килешеп яшиләр, дүрт бала үстерәләр.

Бәйрәм кызганда, Рәшит әнисе киләсен хәбәр итте. Аның тәшвишләнүе, ихтыярсыз, безгә дә күчте. Ишегалдына Замирә ханым килеп керүгә, бар дөнья яктырып киткәндәй булды. Иңенә ак яулыгын ябып,

Автор фотолары



■ Татарстан вәкилләре Рәшит йортында яшәде.



■ Рәшитнең әнисе Замирә ханым белән бергә дога кылдык.

Бу баруымда мин бөтенләй башка Үзбәкстанны ачтым.



Варахша шәһәрчеге.

балкып елмаеп, фәрештәгә тиң зифа сынлы сылу ханым килеп керде. ӘНИ килде! Замирә хон барчабыз белән күрешеп, тыйнак кына яныбызга утырды. Әмма бөтенебез – балалар, оныклар, киленнәр һәм без дә – әни кеше янында кайнаштык. Замирә хон озак еллар табиб-терапевт булып эшләгән, аннары медицина училищесын җитәкләгән. Быел ул Мәккәгә хаҗ кылырга барган.

Без эшмәкәр гаиләсендә яшәдек, әйләнә-тирә мохит тә шуны сиздереп тора иде. Ә менә Рәшитнең керемен бүлүне әнисе хәл иткәнен белгәч, бермәл аптырап калдым. Бөтенесе аңлаешлы, гади һәм гадел икән лә. Дүрт баланың, ун оныкның иң кадерле кешесе зур гаиләдә гармония һәм гаделлек сагында икән ләбаса. «Балаларның барысы да эшмәкәр булып китә алмый, әмма аңа карап алар нәрсәдәндер мәхрүм калырга тиеш түгел, алар да бит эшли, гаиләләре бар», – ди Замирә ханым. Ул оныкларына яхшы югары белем алырга булыша. Йорт салганда йә фатир алганда, эре әйберләр сатып алганда кыз һәм ир туганнар һәрчак әниләренең киңәшен тотып эш итә. Борынгы халыкның гореф-гадәтләре XXI гасырда да әнә шулай үз көчендә кала, һәм алар үзгәрергә ашыкмыйлар...

Үзбәк халкының традицияләре гасырлар гына түгел, мең еллар дәвамында формалашкан, шуңа күрә гаиләдәге, гомумән, социумдагы мөнәсәбәтләр башка халыкларныкыннан шактый аерыла. Безнең татар халкының да гасырлар буе сакланып килгән гореф-гадәтләре, йолалары бар, әлбәттә. Ләкин, кызганыч, күбесен югалта барабыз.

Кокандта узган Халыкара һөнәрмәндләр фестивалендә катнашу өчен Үзбәкстанга баруыбыз, Ташкентта Татарстан Республикасы көннәрендә хәзерге татар сәнгате күргәзмәсен тәкъдим итүебез зур җаваплылык та өстәде, әлбәттә. Бохара өлкәсендә урнашкан «Кыз Биби» мәдрәсәсенә һәм Варахша шәһәрчегенә баруны Казанда ук планлаштырып куйган идек. Әмма аның изге җомга көненә туры киләсен, җомга намазы алдыннан шунда барып керәсебезне күз алдына да китермәгән идек. Сәфәребез җиңелләрдән булды димәс идем.

Бохарадан Хива ягына 50 чакрым ераклыкта «Кыз Биби» дигән хатын-кызлар мәдрәсәсе бар. Үз күзләребез белән күрдек: бу гаҗәеп комплекс оазис белән очсыз-кырыйсыз чүл чигендә урнашкан икән. Тирә-ягындагы агачлар әкияттәге сыман: ботаклары һәм яфраклары таратып салынган хатын-кыз чәчен хәтерләтә. Әйләнә-тирә тып-тын. Әйтерсең без, күзгә күренмәс чикләрне узып, параллель дөньяга килеп кергәнбез. Комплекска аяк басканчы, тәһарәт алу бүлмәсенә уздык. Чүлдә утыруына карамастан, кайнар һәм салкын сулары бар, чиста – рәхәт булып китте. «Кыз Биби» мәдрәсәсенә юнәлдек.



«Кыз Биби»дә Мәстүрә мавзолее.

Комплекстан ерак түгел иске зират урнашкан. Анда-санда агачлар, куаклар күренгәли. Хатын-кыз чәчен хәтерләткән яфраклар җиңелчә шыбырдаша. Әйтерсең пышылдашалар...

Мәчетле комплексны вәзир Мир-Араба Садикхон суфичы хатын-кыз Мәстүрә ханым хөрмәтенә төзеткән. Биредәге халык, аның җаны бүген дә мәдрәсә диварларында, һәм ул безне саклый дип инана. Бәлки, хактыр да. Бусагадан атлап керүгә үк ниндидер тыныч халәткә күчтек.



■ Кызыл бүлмәдәге фреска фрагменты. Варахша шәһәрчеге.



Мәстүрә төрбәсенә керү белән Коръән сүрәләрен укыдык, фәлсәфәгә бирелеп, бераз уйланып утырдык. Китәсе килмәде. Үзбәкләр бөтенесен мең ел элек булганча саклый алган. Әнисен илаһилаштырып олылаучы шул ук Рәшит тә, башкалар да. Мин беләм: бар тырышлыгыңны куеп, тир түгеп тапкан акчаның һәр тиене югары бәяләнә.

Риваятьләр буенча, Кыз Бибине яратмаган кешесенә көчләп кияүгә бирмәкче булалар, ә ул чүлгә качып китә һәм озак еллар берьялгызы шунда гомер кичерә. Билгеле бер вакыттан соң аның савыктыру сәләте ачыла, һәм ул бала таба алмаган хатын-кызларны дәвалый башлый. Арабызда өзелеп бала көтүчеләр дә бар иде, изге теләкләре тормышка ашсын дип без дә дога кылдык. «Кыз Биби»гә андый хатын-кызлар күпләп килә икән. Өч көн ураза тотса, авырулары да юкка чыга, ди. Әлеге комплекста ирләргә Кыз Биби төрбәсенә керү тыела.

Варахша үзенең колачы, зурлыгы белән истә калыр, без аны карап та бетерә алмадык. Зур мәйдан, рәхимсез кояш, аннары бер җирдән икенчесенә күчеп йөрү дә өстәмә кыенлыклар тудырды. Алай да төп сарай өлешендә иркенләп йөрдек. Варахша – кайчандыр Бохара худатлары резиденциясе булган борынгы торак җир санала. Аңа Бохарадан да алданрак нигез салына, һәм зурлыгы буенча да аннан калышмый ул. Көнбатыш чикләрдә халыкның тынычлыгын саклаучы әһәмиятле хәрби застава буларак та билгеле. Бохарага гарәпләр һөҗүм иткәндә шактый сугышларны кичергән шәһәр. Өстәвенә, Хорезм белән Бохара арасындагы бик мөһим сәүдә үзәге. Анда һөнәрчелек алга киткән була, казу эшләре барышында һөнәрчеләр кварталлары табылу шул хакта сөйли. Ул заманнардан соң шактый вакыт узган булса да, теләсә кайда чүлмәк ватыклары аунап ята. Тирәнрәк казысаң, яндырылган кызыл балчык төсендәге рәсемнәр төшерелгән керамик савыт ватыкларына, тоткаларга юлыгасың. Археологлар өчен савыт китекләреннән битәр, аның саплары, төрле капкачлар зур табыш исәпләнә. Чөнки шулар аша автор тамгасы эзләрен, шул чор турында сөйләүче башка әйберләрне табарга мөмкин. Биредә сарай да булган. Бөек рәссамнар һәм осталар иҗат иткән матур паннолар кайчандыр сарай залларын бизәгән, хәзер алар барысы да Эрмитажда саклана.

Ташкентта тусам да, күп нәрсәне бөтенләй күрмәгәнмен, белмәгәнмен. Совет чорында дин бик популяр булмаганда күп изге урыннар хәрабәләр һәм калын ком катламы астында калып, кирәксез булып яткан. «Кыз Биби»не дә туристлар арасында популяр дип әйтмәс идем. Әмма уйларыгыз белән ялгыз гына калып, күңел түрендә йөрткән серегезне бушатасыгыз килсә, бирегә килсәң ярый.

Бу язманы әзерләгәндә Коканд ханлыгы тарихын җентекләп өйрәндем. Алай гынамы, инде күптән вафат ирем Фәтхулланың шушы бөек нәселдән икәнен дә белдем. Соңгы Коканд ханының уллары фотосын ачсам... Миңа яшь-яшь Фәтхулла карап тора! Борынгы киемнәрдән, әлбәттә. Җаннар күчә дигән сүзләргә ышанмас җирдән ышанырсың шул...

PRESSA

«СИНЕҢ КҮЗЛӘР ЧУЛМАН КЕБЕК...»



Ленар ШӘЕХ, шагыйрь, тәрҗемәче, М. Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты. гаилә стажы – 12 ел; ике бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Иң беренче чиратта Айсылуның күзләре игътибарымны җәлеп итте... Аларда үткенлек, чаялык, тынгысызлык та чагыла иде. Шулай ук буй-сын да күз уңыннан читтә калмый. Дөньяда бер җан ярала икән, аңа насыйп хәләл яры да туа, диләр. Алар берсен-берсе эзләп табарга тиешләр. Без аны «җан тартуы» дип атыйбыз, тышкы кыяфәт, кешенең үз-үзен тотышы, холкы бу тарту көчен арттыра гына.

Кояш кунган күзләреңә
Тутырып бер карыйм әле.
Яшәү моңы дәрьясыннан
Җаныма тын алыйм әле.

Синең күзләр Чулман кебек –
Иксез-чиксез, тирән-тирән.
Алсу таңнар яктысында
Бәхетемә якын киләм...

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Бергә яшәгәч, бер-береңә тулысынча ышангач, озак вакытлар буе үпкәләп яту, гомумән, кирәк әйбер түгел. Ничек үпкәләшәсең, шулай татулашасың...

Үпкәләттем сине юкка,
Уйламый-нитми генә.
Күкне сарган кара болыт
Таралмый-китми генә.

Яңгыр ява шыбыр-шыбыр,
Әллә синме еладың?..
Күзләреңне мөлдерәтеп,
Сынадың да сынадың...

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Иманлы хатын-кыз да, иманлы ир-ат та гафу итмәслек гамәлләр кылмас дип уйлыйм.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Икенчесе якынрак. Уңган хуҗабикә үзеннән-үзе илһамландыручы алиһәгә әйләнеп китә бит инде ул. Әгәр өйдә җылылык, бер-береңә игътибар булмаса, алиһә булып күренгәннәр дә тиз арада икенче төрле кабул ителә башлыйдыр. Ир-атлар күп нәрсәне тышка чыгарып күрсәтми, эчтән генә уйлана, сызлана, сөенә... Барыбер хиссез бит ул, дип ир-атка игътибар кимесә, нәтиҗә сөендерерлек булмаячак. Һавада очып йөргән һәм бары тик үз-үзен генә яраткан алиһә янындагы тормышка түзәргә кемнең генә сабырлыгы җитәр икән? Минемчә, бер атнадан да артмас андый сабырлык.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Әлбәттә. Озак еллар бергә яшәгәч, хатын-кыз сөйгән яр да, дус та, хәтта туган да булып китә... Гашыйк булган мизгелдән үк хатын-кыз дус була алмый диясем килми. Ләкин әле бергә яши башлаганда бер-береңне ачканчы яңа хисләр сыналмаган була. Авыр вакытларда бер-берсенә ярдәм күрсәтеп, сынаулар узгач кына барлыкка киләдер ул дуслык хисе.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетында укыганда булды ул вакыйга. Хатыным – дүртенче, мин бишенче курста идем. Тулай торакта яшәгән чак... Кулларымда – чәчәкләр бәйләме һәм пар аккошлы тартмачыкта – көмеш алкалар... Сүзләремне әйткәндә дулкынландым, бик озак әйтелде кебек тәкъдим ясау җөмләсе. Июнь аеның матур бер көнендә никах укыттык, икенче көнне мин диплом алдым.

Мәхәббәтең – йомшак җилкәй,
Тулган ай күк күзләрең.
Елмаюың – май кояшы,
Таң җырлары – сүзләрең.

Хыялларың әкияти,
Ак кардай синең күңел.
Адымнарың шундый җиңел –
Туктатырлык та түгел.

Корабка җилкән булырмын,
Коштай күккә менәрмен.
Теләсәң, җаным бирермен,
Синең өчен сүнәрмен.

Мин сихри таяк булырмын,
Судагы алтын балык.
Очарга да өйрәнермен,
Сине кулыңнан алып.

Елга булып агармын мин,
Ярларымнан ташармын.
Әгәр син янымда булсаң,
Җиде күккә ашармын.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Халык әйтсә, хак әйтә. Әнием белән хатыным арасында уртаклыкларны мин дә күрәм. Дөрес, үзенә яр сайлаганда бер ир-ат та әниемә охшаган кызга өйләнәм дип уйламыйдыр. Бу ничектер үзеннән-үзе шулай килеп чыга.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Мәхәббәт мал белән үлчәнми. Дөрес, бу очракта матриархат килеп чыга инде. Ир кеше үз-үзен раслап яшәргә өйрәнгән бит инде ул. Борынгы һәм урта гасырларда хатын-кыз, гомумән, мал тапмаган, ә гаилә учагын саклап, балаларны тәрбияләп, исәпсез-хисапсыз өй эшләре белән мәшгуль булган. Яшерен-батырын түгел, бала тәрбияләүнең күп өлеше, хәтта төп өлеше әниләр җилкәсенә төшә. Бу табигый да. Балага беренче чиратта әнисе кирәк. Шуңа акча артыннан куып, үзенең төп миссиясен оныткан хатын-кызларны аңлый алмыйм. Борынгы гасырларда ирләр белән бергә сөңге тотып, ауга йөргән хатын-кызны күз алдына китереп буламы?.. Әйе, кеше буларак без тигез, ләкин физиологик һәм рухи яктан – төрле, шуңа вазыйфаларыбыз да аерыла.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Минемчә, хатын-кыз тыйнак булырга һәм бу мәсьәләдә иң беренче сүзне ир-ат әйтергә тиеш дип саныйм. Әмма ир-атлар кыюсызрак яки озак уйлый торган булса, үзләре үк беренче адым ясаган хатын-кызларны тәнкыйтьләү мөмкин түгел.

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Акыл, килеш-килбәт, ихласлык.

11 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Гаиләле кеше чит-ят хатын-кыздан бернинди дә игътибар көтми инде ул... Гомумән, мин үземә артык игътибар иткәнне яратмыйм. Мактый башласалар, үземне кая куярга да белмим. Бу яктан әниемнең әтисе Нәҗип бабама охшаганмын.

12 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Иманлы кеше Аллаһы Тәгаләдән генә куркырга тиеш дип уйлыйм.

13 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Андый очраклар булганы юк. Кайбер очракта хатыным белән бәхәс чыга, ләкин күпмедер вакыт үткәч, шул ачыклана: йә ул, йә мин дөрес фикердә булганбыз икән. Күбрәк, мөгаен, улдыр... Димәк, хатын-кыз акыллырак, сабыррак булырга тиеш дигән сүз бу. Гаиләдә икең бер фикердә, бер уйда, бер юлда булып яшәргә кирәк.

14 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез? Үзегезнең хаклы булуыгызны исбатларга тырышып карыйсызмы әллә инде юл куясызмы?

– Бәхәсне моментында хәл итеп булмый. Кемдер юл куярга тиеш. Кайсы якның дөрес икәнен вакыт күрсәтә. Син – хатының булып, йә ул синең урында булып уйлап карау кирәктер. Гомумән, хаклык бәхәстә туа бит инде.

15 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым дип, диванда кырын ятып тора. Сез нишлисез инде? Кафега чыгып китәсез яки пиццага заказ бирәсез? Тиз генә үзегез берәр нәрсә пешерәсез?

– Һичьюгы, бәрәңге булса да пешерәм инде. Читтә пешкән ризык өйдә әзерләнгәне белән берничек тә чагыша алмый.

16 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар соңга калучан. Бу сезнең ачуны китерәме? Китерә икән, бу хәл белән ничек көрәшәсез?

– Баштарак борчыла идем, ләкин шунысы бар: мин үзем дә җитез кеше түгел. Кайда да булса барасы булса, алданрак җыена башлыйбыз.

17 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?

– Энә дә бүләк, дөя дә бүләк бит, иң мөһиме – игътибар. Барысы да ошый. Кайчакта хәтта бер елмаю да җитә.

Кызыл алма кулларыңда –
Кайнар кояш шикелле.
Шул алмаңны миңа суздың –
Йөрәк шашты, сикерде.

Битләрең дә алма кебек –
Тулып пешкән, кызарган.
Күңелеңә язлар килгән,
Бозлы кыллар кузгалган.



Ютәл генә димәгез

Көзге-кышкы айлар – иммунитетның чын-чынлап сыналу чоры. Салкын һәм дымлы һава, аяк-кулларның туңуы аркасында балага бик еш салкын тия, тамагы шешә, томаулый. Әле моңа тагын вируслар, инфекцияләр дә килеп өстәлсә, бронхитка да озак түгел. Мәктәпкәчә яшьтәге сабыйлар арасында иң күп таралган чирләрнең берсе ул. Республика балалар клиник хастаханәсенең пульмонология бүлеге мөдире, балалар табибы – пульмонолог Илдар ЗИННӘТУЛЛИН белән балаларның тын юллары ялкынсыну – бронхит һәм аны кисәтү ысуллары турында сөйләшәбез.

Бронхит, әйткәнебезчә, тын юллары – бронхларның ялкынсынуы ул. Күп очракта аны вируслар – грипп, парагрипп, аденовирус һәм бактерияләр – пневмококк, гемофиль таякчыгы, стрептококклар китереп чыгара. Кайчак баланың бронхит белән чирләвенә өйдәге күгәрек гөмбәсе, аллергеннар белән контактта булу, токсиннар да гаепле.

Бала бу чирне күбесенчә һава аша йоктыра. Клиник билгеләргә нигезләнеп, диагнозны табиб куя. Бронхитны ачыклау катлаулы түгел, рентген тикшерүе таләп ителми. Ләкин кайчак үпкәдән тавыш килгәндә, табиб рентген да билгеләргә мөмкин. Анысы чирнең үпкәләргә күчү-күчмәвен белү өчен кирәк.

Бронхитның төп билгеләре – дәвамлы ютәл. Башта ютәл коры була, дәвалагач, какырык куба, юеш ютәлгә әйләнә. Салкын тию, ОРВИ катлауланудан да балада бронхит башланырга мөмкин. Югары температура, хәлсезлек, аппетит булмау – әлеге чирнең гомуми билгеләре. Балаларда гына күзәтелүче кискен обструктив бронхит булганда тын бетү, сулаганда тын юлларының гыжлавы кебек билгеләр дә була. Әлеге тавыш гади колакка да ишетелеп тора, баланың хәле авырая, ул еш-еш сулый, организмында интоксикация башлана. Бронхитның кискен гади һәм обструктив төрләре белән 5 яшькә кадәрге сабыйлар ешрак авырый. Бу аларның иммунитеты ныгып җитмәү белән аңлатыла бу. Баланың ютәле өч айдан артыкка сузылып, ел саен даими кабатланып торса, бу очракта инде чир дәвамлы формага күчкән була.

Бронхит – дәвалауга җиңел бирешә торган чир. Дәва чараларының берьюлы берничәсе билгеләнә. Физиологик раствор яки табиб билгеләгән дару белән небулайзер ярдәмендә ингаляцияләр ясау, ютәлне баса торган дарулар һәм кайчагында хәлнең катлаулыгына карап, антибиотиклар да билгеләнә. Дәвамлы бронхит вакытында антибиотиклар кулланмый булмый. Әмма бу даруларны фәкать табиб кына билгеләргә тиеш, үзбелдекләнеп дәвалау чирне катлауландырырга гына мөмкин.

Баланың тын юлларын какырыктан арындыру өчен сулыш гимнастикасы һәм җиңелчә массаж да әйбәт. Сулыш гимнастикасы сыйфатында балага һава шарын кабарту яки шәмне өреп сүндерү кебек гади генә уен элементларын тәкъдим итәргә була.

Бронхит – сабый балаларның сәламәтлегенә куркыныч тудыручы чир. Шуңа да баланың ютәленә, үзе үтәр, дип карарга кирәкми, кичекмәстән табибка күренергә кирәк. Вакытында дәваламасаң, аның үпкә ялкынсынуына китерүе ихтимал. Анысы инде күпкә катлаулырак.

Табиб киңәш итә:

- Бронхит белән авыручы балага суны күбрәк эчерергә кирәк. Сыеклык организмдагы токсиннарны юдырып чыгара. Обструктив бронхит вакытында бала еш-еш сулый һәм организмдагы сыеклык үпкәләрнең эшчәнлеге өчен күбрәк тотыла. Су урынына гөлҗимеш кайнатмасы, соклар, сөт бирергә мөмкин, әмма алар җылы булсын.
- Бала чирне аяк өсте генә кичерергә тиеш түгел. Әмма аны гел яткырып кына торырга да ярамый, югыйсә үпкәләргә сыеклык җыелырга мөмкин. Күкрәк баласын ешрак әйләндерергә һәм кулга да ешрак алырга кирәк.
- Авыру бала яткан бүлмәнең температурасына игътибарлы булыгыз. Артык коры һәм эссе һава зыянлы. Иң яхшысы – температураның 18–22 градус чамасы булуы.
- Бала бактериаль бронхит белән авырган вакытта аны кайнар мунчага яки душка керту тыела. Шулай ук кайнар пар сулату да хәлне катлауландырырга мөмкин.



Буыннар нигә сызлый?

Бу чирне күпләр картлык авыруы дип уйлый. Ялгышалар. Артрит япь-яшь кешеләрдә, хәтта яшүсмерләрдә дә очрый. Республика клиник хастаханәсе консультатив поликлиникасының ревматология үзәге мөдире Игорь СЕРДЮК белән артритның килеп чыгу сәбәпләре һәм буыннарны дәвалау турында сөйләшәбез.

Кул-аякларыбызның буыннары безгә ни өчен бирелгәнен барыбыз да беләбез – хәрәкәтләнер өчен. Көннәрдән бер көнне буыннар бөгелми башласа, сызласа, яшәүнең бөтен яме югала. Буын чирләре арасында иң таралганы – артрит һәм артроз. Ревматоидлы артритны күпләр ревматизм чире белән бутый. Ревматизм балаларда һәм яшүсмерләрдә генә була һәм күп очракта йөрәк мускулларын зарарлый. Ә ревматоидлы артрит – артроздан аермалы буларак, буыннарның ялкынсынуы ул.
Дәвамлы артритның нилектән килеп чыгуы тулысынча билгеле түгел. Алай да өч сәбәпне атарга була: нәселдәнлек, стресс һәм көчле инфекция. Табиблык тәҗрибәмдә бик көчле стресстан соң буыннары сызлаган кешеләрне күп очратырга туры килде. Стресс вакытында организм бөтен көчен бергә туплый, бөер өсте бизләре канга күп күләмдә гормон эшләп чыгара. Әлеге халәт озакка китсә, организм хәлсезләнә, иммун күзәнәкләрнең эшчәнлеге бозылып, алар организмның үз күзәнәкләренә каршы көрәш ача.
Грипп, ангина кебек йогышлы чирләр белән авырганнан соң да ревматоидлы артрит башланырга мөмкин. Кайчак буыннарның сызлавында хламидия инфекциясе гаепле була. Бу очракта реактив артрит күзәтелә. Ревматоидлы артрит башта кул буыннарын, аннары аяк буыннарын зарарласа, реактив артрит башта – аякларны, аннары кулларны зарарлый.
Үз гомерендә бер тапкыр булса да буын авыртуының нәрсә икәнен белмәгән кеше сирәктер. Буыннар авыр физик эш эшләгәннән дә авырта. Һичшиксез табибка күренергә кирәген ничек ачыкларга? Көне буе бәрәңге казып, кичкә аяклар сызласа – бу нормаль күренеш. Буыннарга көч килгән, ял иткәч, сызлану үтәргә тиеш. Әгәр буыннардагы авырту өч атнадан артыкка сузыла икән, димәк, сәбәп физик нагрузкада гына түгел. Кайчак буыннар тик торганда да бик каты сызлый. Торып йөри башлагач, авыртуы бераз басылган кебек була. Монысы – буыннарда ялкынсыну процессы баруын күрсәтүче билге.
Дөрес диагнозны бары табиб кына куя ала. Ул башта һәр буынны җентекләп тикшерә. Кан анализы да бирергә кирәк булачак. Пациентның кул буыннары авыртмый, сызлау аякларда гына булса, хламидия инфекциясе булу-булмавын ачыклау өчен мазок тапшырыла. Анализ нәтиҗәләреннән чыгып, дәва билгеләнә.
Ул өч төп чарага корылган булырга тиеш. Аларның беренчесе – сызлауны басучы препаратлар. Икенчесе – ялкынсынуны басучы базис чаралар. Өченчесе – дәвалау гимнастикасы. Дәвалау гимнастикасыннан башка гына даруларның нәтиҗәлелеге тиешенчә була алмый. Ялкынсыну кимегәннән соң, хәрәкәт булмаса, сеңерләр тартылып, буыннар катып калачак. Менә шуның өчен дә гимнастикага кирәксез әйбер итеп карамагыз.
Дару препаратлары курслап билгеләнә. Ләкин бу курслар шактый дәвамлы һәм аны кешегә еллар буе, кайчак хәтта гомер буе да эчәргә туры килә.
Шулай ук дәва чарасы буларак, массаж, физиодәва, аппликацияләрне дә әйтергә була. Күпләр буыннарны җылыту, балчык ванналары ясау файдалы ди. Көчле ялкынсыну вакытында боларны эшләргә ярамый.
Кызганыч, ревматоидлы артриттан тулысынча дәвалый торган препаратлар әлегә уйлап табылмаган. Чирне дәвалауга караганда, кисәтүе уңайлырак булуын истән чыгармагыз.

Моны белү мөһим:

- Буыннарның сәламәтлеген саклау өчен иң беренче чиратта организмны инфекцияләрдән дәваларга кирәк. Ангина, грипп, пиелонефрит кебек чирләрне кисәтү берүк вакытта артритны да кисәтү.
- Ревматоидлы артритны дәвалаганда остеопорозга каршы профилактика ясау мөһим. Моның өчен рационга кальцийга бай ризыкларны күбрәк кертергә кирәк.
- Ревматоидлы артрит – даими табиб күзәтүен таләп итүче чир.



Хуплу

Беренче кар төшеп, йорт тирәсендә эшләр кимегәч, чуаш халкы бәйрәм итә башлый: дуслар, туганнар бер-берсенә кунакка йөри, җырлар җырлый, күңел ача. Менә шундый бәйрәмнәргә чуаш халкының уңган хуҗабикәләре төрле тәм-том, милли ризыкларын әзерләргә ярата.
Вера ЮНУСОВА – Татарстандагы Чуаш милли автономиясе җитәкчесе урынбасары. Ул – Аксубай ягыннан, бүгенге көндә зур матур гаиләсе белән Биектауда яши. Җаваплы хезмәткәр, чуаш җырларын башкаручы, төрле милли бәйрәмнәр оештыручы ханым гына түгел, ул әле бик уңган хуҗабикә дә. Күрешкәч тә, аның матур итеп саф татарча сөйләменә сокландык. Вера ханым чуаш халкының камырдан пешерелә торган милли ризыгы ХУПЛУ әзерләп күрсәтте.
– Хуплуны безнең халык элек-электән иттән һәм ярмалардан пешергән. Бәрәңге кулланылышка кергәч, хуплуга ярма белән бергә бәрәңге дә куша башлаганнар. Гади халык итле ризыкны бәйрәмнәрдә генә ашаган, шуңа күрә хуплу бәйрәмнәрнең затлы ризыгы булып саналган, – ди хуҗабикә.
Вера ханымның өендә нәселдәге кызларның килен булып төшкәч өй түренә элгән чигүле сөлгеләре, элеккеге милли кием-салымнар кадерләп саклана. Ул үзе дә борынгы гадәт-йолаларны үтәп, гаилә традицияләренә тугры калып яши. «Хуплуны без кунаклар җыелганда, милли бәйрәмнәрдә, балага исем кушканда пешерәбез. Туган көннәргә барганда күчтәнәчкә дә алабыз. Мин әле әбиемнең дә чиккән сөлгеләргә төреп хуплу пешергәнен хәтерлим. Инде хәзер әбинең хуплу пешергән табасы миндә саклана, бу ризыкны шул табада гына әзерлим. Без аны ялтыратып юмыйбыз да, кырып чистартмыйбыз да. Өйгә кергән һәркем аның хуплу табасы икәнен аңлый. Без инде ничә өй алыштырдык, әмма хуплу табасын һәрвакыт үзем белән йөртәм, бик кадерле ул миңа!» – ди Вера ханым.



Кирәк
(7-8 кеше өчен)

Камыр өчен:
- 2 йомырка;
- 3 аш кашыгы көнбагыш мае;
- 1 стакан сөт;
- 1 аш кашыгы тирәсе сода, тоз.

Эчлек өчен:
- 2 кг бәрәңге;
- 1 кг ит (артык майлы булмаса, терлекнең эч маен кушабыз);
- 1 стакан тары ярмасы;
- 3 баш суган;
- тоз, борыч.



Фото: Анна Арахамия

Эш барышы:

- Сода, тоз, йомырканы салып әйбәтләп болгатабыз.

- Сөт, май салабыз.

- Он салып, әйбәтләп камыр басабыз.

- Камыр әзер булгач, эчлеккә тотынабыз: шакмаклап ит, бәрәңге турыйбыз, тәмләткечләр кушабыз, бәлештә исе чыкмасын өчен суганны майда бераз кыздырып салабыз.

- Табага җәелгән камыр өстенә иң беренче эш итеп юылган тарыны салып тигезлибез. Артык майны үзенә сеңдерсен, аз гына хуш ис чыгарып торсын өчен хуплуга тары да кирәк (бәлеш пешкәч, эчлеккә тары салынганы сизелми).

- Тары өстенә алдан әзерләнгән эчлекне салабыз.

- Камырның икенче өлешен юка итеп кенә җәеп, хуплуның өстен томалыйбыз.

- Гаиләгә багышлап матур теләкләр әйтә-әйтә, хуплуның кырыйларын матур итеп бөрәбез.

- Бер йомырка сарысына аз гына су салып, болгатабыз да, мичкә куяр алдыннан шуның белән хуплуның өстен майлап алабыз.

- Сүрән утта 2,5 сәгать пешерәбез.

- Хуплу әзер булгач, аны кунакларга өйдәге иң хөрмәтле кеше кисеп таратырга тиеш. Юнусовлар гаиләсендә хуш исләр аңкып торган хуплуны һәрвакыт Вера ханым үзенең тормыш иптәше Альберт әфәнде белән бергәләп кисеп, балаларына, кунакларга дигән өлешне матур тәлинкәләргә бүлеп чыгалар. Хуплу әле ул түгәрәк бәхет, гаилә иминлеге билгесе дә булып тора.

Мастер-классны оештыруда ярдәм иткәннәре өчен Татарстан халыкларының Дуслык йортына рәхмәт белдерәбез.





Моңа кадәр рационыгызда витграсс булмаган булса, кичекмәстән кертегез сез аны. Гади генә итеп әйтсәк, витграсс – бодай уҗымыннан әзерләнгән эчемлек ул. Дөрес туклану сәхифәсен даими әзерләүче Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА бу юлы безгә аның файдалы үзлекләрен ачар һәм әзерләү серләрен өйрәтер. Әлеге эчемлектә 70 процентка якын хлорофилл бар, ә ул организмны авыр металлардан чистарту процессында катнаша һәм гемоглобинны күтәрә.
Ике аш кашыгы витграсстагы файдалы матдәләр күләме 1,5 кг тазә яшелчәнекенә бәрабәр. Ул тимергә, бакыр, кальцийга бай, составында аминокислоталар, антиоксидантлар, E, B_1, B_2, B_3, B_6 витаминнары булуы белән кыйммәтле.

Витграсс – сәламәтлек эликсиры

БОДАЙ УҖЫМЫНЫҢ СОГЫ:
- начар холестеринны киметә;
- кандагы шикәр күләмен көйли;
- какшаган иммунитетны ныгыта;
- ялкынсынуларга каршы тора;
- дөрес туклану рәвешен саклаганда артык авырлыктан арынырга булыша;
- тукымаларның яңаруын тизләтә;
- организмны токсиннардан һәм шлаклардан чистарта;
- калкансыман бизнең эшчәнлеген яхшырта

Әлеге могҗизалы эчемлекне ничек ясаргамы? Беренче карашка аны әзерләү озак сыман тоелырга мөмкин, ләкин без ул эчемлекне берничә атналык итеп әзерлибез. Моның өчен башта тарттырылмаган бодай сатып алып, аны үрдерергә кирәк. Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм, минем бу беренче тапкырдан килеп чыкмады. Бодай күгәрде дә яраксызга әйләнде. Ничектер, берсендә интернетта бодай үрдерүнең бик кызыклы бер ысулын очраттым. Ул нәкъ менә бу эштә әлегә тәҗрибәсе булмаганнар өчен ярашлы. Зоокибеттән песиләр өчен рәшәткәле лоток сатып алабыз. Лотокны алганда игътибар итегез: өчпочмак эчендә «5» саны язылган булсын. Бу – аның азык-төлек өчен яраклы пластиктан ясалуын белдерә.

Бодайны юып (бер лотокка 150 г бодай), өстенә чиста су агызабыз. 5-6 сәгатьтән бодай бүртә. Лотокның рәшәткәсенә марля яки бәз җәеп, бераз туфрак салабыз. Пульверизатордан су бөркеп, җирне юешлибез һәм бүрткән бодайны тигезләп тезеп чыгабыз. (Туфракның сыйфатлысын сайлагыз, бодай андагы минералларны үзенә ала.) Туфрак урынына юеш салфетка кулланып, бодайны салфетка өстендә дә үрдерергә мөмкин.

Лотокның өстен 2-3 көн – бодай тишелеп чыкканчы – полиэтилен элпә белән каплап торабыз. Көнгә берничә тапкыр ачып, пульверизатордан су бөркү мәҗбүри. Күгәрер дип курыксагыз, суга бер чәй кашыгы тозлы кәбестә суы өсти аласыз.

2-3 тәүлектән бодай уҗымы баш калкыта башлый. Хәзер аның өстендәге элпәне алып, савытны тәрәзә төбенә куярга кирәк. Тагын 5-6 көннән уҗымны кыркып, согын да ясарга була.

Сок ясар өчен шнеклы соксыккыч яки иттарткыч кирәк. Иттарткыч кулланган очракта, тарттырылган уҗым марля аша сөзелә. Әзер сокны боз өчен тәгаенләнгән формаларга салып, туңдыргычта алты айга кадәр сакларга мөмкин.

Фото: www.pixabay.com

НИЧЕК КУЛЛАНЫРГА?

Һәр иртәне берәр шакмак туңдырылган сок кулланудан башлагыз. Аны бер стакан лимонлы суга да салып эчәргә була. Организм ияләнгәч, көненә 2-3 шакмакка кадәр арттырыгыз. Бу бик көчле чара, моңарчы организмыгызны чистартмаган булсагыз, беренче көннәрдә дискомфорт та сизелергә мөмкин. Сәламәт булыгыз!

Кучкар. Күптәннән күңелегездә йөрткән хыялыгыз чынга ашар. Эшегездә уңышка ирешерсез! Хыялларга бирелеп, сәламәтлегегез турында онытмагыз. Ай ахырында финанс проблемалары килеп чыкмасын өчен акчаны саклап тоту мәслихәт.

Үгезбозау. Романтик очрашулар көтелсә дә, башыгызны югалтып гашыйк булу кирәкмәс. Вак-төякләргә игътибарлы булыгыз. Уңышлы бара торган эшегез тукталмасын дисәгез, низагларга кермәгез.

Игезәкләр. Күңелле сәяхәт көтәчәк. Күрергә теләгән дустыгызны очратырсыз. Туганнарыгыз белән дә мөнәсәбәтләрегез әйбәт. Балаларыгызның уку мәшәкатьләре килеп чыгар, булышып җибәрегез!

Кысла. Торак белән бәйле катлаулы проблема чишелер. Яңа эш урыны тәкъдим итәрләр. Тик эшегезне алыштырырга ашыкмагыз, гаиләгез белән киңәшләшегез. Айның икенче яртысында мәхәббәт өлкәсендә киеренке чор башлануы бар.

Арыслан. Шәхси тормышыгызда үзгәрешләр көтелә. Финанс хәлегезне яхшырта торган өстәмә эш табуыгыз бар. Машинагызны алыштырырга ашыкмагыз, андый зур адым ясар өчен уңышлы ай түгел.

Сөмбелә. Яңа танышулардан баш тартмагыз, алар арасында тормышыгызны уңай якка үзгәртергә ярдәм итүче кирәкле кеше дә булачак. Бу айда чит телләр өйрәнә башласагыз, киләчәктә файдасын күрерсез. Ай ахырында хәлиткеч карарлар кабул итәргә ашыкмагыз.

Бизмән. Ноябрь сезнең өчен мәхәббәт һәм иҗат өлкәсендә уңышлы чор. Ай башында романтик очрашулар, мәхәббәт маҗаралары көтелә. Тормышыгызны сизелерлек үзгәртәсегез килсә, вакыйгаларны ашыктырмагыз.

Чаян. Буш вакытыгызны гаиләгез белән үткәрегез. Алар сездән игътибар көтә. Сөйгәнегезгә көтелмәгән сюрприз ясап, мөнәсәбәтләрегез ныгыр. Зур әйберләр сатып алырсыз. Көндәлек мәшәкатьләрне хәл итү, ремонт ясау өчен яхшы вакыт.

У***кчы.*** Үз-үзегезгә ышанычны югалтмыйча башлаган эшегезне ахырынача җиткерсәгез – зур күләмдә керем алырсыз. Бу айга планлаштырган сәяхәтегезне кичектереп торсагыз әйбәтрәк булыр.

Кәҗәмөгез. Дөньяга карашны үзгәртер өчен уңай вакыт килеп җитте. Алдыгызга куелган максатларны чынга ашырыр өчен яңа юллар ачылыр. Бу айда бурычка акча алмагыз һәм биреп тә тормагыз.

Сукояр. Иҗади эзләнүләр, яңа идеяләр чоры. Җанга рәхәт хисләргә төренерсез. Тормыш иптәшегезгә башка күзлектән карарга өйрәнегез. Уҗәт булсагыз, тормышыгызны үзегез теләгән якка бора алырсыз.

Балык. Спорт белән шөгыльләнегез. Тормышта авырлыкны җиңәр көч табарсыз, читтән дә ярдәм килеп торыр, курыкмыйча дусларыгызга, туганнарыгызга таяна алырсыз.

зирәк кешедән нәсыйхәт сүз

ЯХШЫ ҺӘМ НАЧАР СЫЙФАТЛАР ТУРЫНДА

Бервакыт укучылар зирәк карт янына килеп шундый сорау бирәләр:

– Күпне күргән, белгән кеше буларак җавап бирегезче: ни өчен начар сыйфатлар кешене бик тиз биләп ала, ә яхшы сыйфатларны гадәт итеп алу бик авыр бирелә?

– Әгәр дә ашлык бөртекләренең иң уңдырышлыларын кояшта калдырып, начарларын җиргә утыртсак нәрсә була? – дип, сорауга сорау белән җавап биргән зирәк карт.

– Кояшта калган орлыклар уңдырышлы булса да, бервакыт кибеп бетәчәкләр, ә җиргә утыртылган уңдырышсыз, начар орлыклардан авыру үсентеләр чыгачак һәм начар уңыш бирәчәк, – дип җавап биргәннәр аңа укучылар.

– Кешеләр дә шулай: тыйнак кына игелекле эшләр кылып, күңел түрендә якты матур сыйфатлар үстереп йөрисе урынга, бу эшләре турында кычкырып сөйләп, дөньяга чәчеп йөри башлыйлар. Һәм шуның белән матур эшләрен дә ямьсезләп куялар. Кимчелекләрен һәм гөнаһларын башкалар күрмәсен өчен эчкәрәк яшерәләр. Яшерен «орлыклар» үсеп, кешенең йөрәген үк зәһәрли башлыйлар. Сез зирәгрәк булыгыз! – дип, карт сүзен йомгаклаган.

Укучылар зирәк картка рәхмәт әйтеп, уйланып китеп барган.

* * *

Көн яманы тиз китә, адәм яманы тиз китми.

Мәкаль

Кызып киткәндә кылынган гөнаһларның гафу ителүенә өмет бар, әмма тәкәбберлек белән эшләнгән бозыклыкның гафу ителүенә өмет юк.

Суфьян әс-Саури
(716–778 елларда яшәгән математик).

Кулыңнан яхшы эш килмәсә, күңелеңдә ниятең яхшы булсын.

Мәкаль

Вак гамәлләр вак адәмнәрне тудыра.

Бенджамин Дизраэли (1804–1881 елларда яшәгән Бөекбритания премьер-министры, язучы).

Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен.


Мәкаль

Һәр кешедә кояш бар. Аңа яктыртырга ирек бирергә кирәк.

Сократ (б. э. кадәр 469–399 елларда яшәгән философ).

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия Гәрәева, Раилә Хәялиева әзерләде.







ТУГАН ҖИРЕ – ИЛҺАМ ЧЫГАНАГЫ


Гадәттә, ир-ат рәссамнардан: «Талантлы хатын-кыз рәссамнар бармак белән генә санарлык», – дигән фикерне ишетергә туры килә. Рәссам Чулпан Билалованы алар шушы мактаулы исемлеккә кертәләр. Һәм ул иҗат иткән дөньяга сәяхәт итүдән тәм табып, талантына сокланып, аңа рәхмәтләрен белдерәләр. Алай гына да түгел, аның кулын ир-ат рәссамнар кулы белән чагыштыралар, ягъни бик талантлы дип табалар. Без дә шул ук бәяләмәдә.

Чулпан – Башкортстанның Шәехзадә Бабич исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. 2005 елда дөнья буйлап узган «ЮНЕСКОның дөнья мәдәнияте казанышлары. Цивилизацияләр диалогы» иҗади сәяхәт экспедициясендә катнашкан. Франциянең Лион шәһәрендәге П. Гарсен сараенда шәхси күргәзмәсен ачкан. Аның кайсы Халыкара арт-симпозиумнарда, арт-фестивальләрдә, биеннале, олуг күргәзмәләрдә катнашуын санап чыгар өчен генә дә берничә сәгать кирәк булыр иде! Китаплар өчен генә дә меңгә якын иллюстрация ясаган! Болар барысы да Мәскәүдә яшәп иҗат итүче рәссам, график, дизайнер Чулпан Билалова турында.

1987 елны Башкортстанның Акмулла исемендәге дәүләт университетын тәмамлагач, ул берничә ел мәктәп һәм колледж укучыларына сынлы сәнгать дәресләре бирә, 1999–2007 елларда «Акбүзат» балалар һәм яшүсмерләр журналында бүлек мөдире, җаваплы сәркатип булып эшли. 2007 елда ул инде Мәскәүнең «АРС Комьюникейшенс» эвент-компаниясе креатив бүлегенең арт-директоры. Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы Чулпан Билалова 2016 елдан – ирекле рәссам. Аның иҗаты Бөекбритания, Кипр Республикасы, Болгария, Голландия, Франция тамашачыларына да таныш, әсәрләре күп дәүләт тупланмаларын бизи. Алабугада узучы Халыкара арт-симпозиумнарда берничә ел буе катнашып килә. Шулкадәр күп бәйгеләрдә җиңеп чыккан рәссам нинди була икән? «Мин, – ди Чулпан, – бик эмоциональ зат, кешеләрне яратам. Яңа картинама тотынсам, аны унар сәгать һәм бер сулышта, куллар тәмам арыганчы язам, ә инде тәмамлагач, картинага бернәрсә дә өстәрлек булмый!» Чулпан әсәрләрендәге күңелле балачак мизгелләре һәркемгә якын. Голландиянең Геффен шәһәрендәге студиясендә дә языла бу тематикадагы картиналар. «Әмма беркайчан да чит илдә яшәп калмас идем, – ди ул. – Мин туган җиремдә генә илһам алам!»

Аның иҗаты төрле күргәзмәләрдә дәрәҗәле урыннар белән бәяләнә. 2018 елда ватандашлары аны Бөтенроссия сынлы сәнгать бәйгесе лауреаты буларак алкышлый. Аның мәгълүм җырга багышланган «Китә казлар Донбасска», милли гореф-гадәтне чагылдырган «Кыз урлау», атларны гәүдәләндергән «Кара елкыны су кертү», «Кылган» һәм башка искиткеч композицияле фәлсәфи, экспрессив, динамик, эмоциональ, туган як рухы, йолалар, гореф-гадәт һәм башка сакраль үзенчәлекләр, халыкның милли рухы сеңгән әсәрләре беркемне дә битараф калдырмый. Рәссамның шәхси күргәзмәсе Казанда да ачылыр әле. Татарстан Чулпан Билалованы үзендә зур түземсезлек белән көтә!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА











ЧУЛПАН БИЛАЛОВА









ALEXANDER BOGDANOV

Романтика ваших чувств!

Казань, «SUVAR PLAZA», 1-й этаж
тел: 8 (843) 267 17 37
alexanderbogdanov.com

ПРЕДЪЯВИТЕЛЮ КУПОНА
СКИДКА **10%**

РЕКЛАМА